1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2021 ФЕВРАЛЬ № 2

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ИЛСӨЯ БӘДРЕТДИНОВА
аны нәрсә куркыта

йорт куяныннан
РАГУ
һәр останың үз сере

ВАЗЭКТОМИЯ
капма-каршы фикерләр

Энҗе САДЫЙКОВА:
«Хатта – җан җылысы, кул җылысы, йөрәк җылысы...»

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!
Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Минә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...
Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!
Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Нурия ИЗМАЙЛОВА

ӨМЕТЛӘР

Яшел күзле кызым туса,
Яшел күлмәк тегәрмен.
Каермын да кайгырырмын,
Килешми дип йөдәрмен.

Дәртле-хисле улым туса,
Эскерипкә алырмын.
Көе килми дип көйсәм дә,
Биермен, юанырмын.

Яңа-көя тегелер дә
Килешә дип киелер.
Көлә-көлә биелер дә
Җылый-җылый сөелер.

Үтәлмәгән теләкләрне
Басар татлы күз яше.
Бөек Яшәү көен табып
Җырлар Сөю чишмәсе!

Яшел күзле кызым булгач,
Аерылмам яшьлектән.
Дәртле-хисле улым булгач,
Кипмәс илһами чишмәм.
Мин булырмын Әбелхәят
Чишмәсеннән су эчкән!

■ Мин – әтием белән әниемнең бердәнбер баласы. Алар мине 15 ел көткән. Көткәннәр өчен бик озын вакыт бу! Кияүгә чыккач, бер-бер артлы өч бала табып, әти-әниемне куандырдым. Без гел бергә. Әниемне һәрвакыт үзем белән йөртәм, матур киемнәр бүләк итәм, косметологка алып барам, бергә сәяхәт итәбез. Аның куанганын күреп күңелем шатлана. Әнинең гомерен шатлыклы мизгелләр белән генә бизисем килә. Балаларыма да үрнәк күрсәтәм. Безнең дә бит әле картаясы бар...

Люция Алиева. Казан.

Фото: Мила Дементьева.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021




Фото: Гөлнара Сагиева

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Энҗе Садыйкова
Фото: Регина Кириллова

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 3.02.2021 ел.
Чыгу көне: 10.02.2021 ел.
Заказ Е-293
Тираж 9500

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Россиядә: ПО279 (берьеллык)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA





Фото: Анна Арахамия

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ, ПАТРИОТ-ШАГЫЙРЬ МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА – 115 ЕЛ

Муса ҖӘЛИЛ

Хат ташучы
(поэмадан өзекләр)

Тимербулат – хат ташучы,
Бригадир кыз – Фәйрүзә.
Тимербулатның үзәген
Шушы Фәйрүзә өзә.

***

Сызылып таңнар аткан чакта,
Кызлар кырга китәләр,
Кызлар кырга киткән чакта
Юлдан җырлап үтәләр.

«Хат язам да хат язам,
Инде ничә кат язам.
Утырам да үзем китәм,
Бу ел көзен кайтмасаң.
Хатлар яздым ярыма,
Мәскәү калаларына.
Әгәр бу ел да кайтмасаң,
Үзем барам яныңа.
Хатлар яздым утырып,
Ак кәгазьләр тутырып.
Хат урнына үзем китәм
Чуенкәгә утырып...»

Безнең тышлыкта

«Татар – сүзе белән көчле. Безнең открыткалардагы иң мөһим милли әйбер – ул татарча сүз.»



Хатлар яздым утырып... 10
Раилә Хәялиева

Заман һәм без

6 Бәйләтергәме, бәйләтмәскәме?
Чулпан Галиәхмәтова

Һоп-һоп! Киттек! 14
Раилә Хәялиева



16 Мин таянып калдым Шигырьгә!
Эльмира Закирова

«Кешеләргә әйтер сүзем бар...» 20
Чулпан Галиәхмәтова



ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы



22 Әби-бабайлы йорт
Чулпан Галиәхмәтова



26 Иң тугры дустым – ялгызлык
Гөлнур Сафиуллина

30 Йөз егерменең берсе
Фәнзилә Салихова

Мәдәни тормыш



36 Коткаручы
Илсөяр Иксанова

40 Мәскәүдә бар татар «Чишмә»се
Лилия Гәрәева

Яшәеш



48 Тунис белән очрашу
Руслан Ахунов



44 Сыңар алкалар
Фәгыйлә Шакирова

Хуҗабикә

57 Арка мускулларын ныгытабыз

58 Юыну бүлмәсе
Лилия Гәрәева



60 Йорт куяныннан рагу





АКТУАЛЬ ТЕМА

БӘЙЛӘТЕРГӘМЕ, БӘЙЛӘТМӘСКӘМЕ?



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Бу хакта сөйләшмиләр. Хәтта бер-берсенә бик ышанган ир белән хатын да әлеге теманы читләтеп уза, чөнки моның турында сүз дә булырга тиеш түгел кебек. Шулай кабул ителгән инде. Әмма цивилизация үскән саен, Европа илләрендә ул массалы төс ала. Шулай да җәмгыятьтә каршылыклар күп. Аның төсмерләре күп булганга шулай ул. Хатын турында кайгыртумы бу, җавапсызлыкмы, әллә бүгенге көн шаукымына бирелеп, зур хата ясаумы?.. Җавап табарга тырышыйк әле.

Сүз медицина процедурасы – вазэктомия хакында бара. Ир-атларны хирургик юл белән стерильләштерү – балага узмас өчен саклану алымнарының киң таралган төре. Статистика буенча, Канада, Нидерланд, Бөекбритания һәм Яңа Зеландиядә яшәүче ирләрнең 18 проценты әлеге процедураны үткән. Австралиядә ул соңгы дүрт елда популярлашкан: мәсәлән, 2018 елда аларда 25 мең ир бу адымга барырга карар кылган. Стокгольмда да вазэктомия ясатырга теләгән ир-атлар саны икеләтә арткан. Бу операцияне, нигездә, 40–49 яшьлекләр ясата икән.

Юк, ялгыш язмыйм. Чынлап та, ир-атларны стерильләштерү турында бу язма. Сәер, әйеме? Чөнки гомер-гомергә Россиядә балага узу-узмауны көйләү мәсьәләсе хатын-кыз проблемасы булган. Гади итеп кенә әйткәндә, бу – хатын-кызны борчыган иң авыр мәсьәлә. Итәк тулы баласы булган хатын, кабат балага узмас өчен, чарасын үзе күрергә тырышкан. Төнәтмәләр эчкән, кайнар мунча кергән, медицина алга киткәч, төрле препаратлар кулланган, бала төшерткән... Элек-электән шулай куелган: хатын-кыз бала төшертү юлында йөрсә йөргән (ә бу аның йөрәгенә тигән иң авыр адым һәм гөнаһ!), әмма иренә каршы килә алмаган.

Вазэктомияне кастрация белән бутарга ярамый. Әмма әлеге процедураларның уртак ягы бар – балага узу 99 процент булмаячак. Интернет битләрендә йөргән хәбәрләргә карасак, вазорезекция кирәк булганнарның 20 проценты гына әлеге процедурага барырга карар кыла, чөнки бу хакта мәгълүматлары әз, бөтенесе турында төптән үк белмәгәнлектән, курку да бар. Стерильләштерү – ярты сәгать дәвам итеп, җирле анестезия белән ясала торган микрооперация. Пациентның күкәйлекләрен тишеп, анда урнашкан орлык каналын кисеп, бәйләп куялар. Ни өчен киселә, чөнки организм үзен-үзе тернәкләндерергә тырышачак. Кисеп бәйләгәннән соң исә мәни чыгу юлы ябыла.



Табиб-уролог Владимир ПЕРЧАТКИН әйтүенчә: «Вазэктомия безнең илгә хас алым түгел. Ир белән хатын арасында сайлау ихтыяҗы туа икән, бу адымга күп очракта хатын-кыз бара».

Хатыныма бүләк

Бу операцияне ясар өчен медицина күрсәтмәсе һәм социаль күрсәтмә булырга тиеш. Әгәр гаиләдә хатынга башка бала табарга ярамаса йә ир-атның нәселдән бирелә торган генетик авыруы булса, берсүзсез, вазэктомия ясала. Чынлап та, интернет челтәрләрендә яшь кенә егетләрнең генетик авырулары барлыгы һәм аларның туачак балаларының тормышын бозасылары килмәгәнгә, бу адымга барулары турында сөйләгән язмалар очрады. Әмма моның өчен табибтан бер кочак документ җыярга кирәк. Юк икән, әлеге процедура законга каршы булып чыга. Россиядә бу нисбәттән махсус канун да бар. Федераль законның 57 нче маддәсендә язылганча, әлеге контрацепция алымы кешенең язмача гаризасы аша эшләнә. Моның өчен аның 35 яшьтән өлкәнрәк булуы йә ике һәм аннан да күбрәк баласы булуы шарт. Болар үтәлми икән, димәк, законга каршы эш башкарылып, бу гамәл җинаятькә тиң булачак. Ә ни өчен нәкъ менә 35 яшьтән соң?

Табиб-уролог, Эндоурология үзәге җитәкчесе Владимир Перчаткин әйтүенчә, 35 яшь – ир-ат өчен акыл кергән вакыт. Дөрес, табиб сүзләренә караганда, ир-атларны стерильләштерү безнең илгә хас алым түгел. Ир белән хатын арасында сайлау ихтыяҗы туа икән, күп очракта бу адымга хатын-кызлар бара. Чөнки мондый операциядән соң көчле затлар ирлек көченә кимчелек килә, потенция бозылачак дип уйлый. «Минем тәҗрибәмдә мондый операцияләр булды, әмма бик аз. Барлык пациентлар да өч һәм аннан да күбрәк баласы булган кешеләр иде. Алар белән дә алдан бик озаклап сөйләштем. Бу процедурага хатыны белән бик ышанычлы мөнәсәбәтләрдә яшәгән ирләр генә барадыр дип уйлыйм», – ди Владимир Перчаткин. Табиб, барлык документлар белән танышып чыккач, пациенттан киләчәктә дәгъвалары булмаячагы турында расписка алгач кына, операция үткәрә. Операция ясалып бетүгә үк пациент өенә кайтып китә. Җенси якынлык кылганда өч ай буе саклану киңәш ителә, чөнки канал киселүгә карамастан, авырга узу ихтималы бар. Бу – орлык капчыкларында мәни калу белән аңлатыла.

– Өч балабыз бар. Башка бала табарга планлаштырмыйбыз. Боларын кеше итәсе бар. Саклана-саклана яратышу туйдырды. Хатыным гормональ төймәләр эчүдән курка, ә мин башка төрле саклану чараларын яратмыйм. Уйладым-уйладым да, хатыныма бүләк ясарга булдым – бәйләттем, – ди операция ясатырга батырчылык иткән Борис (исеме үзгәртелде). – Бу хакта, әлбәттә, башта хатыныма әйттем. Утырып сөйләштек. Хатын-кызларга караганда, ир-атларны стерильләштерү катлаулырак. Ә безгә бары ике тишек тишәсе. Урологка барып теләгемне әйткәч, бер мәлгә аптырап калды. Уемнан кире кайтару өчен үгетләп тә карады. Егет сүзе бер була ул. Барлык анализларны, документларны җыеп бардым да,

Фото: www.pixabay.com





Зөлфия ӘЛМӨХӘММӘТОВА, психолог

Медицина күрсәтмәсе нигезендә ясалган вазэктомиядән соң ир-атлар депрессиягә китәргә мөмкин. Аны «мин ир түгел инде» дигән уйлар борчый башлый. Беренчедән, стерильләштерү сексуаль тормышка берничек тә тәэсир итми. Икенчедән, ирләр шуны онытмасын иде: ир һәм ата булу – икесе ике әйбер.
Ир-ат үз каныннан булмаган балага да – ата: аны кайгырта, кечкенә кешегә чын дус була ала. Чит баланы тәрбияләп, биологик әтисен алыштырган кешеләр турында күп үрнәкләр беләбез. Ата бу-лып була, моны бик тә нык теләргә генә кирәк.

Әгәр вазэктомия психологик яра салып, ир-атның интим тормышына тәэсир итсә? Озакка сузылган депрессия импотенциягә китерә ала. Бу вазэктомиядән соң гына түгел, төрле стресс нәтиҗәсендә дә килеп чыгарга мөмкин. Аны дәвалап була. Вакытында белгечләргә генә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кайчак дару эчүгә караганда, бу процесс әле нәтиҗәлерәк тә. Ир-ат бары тик үз эченә бикләнмәсен, йомылмасын, дәваны алкогольдән генә эзләмәсен. Ышаныгыз: хәл ителә торган проблема ул.

ярты сәгатьтән инде операциядән чыккан идем. Дөрес, өч-дүрт ай сакландык. Хәзер бөтен шикләнүләр, борчылып көннәр санау онытылды. Хатынымның да миңа карата ышанычы артты кебек. Интим тормышыбыз да яңа төсмер алды.

– Иртәгәсе көнегез өчен курыкмыйсызмы?

– Беренчедән, без инде хатыным белән бергәләп утны-суны кичкән кешеләр. Бер-беребезгә бик нык ышанабыз. Балаларыбыз үсеп килә. Хыянәт, аерылышу турында сүз дә була алмый. Ярату дигән хис бар бит әле ул җирдә... Без – бер гаилә! Икенчедән, нинди фаҗигаләр турында уйлый башлыйсың икән, бу дөньяда яшәп тормасаң да була. Безнең гомер барыбер кайчан да булса фаҗига белән тәмамлана түгелме соң? Иртәгәсе көн – Аллаһы Тәгалә кулында. Бу процедураның радикаль икәнен дә беләм, күпләр мине аңламас. Шуңа күрә бу хакта якыннарыбызга әйтмәдек. Гомумән, ул ир белән хатынга гына кагыла. Башкаларның бу хакта белергә, гаепләп сөйләргә хакы юк. Иң мөһиме: без бүген бәхетле.

Кирегә юллар юк

Хатын-кызларны стерильләштерү – гомерлеккә. Аларның репродуктив фукцияләре башка эшләмәячәк, ә ир-атларныкын кире кайтарып була дип язалар интернет битләрендә. Биш ел эчендә операция ясатсаң, киредән торгызу мөмкинлеге 55 процентны тәшкил итә. Владимир Перчаткин әйтүенчә, бу сан күпкә әз, юк чигендә. «Орлык каналы бик нечкә җир. Бәйләнгән каналларны чишеп тоташтыру – микрохирургик операция... Моның өчен махсус инструментлар, микроскоплар кирәк. Каналны тоташтырсаң да, җөй кала. Алынган җәрәхәт үзен сиздерми калмый. Казанда андый операцияне, гомумән, ясамыйлар. Вазэктомиядән соң елдан-ел репродуктив функцияне кире кайтару мөмкинлеге азая. Организмда мәнигә карата антитела эшләнеп чыга башлый – организм үзеннән-үзе орлыкны бетерә. Шуңа күрә, бу адымга барганчы, мең кат уйларга кирәк. Әгәр медицина күрсәтмәсе аркасында хатын белән ир-ат арасында сайлау туа икән, ирләргә операция ясау күпкә җиңел. Кабатлап әйтәм, әгәр сайлау мөмкинлеге туа калса гына бу процедурага барырга киңәш итәм. Анда да бик ышанычлы мөнәсәбәтләрдә яшәсәләр. Хәзер, мәсәлән, ир, хатынын җәлләп, бу адымга барды, ди. Кем белә, бәлки, аерылышырлар. Ир-ат яңа гаилә корыр, бала табасылары килер. Әмма инде күперләр янган булыр. Дөрес, орлыкны банкка биреп консервация ясау, күкәйлектән биопсия ысулы белән сперма алып, ЭКО ясау мөмкинлеге юк түгел. Чыгу юллары бар, әмма катлаулы. Әйткәнемчә, организм

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Любовь МУМЛАДЗЕ, сексопатолог-андролог

Бу язмага тотынгач, сексопатолог-андролог Любовь Мумладзе фикерен дә сорамый кала алмадык. Ул, билгеле булганча, ир-атлар сәламәтлеген кайгыртучы, хәтта чаң кагучы табиб.

– Мин бу контрацептив алымга берсүзсез каршы. Практикамда да ир-атларны стерильләштерү очрагы булмады. Беренчедән, ир-атлар тәннәренә, бигрәк тә җан җирләренә бик четерекле карый. Икенчедән, ир-атлар ирек ярата. Табигатьләре шундый! Аларның һәрвакыт сайлау мөмкинлеге булырга тиеш. Бүгенге ныклы гаиләне иртәгә нәрсә көтәсен беркем белми.

Сексопатолог буларак, шуны әйтә алам, «бәйләткәннән соң» ир-ат үзгәрми. Дөрес, хисчән, бик сизгер кеше булса, «миннән башка бала таба алмаячаклар» дигән комплекс барлыкка киләчәк. Ә дәрткә ул бөтенләй йогынты ясамый. Хатын-кыз берничә кат барып бала төшертергә мөмкин, ә ирләр мондый нәрсәләрне бөтенләй яратмый. Тик бер ир-ат та үзе теләп бу процедураны ясатыр дип уйламыйм. Оригиналга тияргә ярамый. Үтә нечкә җир ул. Кабат төзәтеп булмаячак.

мәни ясауны дәвам итә. Күкәйлекләр шартламаячакмы дигән сорау да туарга мөмкин. Юк, әлбәттә, ул организмда үзеннән-үзе таркала бара. Гормональ фон да үзгәрми», – ди табиб.

Зиначылыкка юл

Хатынын кайгыртып, вазэктомиягә баручы ирләргә карата хөрмәт кенә туа. Әмма йөгәнсезлеккә дә юл салынырга мөмкин. Бик күп танылган чит ил шәхесләре, Пеле, Рональдо кебек Бразилия футбол йолдызлары бу процедурага барулары турында ачыктан-ачык әйтәләр. Ярый ла хатыннарын кайгыртып кына бу адымга барсалар... Әмма күреп торабыз, бик күп танылган кешеләрнең әле анда, әле монда никахсыз балалары килеп чыгып, баллы тормышларына дегет сала. Әлеге хәлне булдырмас өчен, вазэктомия – йөремсәк ирләр өчен менә дигән чара. Тик бу инде кайгырту түгел, җавапсызлык билгесе. Интим тормышларында хаос булган әхлаксыз зиначылар. Кайберәүләр вазэктомия инфекцияле авырулардан да саклый дип уйлый икән. Бу белемсезлектән килә. Әлеге процедура берничек тә авырулардан саклап кала алмый. Үзең корган капканга үзең үк эләгергә дә мөмкинсең...

Бүген – чайлдфри, ә иртәгә...

«Миңа 28 яшь. Кечкенә чактан ук башка балаларны яратмый идем, гел өлкәннәргә тартылдым. Хәзер дә миңа 40 яшьтән өлкәнрәк кешеләр белән аралашу рәхәт. Аннан соң илдәге социаль-икътисадый вазгыятьне төшенгән саен, балам булмаячагын аңладым. Классик гаилә кору, ата булу – минем өчен түгел. 19 яшемдә чайлдфри дигән агым барлыгын белдем. Социаль челтәрләрдәге төркемнәрдә аралаша башлагач, мондый кешеләрнең вазэктомия ясаулары мәгълүм булды. Бу процедура турында укый башладым, өйрәндем һәм моның миңа кирәк алым икәненә төшендем. Укыган вакытта акча юк иде. Аннан соң безнең илдә баласыз яшь кешеләргә операция ясату закон буенча тыела. Дөрес, метрода теләсә нинди документ ясатып алып була, шуларны тотып шәхси клиникага барсаң, карап та тормаячаклар, дип киңәш биргәннәр иде. Әмма мин алай теләмәдем. Финанс ягыннан аякта нык басып тора башлагач, чит илгә барып, түләүле клиникада бәйләтеп кайттым. Өч елга кадәр операция ясатсаң, барлык функцияләрне дә кайтарып була, диде табиблар. Әмма ул хакта тыңларга да теләмәдем. Бу мине бөтенләй кызыксындырмый. Әтиәнием, билгеле, бернәрсә белми, әйтмәячәкмен дә. Моның ни белән бетәсен чамалыйм чөнки. Элек нәсел дәвам иттерәсем килми, дип әйтә идем. Мине ул чакта беркем дә җитди кабул итмәде. Безнең илдә, беләсез, ир-ат өй салырга, агач утыртырга һәм ул үстерергә тиеш. Әмма мин стереотиплардан азат. Дуслар мондый радикаль адымга баруыма гаҗәпләнде гаҗәпләнүен. Тик бергә яшәгән сөйгән ярым операциягә ике куллап риза булды. Ул да минем кебек үк чайлдфри. Вазэктомия ясаткаҗннан соң үземне ирекле итеп хис итәм».

Интернет битләрендәге чайлдфри төркемендә утыручы берсенең тарихы бу. (Чайлдфри, ягъни баладан ирекле яшәүчеләр субкультурасына керүчеләр. Алар аңлы рәвештә бала тапмый. Бу агым Америкада барлыкка килгән. Ике меңенче елларда Россиядә дә популярлаша.) Билгеле, ул миңа исемен дә, кайда яшәвен дә әйтмәде. «Сезгә исемем түгел, позициям мөһим», – дип язу белән генә чикләнде. «Ун елдан соң чынлап гашыйк булып, ул кыздан балаң тууын теләсәң нишләрсең?» – дигән соравыма кырт кына: «Бу мөмкин хәл түгел», – дип җавап бирде. Яше инде утызга җитсә дә, яшьлек максимализмы чыгып бетмәгәнен аңладым. Мондый яшьләргә нидер аңлату мөмкин дә түгел. Алар дөньяны ак һәм кара төсләрдә генә күрә кебек. Әлеге кешеләр өчен вазэктомия алымын куллану тормышларындагы төзәтә алмаслык иң зур ялгышлык та булырга мөмкин. Җитмәсә, документларга карап тормыйча операция ясарга әзер табиблар да очраса.

«Яшь кешеләр нотариаль яктан расланган әллә нинди документлар алып килсә дә, операциягә барыбер алынмыйм. Бу агымга ярдәм итәсем килми. Аңлыйм, һәр кешенең сайлау мөмкинлеге бар. Әмма иртәгә фикерләре үзгәрмәс дип, кем гарантия бирә ала? Барысы да катгый закон буенча эшләнергә тиеш», – ди Владимир Перчаткин.

Мәкаләгә төрле фикерләр кертергә тырыштык. Чынлыкта ир белән хатын арасында гына сөйләшә торган интим темаларның берсе бу. Әлеге процедураның кирәкме-юкмы икәне дә ачык сорау булып калсын. Һәр балалы (!) парның үз дөреслеге булсын. Мин шулай телим дип түгел, безгә шулай уңайлырак дип эшләнсен. Уйланып. Терсәк якын кайчак, әмма...



Булат хәзрәт МӨБАРӘКОВ, Татарстан Диния нәзарәтенең шәригать бүлеге җитәкчесе, Голамәләр шурасы әгъзасы, Казан казые, Коръән-хафиз

Әлеге процедура – шәригатькә, бигрәк тә ир-ат табигатенә каршы килү. Бу инде ирлекнең бер өлешен югалту дигән сүз. Дин буенча карасак та, кеше биологиясе буенча карасак та, аңлыйбыз: кеше бу җиргә үзеннән соң нәсел калдыру өчен яратылган. Аңардан сәламәт балалар туарга тиеш. Ә ул операцияне ясатып, бу миссиясен югалта. Аллаһы Тәгалә кешенең табигатен үзгәртүне тыя. Медицина күрсәтмәсе булса – икенче мәсьәлә. Үлем йә яшәүне дәвам иттерү арасында сайлау кирәклеге килеп баса икән, ул вакытта рөхсәт ителә. Гомереңне дәвам иттерүне сайларга кирәк. Ләкин башка шартларда рөхсәт ителми. Ул – ислам шәригатендә гомуми кагыйдә.

Хат килгән! Йөрәк дөп-дөп тибә! Кулда әле ачылмаган конверт! Җентекләп маркаларын күзәтәсең, печатенә игътибар итеп, ничә көндә килеп җиткәнен санайсың. Аннан, бармаклар белән капшап, конвертта фото бармы-юкмы икәнен тикшереп чыгасың. Сак кына кисеп ачасың. Ертылып китмәсен! Таслап төрелгән кәгазь шыгырдавы, каләм исе, тигез юллар. Ымсынып укырга керешәсең. Кабат-кабат укып чыгасың. Аннан җавап язарга утырасың. Яңа конвертны кулыңа алып адрес язасың. Ябыштырганда ничек тә телне кисмәскә! Ябыштырган җиргә параллель сызыклар сызып чыгасың. Юлда ачмасыннар, янәсе. Зәңгәр почта тартмасының ачык авызына хатыңны шудырасың. Капкачы ябылуга, яңадан хат көтә башлыйсың...
Энже САДЫЙКОВА – «Хатлар йорты» проектының авторы. Без аның белән хатлар язуның сере, тылсымы һәм хат алышу гадәтен кире кайтару хакында сөйләшәбез.

Фото: Регина Кириллова

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП...



Раилә ХӘЯЛИЕВА

*«Хат башы, яз каршы!»**

Тормыш иптәшем Фәнис белән без бөтенләй төрле эшләрдә эшлибез. Мин – университетта төрек телен укытам, тәрҗемә белән шөгыльләнәм, ә ул үзенең it-проектын җитәкли. Ләкин шуңа да карамастан, безне татарча тәбрикләмәләр иҗат итүче «Хатлар йорты» проекты авторлары буларак беләләр. Инде алтынчы ел эшләп килгән «Хатлар йорты» безне дуслар, танышлар, хәтта милләт белән дә бәйләп торучы проект ул.

Һәр нәтиҗәнең сәбәбе – балачакта. Открыткалар белән әвәрә килүем дә юктан гына килеп чыкмагандыр. Кечкенәдән төрле матур картина, постерларга исем китә иде. Әни миңа дип алдырган «Миша» журналында хат алышу өчен адреслар да бирелә иде. Берсендә шундагы адресларны алып, мин дә хат язып карадым. Ярты ел буена ник бер җавап хаты килсен! (Нәүмизләнеп, хат көтүнең ни икәнен белүчеләр бардыр әле!) Инде миңа язмыйлар, дип өметем өзелгәндә, почта тартмасы Россиянең төрле шәһәрләреннән килгән хатлар белән тула башлады! Шулай итеп, кечкенәдән хат алышуның тәмен тоеп, татып үстем. Соңрак, журналистикага кереп киткәч, язмаларга баш исем уйлап табу белән мавыга башладым. Берничә сүз генә кулланып, кешеләрнең игътибарын яулый алу кызык тоела иде миңа!
Фотога төшерү белән мавыккан чорда визуаль сәнгать законнарын өйрәндем. Университетка укырга кергәч,

төрле экспериментлар ясарга керештем. Беренчесе – «Татар балы» белән оеткы рәвешендә иҗади лаборатория ясарга теләгән идем. Иҗат дөньясы шулкадәр киң, колач җитмәслек чиксез икән ул, бераздан, таралып китмәс өчен, тараерга кирәклеген аңладым. Фото белән кызыксынуым җиңеп чыкты: «Кәрәз клуб» татар фотография мәктәбе туды. Ниләр генә уйлап чыгармадык без! Дүрт ел эчендә җиде курс оешты, өч күргәзмә ясадык һәм проектның башы түшәмгә тигәне аңлашылды. Һәм тагын да тараерга кирәклеген аңладым. Миндә татарча тәбрикләмәләр ясап карау идеясе бөреләнде. Әлбәттә, миңа кадәр дә татарча открыткалар чыгаручылар бар иде. Әмма әлеге тәҗрибәм теле кызыклы булган, заманча продукциягә ихтыяҗ зур икәнлеген аңларга ярдәм итте. Беренче эш итеп, үзем Photoshop программасында конвертлар, открыткалар ясап, аларны кулдан кисеп, ябыштырып дусларыма, якыннарыма җибәрә башладым. 2014 елда шул открыткаларны сатарга Печән базарына чыктык. Монда безне сүктеләр дә, мактадылар да, әмма барлык открыткаларны алып та бетерделәр! 2015 елда инде «Хатлар йорты» проектына ирем Фәнис тә кушылды. Проектны рәсмиләштердек, логотип уйлап таптык, җитди типография белән эшли башладык. 2016 елда инде безнең Казанда 30 дан артык сату ноктасы бар иде. Интернет кибетебезне дә булдырдык. Әгәр биш ел элек миңа «синең тәбрикләмәләрең зур кибетләрдә сатылачак» дисәләр, ышанмас идем!

Хатлар язу өчен мөһим сәбәп тә кирәк түгел.



■ Егет чагында Фәнис тә миңа бик күп открыткалар бүләк итә иде. Финанс институтында укып йөргән егетнең үз куллары белән открытка ясап утыруларын күз алдына китерегез инде! Ә алар хәзер ничек кадерле миңа! 2013 елда очрашып кына йөргән вакытыбыз бит әле. Мине ике атнага Адыяманга укырга җибәрделәр. Киткәндә 14 көнгә 14 хат язып калдырдым. Һәр көнне берне укырга. Аларны энесе аша Фәнискә тапшырдым. Ул мине шул хатлар аша көтеп алган иде. Ә хәзер инде «Хатлар йорты»ның булуы Фәнис белән бер-беребезгә хатлар язышу гадәтен бетерде. Без бит ул открыткаларны бергәләп уйлыйбыз, төзәтәбез-яңартабыз, әллә ничә тапкыр кулдан кичерәбез. Хәер, хатларның бурычы – ерак чакрымнарны якынайтудыр ул.

«Ат җитмәс җиргә хат җитәр»

Бер елны әнигә туган көненә шактый кыйбатлы хушбуй бүләк иттем. Янына татарча тәбрикләмә дә кыстырдым. Ул елны ирем белән открыткаларны кулдан, өйдәге принтерда ясый гына башлаган идек әле. Һәм, беләсезме, әни хушбуйга биш секунд сөенде, ә тәбрикләмәгә – унбиш минут буе сокланып карап торды! Әле аннан соң да бөтен күргән-белгәнгә күрсәтеп йөрде. Инде ничә ел аның китап шкафында сакланганын да беләм. Тел төбемне аңлагансыздыр, кыйбатлы бүләк – яхшы нәрсә, тик ул бетә. Ә сүз йөрәк түрендә мәңгегә уелып кала.

Миндә гаиләбез өчен бик кадерле булган бер ядкарь: әнием Арчада укыганда әтисе Әнүрнең аңа язган биш битлек хаты саклана. Энҗедәй тезелеп киткән тигез хәрефләр, кәртинкәдәй имзасы, язуының матурлыгы!.. Менә шул дүрт-биш битлек хатны укып, бабай турында тулы бер портрет төзедем, ничек яшәвен, фикерләвен күзалладым. Миңа – өченче буын оныкка шушы хатны укып чыгу күпме тарихи мәгълүмат бирде. Авыл хәлләрен дә, бер буразнадан ничә капчык бәрәңге чыгуын да, авылдашларының яңалыгын да сыйдырган ул анда. Телефоннар юк заман бит, барысы да хат аша сөйләнелгән. Сәламнәр белән башланган, хәбәрләр, хәл-әхвәл сорашу белән дәвам иткән, күргән-белгәнгә сәлам юллап, матур теләкләр һәм имза белән төгәлләнгән – безнең халыкка хас хат язу үрнәгенең иң матур өлгеседер ул, минемчә. Кайчандыр хат язганда гына кулланылган канатлы сүзләр булган, хат язуның үз тәртибе сакланган. Хатлар кешеләрне яшәткән, бер-берсенә бәйләп торган. Хатлар аша мәхәббәт тарихлары язылган, сөйгәннәрнең язмышлары хәл ителгән. Хәзер кешеләрнең хат язышмавына борчылам! Ватсап, интернет аша хат язуның яме юк бит аның! Югары техника заманында яшәсәк тә, киләчәк буын, оныклар безне ничек хәтерләр икән соң? Смайликлар яисә таныш-белешкә җибәрергә дип, кафега, театрга баргач төшкән кыска видеолар ашамы?! Аларга карап кына безнең фикер сөрешебезне, күңел халәтебезне күрә алырлармы икән? Хат язу шундый татлы романтика бит ул! Хатлардагы сүзләрдә язган кешенең кулыннан сеңгән үз җылысы саклана бит аның. Хаттагы сүз фикерләрне үзгәртергә сәләтле!

Минем әни – көчле холыклы, үз сүзендә нык тора торган хатын-кыз. Авырлы вакытында күңеленнән генә миңа Эльза дип исем кушарга карар кылып куйган. Мин тугач, төнлә әтигә шалтыратып хәбәр биргәннәр. Дәрвишләр бистәсе урманнары аша әти төнге икедә бала тудыру йортына киткән. Әни белән күрешә алмаса да, акушерка аша кыска гына хат җибәргән: «Котлыйм! Рәхмәт! Кызның исеме Энҗе була.» Өч җөмлә. Шушы кыска хат әнине йомшарткан. Шуннан күз алдына китерегез инде минем тормышымдагы хатларның ролен! Хатка язган сүз тирәнрәк мәгънәгә ия, аның җаны бар төсле. Әмма бүгенге көндә социаль челтәрләр сүзнең бәясен төшерде, ямен югалтты дип уйлыйм. Менә шул тылсымын кире кайтарасы килә безнең! «Хатлар йорты» проектының төп максаты – әти-әниләр, әби-бабайлардан калган, инде онытыла башлаган гамәл – кәгазь битенә хатлар язу, бәйрәмнәрдә генә түгел, хәтта бер сәбәпсез

Хат килгән көннең һава торышы ук истә кала кайчак.

бер-беребезгә татарча открыткалар җибәрү гадәтен торгызу.

Алты-җиде ел элек, халык телефон белән мавыккан бер мәлдә, хат экспериментларымны башладым. Кулдан язып утызлап хат җибәргәнмендер. Беренче тапкыр хат алган кешеләрнең ул вакыттагы эмоцияләрен күрсәгез икән! Төркиягә укырга баргач, үземнең әниләргә һәм ул вакытта әле булачак иремнең әти-әниләренә открытка җибәргән идем. Шактый вакытлар узып, инде танышырга кайткач, аш бүлмәсендәге сервант тәрәзәсенә кыстырып куелган Төркия открыткасына күзем төште. Саклаганнар! Открытка, хат алу – кеше өчен онытылмас хис. Элек безнең дәү әниләр, әбиләр хатларны, чәчәкле открыткаларны бер чите белән стенадагы ярыкка яки түргә эленгән көзгегә кыстырып куя торган булганнар. Кайберәүләрдә әле өчпочмаклы сугыш хатлары да саклана торгандыр.

Ә хатны көтү хисе! Көн саен почта тартмасын тикшереп тору, көннәр санау... Почтальонның, биетеп, хат биреп китүе! Ертмаска тырышып кына конверт ачулар... Солдат хатлары!

Мин үзем кечкенә чакта әбиләремә бәйрәмнәргә открыткалар җибәрә идем. Кызым Ләйлә белән дә хатлар язабыз. Сүзне, фикерне кәгазьгә язып та җиткереп булуына төшендереп үстерәсем килә баламны. Студентларымны да бу идеягә төрдем. Кайсы илгә китсәләр дә, сәлам хатлары алам, открыткалар җибәрәләр.

Шунысын да әйтим, әгәр дә миңа вакытында Фәнис ышанмаган булса, бу проект идея буларак бер урында калыр иде. ИПлар оештыру, исәп-хисапны алып бару, кибетләр, накладнойлар, бизнес нечкәлекләрен аңлау... Юк-юк, мин болар турында уйларга да куркыр идем. Ә хәзер яхшы аңлыйм, менә шул куркулар аркасында без, хатын-кызлар, үзебезнең күпме хыялларыбызны, потенциалыбызны чынга ашырмыйча калабыз! Андый мисаллар тирә-юньдә генә дә тулып ята бит! Идеяне үстерер өчен финанс ягыннан белемең булу кирәклеген генә искә төшерәсем килә, чөнки хыяллар чынга ашарлык көч белән бергә туа ул. Чикләр куймыйча, һәрнәрсәнең чынга әйләнәсенә ышанып яшәргә генә кирәк.

Хат өмәсе

Узган гасыр башында ук нигез салынган Hallmark компаниясе чыгарган открыткаларын күргәнегез бардыр инде. Hallmark компаниясенә Америкада яшәүче абыйлы-энеле ике кеше нигез сала. Бервакыт аларның барлык товарлары да сакланган открытка кибетләре янып китә. Бу вакыйгадан соң алар бизнесларын үстерүче яңа алым уйлап табалар: открыткаларны конвертларга салып сата башлыйлар. Конверт эчендә җибәргәндә открыткага язылган сүзләрне башка кеше күзеннән саклап булганын аңлап ала халык. Шулай итеп, Hallmarkның эше яңадан үргә китә. Безнең открыткаларга кибеттә сатылганда зыян килмәсен өчен үтә күрен-мәле конверт «кидертү»нең матур тарихы да Hallmarkныкыннан бер дә ким түгел.

Открыткалар күпләп сатыла башлагач, зур типография белән эшли башларга туры килде. Ә типографиядә аз тиражда бастыру бик кыйммәткә чыга. Шуңа 350 данәдән берничә төрле открытка алабыз. Ә аларның барысын да үтә күренмәле конвертларга салырга кирәк. Уйладык-уйладык та, машинага төяп Фәниснең туган ягы Нурлат районы Бикүле авылына алып кайтып киттек. Авыл кешеләре өчен мондый эш бәйрәм икән ул! Шәһәргә китә торган әйбердә катнашуны зур итеп кабул иттеләр. Авыл халкына чын күңелдән сокланам мин! Открыткалар кайтуга – өмә җыябыз! Әнкәй тиз генә ватсаптагы группадан авылдашларга яза. Озак та үтми, өйгә унлап кеше килеп утыра. Әнкәй бәлеш сала, телевизордан кызыклы тапшыру куеп җибәрәләр. Аңа күз төшерүче кеше дә юк инде, фасон өчен генә сөйләп тора. Авыл апалары кайсы открытканы мактый, кайсы тетмәсен үк тетеп ата! Ихлас алар! Кул эшли, сүз куера тора, нәкъ элеккеге кич утырулар кебек! Җай булганда үзебез дә алар белән кайтып утырабыз. Аннан, авыл халкының кул җылысы сеңгән конвертлы открыткаларны төяп, яңадан Казанга алып китәбез. Хат өмәсе шулай оеша.

«Каз канаты каурый-каурый, Хатлар язарга ярый...»

Үзем төрле шәхесләрнең китапларына кергән хатларын укырга яратам. Хәсән Туфанның хатлары урын алган китапны кадерләп саклыйм. Хатлар – ядкарь ул. Язучылар да шәхес буларак хатларында күбрәк ачыла.

Диссертация язганда Ататөркнең башка ил башлыкларына язган хатлар китабына юлыккан идем. Төрекләрнең хат язу алымнары безнекеннән шактый аерыла икән. Төркиядә открытка, хатлар язу әллә ни популярлык алмаган. Гомумән, минем фикеремчә, хат язу, хат тәмен тоя белү Россия җирлегенә генә хас әйбер бугай.

Татар – сүзе белән көчле. Безнең открыткалардагы иң мөһим милли әйбер – ул татарча сүз. Дизайн белән шаккаттырырга тырышмыйбыз. Открыткалар алар – көндәлек товар. Төп акцент – сүздә. Открыткаларда милли код булырга тиеш дип уйлыйм мин. «Татарның каймагына», «Нинең ниен нитәбезме?» Бу җөмләләрне бары тик татарлар гына аңлый, килешәсезме? Безнең тагын бер үзенчәлек – ул сәбәпсез открыткалар. «Син миңа кирәк, онытма!», «Мин чәйне шикәр белән эчәргә яратмыйм, синең белән эчәргә яратам», «Йөз ел очрашкан юк!» Мондый открыткаларны кемгә дә биреп була бит, бәйрәм килгәнне көтеп тә торасы юк! Открыткаларга сүзләр эзләгәндә әйтемнәргә, җырларга мөрәҗәгать итәргә тырышам. «Шикәрем син, балым син, сөеп туймас ярым син» дигән открытканың сүзләрен менә кайнанам уйлап тапты. Идеяләрегез булса, сез дә языгыз! Журналның бу санында бүләк итеп махсус сезнең өчен дә открытка иҗат иттек. Егермеләп вариант от-

крытка ясап карадык! «Сөембикә» укучылары өчен иң зәвыклысы, матуры булырга тиеш иде ул! Уйлый торгач, рәссам Лилия Гәрәеваның «Ана каз» иллюстрациясенә тукталдык. Каз темасы безгә якын бит ул. Каз белән бәйле мәкаль-әйтемнәр, җырлар, каз өмәсе... Нәкый Исәнбәтнең мәкальләр җыентыгыннан килеп чыккан «Каз канаты кауырсын, хатым килсә – алырсың», дигән әйтем дә бу идеянең дөреслеген раслады. Менә шулай итеп журнал укучыларына бүләк итәсе открытка туды.

Татар иле киң һәм зур! Әлбәттә, безнең тәбрикләмәләрне яратучы, якын итүче милләттәшләребез Татарстаннан читтә дә бихисап! Җан җылысы, кул җылысы, йөрәк җылысы саклаган хатлар тере җан кебек! Аңа кагылып була... исен тоеп... күкрәккә кысып була. Ул сөйкемле тавышлар чыгарып кыштырдый. Хис уята, сөендерә, куркыта, каушата. Һәм ул озак яши ала! Ә сез нәкъ менә шундый чып-чын хат килеп төшүен теләмәс идегезме?

---

* Язмада Энҗенең әнисе Илсөяр ханымның куен дәфтәреннән һәм Бикүле авылы халкы хәтерендә калган канатлы сүзләр кулланылды.

Открытканы кемгә җибәрергә: ерак-ераклардагы туганнарга, күптән аралашмаган классташларга, укытучыларга, өлкәннәргә, яшьрәк танышларыңа, улыңа-кызыңа.

Нәрсә язарга: «Исеңдәме..» дип, берәр хатирәне искә төшерергә, кунакка чакырырга, хәл белешергә, котлау юлларга...

Почта бүлегенә барып, открыткага марка ябыштырырга һәм хат иясенә җибәрергә.

Әйдәгез, бергәләп хат язу гадәтен яңартыйк әле! Журналда бүләк булып килгән открытканы җибәргәндә инстаграм битенә пост һәм **#СөембикәЖурналы #Татмедиа #Хатларйорты #Хатяз** хештегларын куегыз. Башкалар да кушылсын өчен, берәр дустыгызны билгеләгез һәм «Киләсе хатны син яз!» дип, эстафетаны аңа тапшырыгыз!



ҺОП-ҺОП! КИТТЕК!

– Һоп-һоп, минем яшьтәгеләр, киттек, киттек бергәләп! Һава торышы менә дигән, өйдә утырмагыз, кулга чаңгыларны, таякларны алабыз, әйдәгез, әйдә!

Түбән Каманың Сөембикә урамына янәшә урнашкан паркта яки урманында чаңгыга баскан Әлфия апаны очрату бер дә гаҗәп түгел. Һәр көнне спорт белән шөгыльләнү – кышын чаңгыда, җәен Скандинавия таякларында йөрү яшьлек дәрте өсти, күңелне күтәрә, ди. Башкалар өчен дә үрнәк ул! Урман юлында, паркта инстаграм аша танышкан, аның командасына кушылырга теләп таяк, чаңгы тотып чыккан кызлары күтә ич, әнә!

Лаеклы ялга чыккач, инстаграм блогеры булып танылган Әлфия апа Галиәхмәтова белән күптән очрашасым килә иде. Шуңа да, кышның салкын көннәре дип тормадык, тәвәккәлләп юлга чыктык. Әлфия апа безне әллә кайчан белгән танышлары кебек якын итеп каршы алды. Үзебез өчен дә гомер буе белгән кеше кебек ул! Таныш аш бүлмәсе, өлеңгеләр, чәчәкле яулыгы, чебуреклары, тәмле кайнатмалары... Ничек таныш булмасын инде, һәр көнне туры эфирда, ул төшергән видеоларда күреп торабыз ич аларны. Әлфия апа игътибардан югалмый, җәлт кенә туры эфирда да күренә, постлар да язып ташлый, үзе белән табигатькә дә алып чыгып китә.

Мамадыш районы Иске Чәбия авылында туып-үскән кыз, мәктәпне тәмамлагач башта Казанга китә. Анда укып, җитен комбинатында эшләп алгач, дус кызы чакыруы буенча Түбән Кама шәһәренә кайта, шиналар җитештерүче заводка эшкә урнаша. Ир-атлар арасында, физик көч таләп ителә торган заводта 33 ел эшли ул! Ире Назыйм абый белән дә биредә таныша. Туйдан соң да яшьләрнең һәр көне завод тормышы белән бәйле була. Ир беренче сменага эшкә чыгып китсә, ул кайткач, хатын икенче сменага ашыга. Бер-бер артлы уллары Нияз белән Ринат дөньяга килә, ике сменада эшләгәч, аларны карап үстерү дә шулай җайлана. Кечкенәдән тырыш, кешелекле булып үсә егетләр. «Авылга кайткач, печән чабарга барганда, әле кечкенә булсалар да, сәнәк тә күтәрткәннәре булмады. Өйләнгәч, хатыннарыгызга да булышыгыз, ир кешенең ярдәме беркайчан да артык булмый, дип үстердем улларымны», – ди Әлфия апа. «Илүзәмнең салаты тәмле килеп чыга, Венерамның рецепты әйбәт аның», – дип, улларының хатыннарын мактый. Алар турында «кызларым», дип сөйли. Оныклары Самат, Әскәр, Сәфинәне теленнән дә төшерми.

Сүзебез акрын гына блогер булып китү тарихына күчә.

– Инстаграмга моннан биш ел элек, лаеклы ялга чыккач ук теркәлдем. Ул вакытта әле Ринат улым (без аны танылган блогер «Татар малай» дип беләбез – *Р. Х.*) безнең белән Түбән Камада яши иде. Ялга чыктым да, инде нишлим дип утырмадым. Башта ял итәргә барып кайттык, аннан сентябрьдә «Өченче буын» университетына компьютер өйрәнергә укырга кердем, бездән ерак түгел генә урнашкан «Батыр» спорт комплексына йөри башладым. Бу вакытта инде мин инстаграмда утыра идем. Ринат миңа анда теркәлергә, фотолар куярга ярдәм итте, ә мин Ринатка үз блогында татарча матур һәм дөрес итеп язарга булыштым. Ринатның блогер булуында минем дә өлеш зур! *(Рәхәтләнеп көлә.)* Соравым булса, хәзер дә аңа шалтыратам. Инстаграмдагы битемә кереп язылучылар саны артканнан-арта барды. Блогер исемен дә халык үзе бирде. Хәзер яңа блогерлар гивлар, конкурслар аша үсәргә тырыша бит. Ә мине туры эфирларым танытты дип уйлыйм. Иртәнге биш буламы ул, алтымы, туры эфирда ашарга пешерә башлый идем. Көне-төне туры эфирда булдым. Кешеләр белән күп аралашам. Көннәр буе берсеннән-берсе матур сүзләр явып тора, «Синнән үрнәк алабыз!», «Син молодец, булдырасың!», «Син безгә бик кирәк, югалма!» дигән хәбәрләрне күп алам. Йөзләрең матур, диләр. Юк инде, анысы маска аның, дип шаяртам. Күрше йортта гына бер егет яши безнең. Мин эфирга чыккан вакытларда, аның фатирында ялгызлыгыннан каңгырып йөргән көннәре булган икән. «Радио тыңлаган кебек, гел синең татарча сөйләвеңне тыңлый идем, Әлфия апа. Лекция вакытларында да колакчын киеп, эфирыңны тыңлап утыра идем. Хәзер дә өйдә гел синең тавыш, аш бүлмәсендә минем телефонда сөйлисең, залда энем кабызып куя», – дип көлдерде беркөнне. Эфир аша дуслаштык без аның белән. Укуын бетердек, зур планнар белән йөри хәзер. Шулай итеп, туры эфир аша танышкан кешеләр күп безнең. Берберебезнең тормышын күзәтеп барабыз, җылы сүз белән булышабыз, кызларның егетләрен армиядән көтеп алабыз, кияүгә бирәбез, бала табып чыкканын көтәбез. Чит илдә яшәүче татарлар да бик күпләп кушыла башлады. Испания, Италия, Америка, Англиядән язалар. Тормыш матур димичә ни диясең! Элегрәк негатив язучылар бар иде. Эфирда утырганчы, намазга бас, дип әрләүчеләрнең күбесе үзләре минем белән туры эфирга чыга хәзер. Үзем гел позитив дулкында булгангамы – бер еллап инде хейтерларым юк. Реклама дип тә (заманнан артта калып булмый бит инде!) теләсә нәрсә куймыйм мин. Башта ныклап үземдә сынап карыйм. Ә язылучылар бик кызыксынучан минем! Нәрсә эчәсез, спорт костюмын каян алдыгыз, фирмасы нинди... Ууу, миңа килгән сорауларны күрсәгез! Кешеләр алдында үземне һәрвакыт җаваплы хис итәм, шуңа көнгә 150 шәр кешегә җавап җибәрәм!

Урамда да танийлар, исәнләшәләр. Кайвакыт кибеттә яныма килеп, мине танымыйсызмыни, диләр. Аптырап китәм. 45 мең язылучымны да хәтерләп бетерә алмыйм шул. Андый хәлләр булса, ачуланмагыз, яме! Илне, тормышны, язмышны туктаусыз сүгүчеләрне, зарланучыларны яратмыйм. Пенсиягә чыгучы хатын-кызларга да киңәшем шул: иң беренче итеп аласыз чаңгы, Скандинавия таяклары, һәм спорт белән шөгыльләнә башлыйсыз!

Әлфия апаның үзенең блогер бүлмәсе дә бар икән бит! Фатирның бер бүлмәсен уллары махсус блогер бүлмәсе итеп ясап бүләк иткән аңа. Зәвык белән эшләнгән пәрдәләр, җәймәләр, урындыклар урынына – пуфиклар, телефон куяр өчен төрле техника да бар монда!

Раилә ХӘЯЛИЕВА

– Сәлам, Марат, Миләүшә, Талия, Зилә, Нияз!.. Туры эфир өчен күп әйбер кирәкми, минут эчендә иннек сөртәм, үземне тәртипкә китерәм дә чыгам, – ди Әлфия апа. – Ә иң мөһиме – ихласлык! – дип өсти аннан. – Мин барысын да күрсәтәм, балаларны да, бакчаны да, тормышыбызны да. Назыйм гына башта фотога төшәргә һич яратмады. «Болай да кешеләр таный башлады, төшермә!» – дия торган иде. Җайлап кына уңайлы мизгелен, балыкка җыенган чагын туры китереп кенә төшергәләдем инде, аны да күрсәтәсе килә бит! Минем 42% тыңлаучыларым – яшьләр. Ир-егетләр дә күп. Ирең көнләшмиме, дип сораучылар да бар. Юк, көнләшми, кызлар, Аллага шөкер! Туры эфирларымны карый, авылда булса, шуннан кереп миңа сәламнәр җибәрә. Бигрәк матур син монда, дигән була. Чыннан да, матур булырга кирәк, кызлар! Ялга чыктым дип, үзеңә кул селтәргә ярамый. Карагыз, нинди кышкы матур көн! Рәхәт саф һава! Кулга чаңгыларны алдык та, һәй-һәй, минем яшьтәгеләр, киттек әйдәгез табигатькә!

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия



PRESSA

МИН ТАЯНЫП КАЛДЫМ ШИГЫРЬГӘ!



Шагыйрә Шәмсия ҖИҺАНГИРОВАның тормыш кагыйдәләре

ИСЕМЕМНӘН ТӘМ ТАБЫП ЯШИМ: ШӘМСИЯ – КОЯШ ДИГӘН СҮЗ. Исемем өчен хурлануларым балачакта!.. Чөнки малайлар, аны ике иҗеккә бүлеп, гел ирештерә иде. Нигә андый исем куштыгыз, дип елыйм. Апаларым Әнисә, Халисә, Әлфия югыйсә. Кияүгә чыгып, Гариповадан Җиһангировага әйләнгәч, исемемнең мәгънәсе тагын да көчәйде. Җиһангир – җиһанны яулаучы ул. Кояш кебек ялт итеп торасың, исемең җисемеңә туры килеп тора, диләр хәзер.

ШУНДЫЙ ГАҖӘЕП ҖИРДӘ ТУЫП ТА ШАГЫЙРЬ БУЛМАУ – ГӨНАҺ. Мөслимнән, Баектан башка җирдә тууымны күз алдына да китерә алмыйм. «Баекны икенче Швейцария дип әйтәләр. Барып күрәсе иде авылыгызны», – диючеләр бар. Әйе, искиткеч ул! Сарашлы буена, Башкортстан чигенә урнашкан. Роберт Миңнуллинга: «Сезнең Сөнне Сөн иткән безнең Сарашлы», – дия идем. Казанга укырга киткәнче Мөслимне бер генә барып күргәнмендер. Чөнки район үзәгенә бездән 45 чакрым, ә Бакалыга җәяү дә йөрибез, турыдан сигез чакрым гына.

ОЯЛУ МИНДӘ КАПЧЫК-КАПЧЫК! Нәселдән килә торган сыйфат инде ул. Яши-яши дә котыла алмадым шуннан. 3 яшемнән шигырь чыгара башлап, «шагыйрь» дигән кушамат та тактылар. Шулкадәр гарьләнә идем... Һич кенә дә шагыйрь булам дип йөрмәдем. Кулга каләм-кәгазь алып шигырь язуым 4 нче сыйныфта булды. Казанга 10 нчы интернат-мәктәпкә укырга килгәч, язган шигырьләремне күтәреп редакцияләргә барам да, кирәргә йөрәгем җитмичә, кире борылып кайтып китәм. Берәр иптәш кызым белән барсам гына керергә җөрьәт итәм.

ГОМЕРЕМ БУЕ ӘТКӘЙНЕ КӨТЕП ЯШӘДЕМ. Малайлар рәнҗетә башласа, «әткәйгә әйтәм» диясе килә иде. Һәм әйттем дә! Авылның икенче урамында гына яшәп ятканын беләм бит! Малайлар: «Синең әтиең түгел бит ул!» – дип, йөрәкне өтә. Ул миңа бер яшь ярым вакытта бездән китеп, «җизни, җизни», дип йөргән Сайра белән (әнкәемнең әнисе белән аның бабасы – бертуганнар) яши башлаган. Укыган кеше булмаса да, авылда радиоаппаратураны эшләтеп торды, суыткыч, радиоалгыч, телевизорлар төзәтте. «Әтиеңнең җырлаганын ишеткәнең бармы? Илһам кебек җырлый Гатуф», – диләр иде. Җырлау сәләте миңа да күчкән. Шулай туры килде: яшьләр өй сала торган урамга, Халисә апаларга каршы гына әткәй дә йорт салып чыкты. Апамнарга барган саен, әткәем күренмәсме дип, гел карап узам. Үтеп китмәсме дип, тәрәзәдән күз алмыйм...

ӘНКӘЙ – АВЫЛНЫҢ ТРАКТОРЫ ДА, КОМБАЙНЫ ДА ИДЕ. Метрлы ирләр чалгысы белән печән чапты. Бөтен эшкә өлгерә иде. 30 тиенгә, 50 тиенгә кешеләргә күлмәкләр тегеп кидерде. Теккән өчен акчасын беркайчан да сорап алмады. Безне дә ялт иттереп әнкәем киендереп үстерде. Ул мулла кызы булган. Исеме дә – Мосаллия, намаз укучы хатын-кыз мәгънәсендә. 8 яшендә бабам аны намазга бастырган. Һәм гомере буе, 95 яшькә кадәр ул шул юлында булды. Һәм 40 елга якын авылыбызда мәетләрне соңгы юлга озатты!

ИРЕМ НАЗЫЙМ, КЫЯФӘТЕМӘ КАРАП, МИНЕ ПРЕДСЕДАТЕЛЬ КЫЗЫ ДИП УЙЛАГАН. Якын килеп сүз катарга курыктым, ди. Ике ел күзәтеп йөргән. КИСИда укыганда, безнең Кызыл Позиция урамындагы тулай торак ашханәсенә килә торган булганнар. Мин беркемнекенә охшамаган киемнәрдән – чөнки үзем тегәм! Кибеттә тукыманы күрү белән, фасоны күз алдыма килә иде.

ҮЗЕМДӘГЕ БӨТЕН СЫЙФАТЛАРНЫ ӘНКӘЙДӘН ТУПЛАДЫМ, АННАН ҮРНӘК АЛДЫМ. Һәм аннан эшне кушканга гына эшләмәскә өйрәндем. «Менә шуны эшлә әле, дип кушмыйлар, үзең белеп эшләргә өйрән», – дип әйтә иде ул.

БАЛАЧАКНЫҢ ХӘТЕРЕ БИК УЯУ: КҮП НӘРСӘЛӘР ИСТӘ КАЛА! Апамнан калышмаска тырышып, зур чиләкләр асып су ташулар... Тау башына менеп җиткәндә генә, көянтә озын булу сәбәпле, чиләкләр җиргә бәрелеп, су түгелүләр... Әмма балачагымның иң озын хатирәсе – ул әткәемне көтү. Һәм кызыл пәлтә алып кайта дип көтү. Бер кызга әтисе кызыл плюш пәлтә алып кайткан иде. Минем дә шундый кызыл пәлтә киеп йөрисем килде! Хәерчелектән түгел, аны әти алып кайта дип өметләнү бу.

КАЗАН МӘКТӘБЕНДӘ ИНДЕ ЧЫНЛАП ТОРЫП ШИГЫРЬ ДӨНЬЯСЫНА ЧУМДЫМ. Мәктәптә яхшы укуым, олимпиадаларда катнашуым мине Казанга, 10 нчы интернат-мәктәпкә китерде. Әйдә, минем исемгә шигырь яз, ди классташлар. 30 баланың һәркайсына багышлап шигырь язам. Әдәбият укытучыбыз Маһруй Исхаковна университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керүемне теләде. Математиканы да су урынына эчәм! Маһруй апаның үз туксаны – туксан: мин, һичшиксез, шигырь язу нечкәлекләренә төшенергә тиеш икән! Камал театры артистлары бездә түгәрәк алып бара, «Зөбәйдә – адәм баласы»нда мин – Зөбәйдә! Актриса булып китү ихтималым да юк түгел. Буең бар, җырлыйсың, диләр. Һәм җырчы булып китәргә дә кыстыйлар...

КЕМГӘДЕР ОХШАГАНСЫҢ ИКӘН, БУ ТЫШКЫ КЫЯФӘТТӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕНДӘ ДӘ ЧАГЫЛА.
Миндә, мәсәлән, Нонна Мордюкова белән охшашлыклар бар. Чәчләр, тавыш, холык... Хәтта эшләп тупасланган кулларымны да аның кебек яшерергә тырышам. «Молодая гвардия»нең экраннарга чыккан чагы. Калын чәч толымнарым билдән түбән төшеп тора. Шунда миңа: «Нәкъ Ульяна Громованы уйнаган Нонна Мордюкова!» – диделәр.

«ТАТАР БҮЛЕГЕНӘ УКЫРГА КЕРМӘГӘН БУЛСАМ, МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЛЕКЦИЯЛӘРЕН ТЫҢЛАУДАН МӘХРҮМ КАЛЫР ИДЕМ...» Шулай язып куйганмын. Аның лекцияләрендә үзеңне башка дөньяда кебек хис итәсең! Сөйли-сөйли дә, офыкларны киңәйтеп, төрле җирләргә алып кереп китә, халык җырыннан берәр дүртьюллыкны китереп куя. Әсәрләрендә дә сюжет төрле якларга кереп китә бит... Флёра Сафиуллина лекцияләре үзе ни тора!

Фото: Анна Арахамия

МОСТАФА НОГМАН УКЫТКАНГА ГЫНА ФАРСЫ ТЕЛЕНӘ ЙӨРДЕМ. Ул университетка җәяүләп килә. Аудиториягә кергәндә күзләрендә очкыннар бии! Миңа карап: «Балам! «Киек казлар»!.. – ди. Мин бөтен аудиториягә аның «Киек казлар»ын җырларга тиеш булам. Берсендә: «Балам, бер шигырь язып килдем: «Бөдрә таллар». Шуны «Җиз кыңгырау моңнары» көенә җырла әле», – ди. Җырлыйм! «Җиз кыңгырау»ның бик популяр вакыты бу. Соңрак «Бөдрә таллар»га Рөстәм Яхин музыка язды.

КАЯ ГЫНА БАРСАК ТА, «ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!»ЛӘР КИЛДЕ ДИП КАРШЫЛЫЙЛАР! Радиода эшли башлавыма да 30 ел була. Анда яңа сулыш белән килеп кергән идем. Ә «Хәерле иртә!»м 22 ел буе иң популяр тапшыру булды.

ЭШНЕ ҖЫРЛАП ЭШЛӘРГӘ ЯРАТАМ. Токмач кискәндә дә, бәлеш пешергәндә дә, машинада юлга чыксам да, җырлыйм. Җырчылар ялындырып кына җырлый гадәттә. «Тавышым әле ачылмаган», «фонограммасы юк», «минем тавыш әле 11 дә генә уяна», диләр. Минеке гел уяу! Рульдә барганда улым: «Әни, әйдә, «Озын су өсте»н, әйдә, «Иске карурман»ны, «Олы юлның тузаны»н», – дип тезеп китә. Икәүләп юл буе рәхәтләнеп җырлыйбыз.

«КАРЫНДАГЫ БАЛАҢ БЕЛӘН ГЕЛ СӨЙЛӘШ. УЛ СИНЕ ИШЕТЕП ТОРА БИТ!» Йөкле вакытта әнкәем гел шулай әйтә иде. Хәзер докторлар да сөйләшергә, музыка тыңларга киңәш бирә. Улымны тапкач, әнкәй бәби күрергә килде дә: «Кызым, бер дә сөйләшкәнеңне ишетмим», – ди. «Ул бит әле аңламый», – дим. «Ул аны сеңдереп ята. Сөйләш, шигырьләр укы», – ди. Чыннан да, теле тизрәк ачыла икән! Улым тәпи йөргәнче сөйләшә башлады.

ИҢ ЗУР БӘХЕТЕМ – БАЛАЛАРЫМ АКЫЛЛЫ. Шигырьләр языгыз дип өйрәтмәдем – барысы да шигырь яза! Улым Илдар да, кызым Гөлназ да, оныкларым Илһам белән Камилә дә! Икесе дә Халыкара конкурс лауреатлары. Гөлназ менә дигән җырлар яза, бик матур җырлый да. Ул музыка көллиятендә укыта. Илдарның кызы Камилә – рәсем буенча халыкара, татар теле буенча республика конкурсларында җиңгән бала. Кечкенә Мәликәбез шуларны күреп үсә.

ҖИДЕ КҮКЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛӘНГӘНЕМНЕ ИНКАРЬ ИТӘ АЛМЫЙМ. Кайчак, боларны мин яздым микән, бу сүзләр акылыма каян килде икән, дип шаккатам. Ике-өч ай шигырь язмаска да мөмкин мин. Эшләп йөрим: җир казыйм, кирпеч ташыйм. Берзаман шигырь дулкыны китереп бәрә! Үзенең ритмы, моңы белән!.. Шуны кәгазьгә генә төшерәм.

МИН – ҮЗЕМӘ БЕРТӨРЛЕ! Берәүне дә уздырырга тырышмыйм. Кайберәүләр, син икенче Гөлшат Зәйнашева, диләр. Юк, мин икенче түгел, мин беренче Шәмсия Җиһангирова!

ҺӘР ҖЫРЫМ БАЛАМ КЕБЕК КАДЕРЛЕ. Ә ШИГЫРЬГӘ ЯЗЫЛГАН ҖЫР – БАЛАНЫҢ БАШЛЫ-КҮЗЛЕ БУЛУЫ УЛ. Студент чагымда «Азат хатын»да «Нишлим?» дигән шигырем чыкты. Китап нәшриятында эшли башлаган көннәрем. Фасил Әхмәтов шалтырата. «Нишлим?» шигыренә көй язган икән. Пианинода уйнап күрсәтте. Җырны иң беренче башкаручы Люция Хәсәнова булды. Аннан Зилә, Зөһрә, Хәйдәр, Айдар, Миңгол... «Ак күлмәгем», «Бураннар», «Күрәсем килгән иде», «Мөслимем»... Һәр җырым кадерле.

БӘРӘКӘТЕ БУЛСА, ӘЗ ДӘ ҖИТӘ, БӘРӘКӘТСЕЗ БУЛСА, КҮП ТӘ БЕТӘ. Әнкәй гел шулай ди торган иде. Иҗатны акчага сатуны күз алдына да китерә алмыйм. Кул сузып акча алган мәлдән Күкләр белән элемтәм бетәр шикелле.

КЕШЕГӘ РӘХӘТ КҮРСӘТҮ РӘХӘТ! Мин кеше кайгыртудан ләззәт табам. Ирем кайтышка тәмле ризыклар пешерергә ярата идем. Кулларын пешерә-пешерә, өчпочмакларымны тәмле итеп ашый иде... Бик акыллы, чибәр, затлы кеше иде ул. Аз яшәде, әмма рәхәт яшәп китте.

МИН АНЫ ЯШӘҮГӘ ӨМЕТЛӘНДЕРЕП ЯШӘТӘ АЛДЫМ. Бәлки, үзе сизенгәндер дә рак икәнен. Алдаша торган кеше булмасам да, «юк, начар чир түгел синдә», дип юата идем. Аңа бик килешә иде мин алган киемнәр... Баекта хәзер дә: ирегез белән урамнан төшеп барганыгызны сокланып карап кала идек, диләр. Мин җырлыйм, Назыйм баянда уйный. Без һәр табын түрендә бик кадерле кунаклар идек! Миңа бик матур шигырьләр яздыртты ул. «Нишлим?» дә аңа багышланган иде.

ЭШНЕ МИН ТЕЛӘГӘНЧӘ ЭШЛӘМӘСӘЛӘР ДӘ, КАЙЧАК БӨТЕНЛӘЙ ЭШЛӘМИ КАЛСАЛАР ДА, СҮЗ ӘЙТМИМ. Усал кайнана да, усал әби дә түгелмен. Үземне алар урынына куеп карыйм: миңа да авыр ишетелер иде!.. Эшне кушып эшләтергә яратмыйм.

ЯЗМЫШ ГАМӘЛ КИТАБЫНА ЯЗЫЛЫП КУЕЛАДЫР. ҺӘМ СИН ШУНЫ ҮТӘ АЛЫРГА ТИЕШ. Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә ышанам, шөкер итә беләм. Шушы язмышта яшәргә яратам, шушы язмышта яшәп бетерермен, дим.

ИР-АТНЫҢ ЗИРӘК АКЫЛЛЫСЫ ХАТЫНЫ ФИКЕРЕ БЕЛӘН КИЛЕШМӘСӘ ДӘ, АНЫ ҺӘРВАКЫТ ТЫҢЛЫЙ. Аныңча эшләмәсә дә, ярар, шулай эшләрбез дип әйтә ала.

КЫЕН ЧАКТА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ҺӘМ ШИГЫРЬГӘ ТАЯНАМ. Иремне югалткан көннәр иң авыр чак булгандыр. Ул гаҗәп икән. Хезмәттәшләре, туганнары баштарак килеп хәлен белде. Аннары юкка чыктылар: биш ел бит ул бик озак... «Мин таянып калдым шигырьгә» дигән шигырем дә бар... Елый-елый шигырь язам да бушанам.
Ни өчен әле мин, үземә җиңел булсын дип, башкаларга сөйләргә тиеш? Иремә 17 операция ясадылар, үлем эчендә ятты дип, нигә дусларымны хәсрәткә салырга тиеш?.. Барысын да Аллаһы Тәгалә белә, күрә...

НИНДИ ЭШКӘ АЛЫНСАМ ДА, СЕР БИРМӘЯЧӘКМЕН! Җиңәргә тырышачакмын, һәм җиңеп чыгачакмын! Эшкә алынгансың икән – эшлә. Эшли алмасаң да эшлә!

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.



МИН ШУЛАЙ УЙЛЫЙМ

ИРГӘ ХӨРМӘТ БУЛЫРГА ТИЕШ!



Марат КӘБИРОВ, язучы

И, акыра күрше фатирда бер хатын, тавышы стеналарны дер селкетә. Ирен сүгә. Фәлән-фәсмәтән, тегесе-монысы... Мин мәнә язучы кеше, татар телендәге бөтен сүзләрне дә беләм кебек, тик моның авызыннан чыккан кабахәт сүзләрне беренче тапкыр ишетәм. Талашмаган чакларында да шулай ул, ирен гел кимсетергә, кеше алдында абруен төшерергә генә тора.

Күзең төшкән кызның гаиләсенә кара. Әгәр анда әтисенә хөрмәт зур икән, димәк, кызлары да ир өчен өзелеп торачак; әгәр әтисен санламыйлар икән – якын да килмә: кызлары да шуны куачак.

Без яшь чакта шундыйрак сүзләр дә әйтештерәләр иде. Акыл өйрәткәнне кем яратсын инде. Без дә яратмадык. Һәм ул сүзләрне ишетмәдек тә. Әмма бик күп гаиләләр мисалында, әлеге сүзләрнең дөреслегенә ышанырга туры килде. «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», дигән әйтем дә юктан гына түгел бит инде. Хәзер үзем дә, акыллы кыяфәт чыгарып, шул сүзләрне кабатлыйм. Тик мине дә ишетмиләр. Ишеттерергә тырышсам – яратмый башлыйлар... Шуңа кайчак шаяруга күчәм...

Гомумән, ирләрне хөрмәтләп, кадерләп, саклап кына яшәтергә кирәк. Чөнки без ифрат аз калып барабыз. Рәсми статистика буенча, бүген бер иргә ике хатын туры килә. Бу инде уен түгел, бу – фаҗига. Бер хатынга ярты гына ир туры килә дигән сүз. Әле аның кайсы яртысы эләгә!..

Шуңа күрә, ирнең кадерен белеп кенә, аңа бер авыр сүз әйтми генә яшәргә кирәк. Көнләшмәскә. Сулга йөрештерә икән – йөрсен. Ирнең теләге – закон. Һәм аның сөяркәсен дә әллә нинди авыр сүзләр әйтеп тиргәргә ярамый. Ул да хатын-кыз. Аның да җаны бар. Һәм син дә аның урынында булырга мөмкин идең. Шул ир кисәгән әллә кемгә күреп, качып-посып очрашып, төн йокыларыңны онытып уйланып, гайбәтчеләр теленә кереп иза чиксәң нишләр идең? Вәт, шуларны уйласаң, әле синең хәлең ireңнең сөяркәсенә караганда мең кат әйбәтрәк. Яши бир шул әйбәтлекнең рәхәтен күреп. Шөкер итә белсәң, җәннәттә яшәрсең.

Ни генә әйтсәң дә – статистика! Һәм табигый ихтыяҗ. Ике хатын-кызга – бер ир-егет. Уен эш түгел. Кешенең хайванлыгын һәм статистиканы бернәрсә дә җиңә алмый.

Ахирәтләреңнең ире сулга йөрмимени? Ә син нәтиҗә чыгарырга артык ашыкма, ныклабрак сораштырып кара. Сулга йөрмәгән ир, гадәттә, уңга да йөрми ул...

Эчә икән – эчсен. Ир теләге – закон. Ә кем әйтте сиңа аны бернәрсә турында да уйламый, эчүдән башканы белми, дип. Ул бәлки югары идеялар белән, кешелек язмышы турында хәстәрлек күреп йөридер. «Киләчәк буыннар, улларым-оныкларым алкоголизмнан интекмәсен, алар бу явызның барлыгын да белмәсен. Шуңа күрә мин бүген дөньядагы бөтен аракыны тамчысын да калдырмыйча эчеп бетерәм!» – дип тибәдер, бәлки, аның йөрәге. Җил тегермәннәре белән көрәшкән Дон Кихот – герой, ә реаль явызлык белән көрәшүче ireң беткәнбашмы?! Ничек кенә булмасын, артыгын бәйләнмә аңа. Сүгеп йоклатсаң да, үбеп уят. Һәм өметеңне өзмә – исерек бер айный ул. Бары тик мәеткә – җан, ахмакка аң керми.

...Кайчагында менә шундый кәкре киңәшләр бирештерсәм дә, гаиләдә иргә чынлап та хөрмәт булырга тиеш дип уйлыйм. Гаиләдә иргә хөрмәт булырга тиеш! Хөрмәт юк икән – ир дә юк, дигән сүз.

Моны гаиләдә бары тик ирләргә генә хөрмәт булырга тиеш дип аңларга кирәкми. Хөрмәт хатынга да булырга тиеш. Гомумән, һәрбер гаилә әгъзасына булырга тиеш ул. Бәхет өчен шулай кирәк.

Ләкин хөрмәт – бүләк түгел. Товар да түгел. Аны бушка да бирмиләр, сатып та йөрмиләр. Хөрмәтне бары тик яулап алып кына була. Ә ничек яуларга кирәген берәү дә белми, белсә дә әйтми, әйтсә дә – аны башкалар куллана алмый. Хөрмәтне һәркем үзенчә яулый. Ир-ат та, хатын-кыз да. Адәм баласының һәр мизгеле хөрмәткә омтылудан тормый микән әле ул...

«КЕШЕЛӘРГӘ ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР...»

Бүген ул татар эстрадасында иң хайплы җырчы. Популяр сүзен хәзер әнә шулай диләр. Аны йә үлеп яраталар, йә куралмыйлар – битараф калучылар юк. Чибәрлеге, усаллыгы, төпле фикере, үткен сүзе, турылыгы белән үзенә карата ул. Татарстаның атказанмаган, әмма иң дан казанган җырчыларның берсе – Илсөя БӘДРЕТДИНОВА белән сөйләшәбез.



Илсөя, син 18 ел элек татар сәхнәсенә чәнечкеле җырларың белән килеп кердең. Рок җырчылардан бер дә ким түгел идең. Хәзер образың да башка, җырларың да, нигездә, мәхәббәт, тормыш лирикасына багышланган...

– Беренчедән, моңа шәхси тормышымдагы вакыйгалар сәбәпче. Андый текстларны Илфак Шиһапов кебек башка беркем дә яза алмый. Илфактан калган мирасның 99 проценты инде актуаль түгел, дөнья үзгәрә тора. Үзеннән-үзе башка юнәлешкә кереп китәргә туры килде. Яшермим, бик авыр булды. Икенчедән, олыгаям бит инде. Миңа 40 яшь. Һаман турыга ярып йөреп булмый.

Диана Арбенина бар бит?

– Ул бит Мәскәүдә! Рус эстрадасы... Безнең татарның стереотиплары белән болай йөргәнгә дә мең рәхмәт инде. Бездә чикләүләр көчле. Сүзне мең тапкыр уйлап әйтергә кирәк. Чит ил эстрадасы йолдызларының интервьюларын укыйм кайчак. Алар кебек сөйләп кара әле: бетте, син кеше түгел. Бездә барысы да ал да гөл. Бездә бөтен кеше дә тәртипле булып кылана. Миңа яраклашырга туры килә. Үземне сәхнәсез күз алдыма китерә алмыйм. Ялгызлыктан куркам, миңа кешеләр белән аралашырга кирәк. Бүгенге көндә читтә акча китерә торган шөгылем булса, бәлки, иҗатымны башка төрле алып барыр идем. Кроссовки, джинсы чалбар гына киеп рок җырлар башкарып, квартирниклар оештырыр идем...

18 элек булган Илсөя белән хәзерге Илсөя арасында аерма зурмы?

– Ул вакытта заманы да башка иде, мин дә яшь идем. Башкарган җырларның да бөтен мәгънәсен аңлап бетермәгәнмендер.

Бу, мөгаен, мәрхүм Илфак Шиһаповка ышану булгандыр?

– Илфак мине сәхнәгә чыгарган кеше. Ничек әйтсә, шулай булды. Иҗатта бигрәк тә. Ул җырлар мине сәхнәдә Илсөя Бәдретдинова иткән җырлар һәм мин моның өчен Илфакка чиксез рәхмәтлемен. Хәзер дөньядагы вазгыятьне күзәтәм дә: «Илфак исән булса, вәт язар иде» дип уйлап куям. Шәхсән үземә килгәндә 20 яшьлек белән 40 яшьлек хатынның аң дәрәҗәсе аерыла инде. Бар кешегә ышана торган, бөтен нәрсәдән матурлык эзли торган хатын идем. Хәзер күңел катыланды. Беркемгә дә ышанмыйм. Бигрәк тә коллегаларга.

Хәзерге заман ир-атын ничек сурәтләр идең?

– Минә бу авырткан урын инде. Минем күзаллавымда ир-атлар бөтенләй башка төрле.

Ир-атны хатын-кыз ясый, диләр

– Күптән үземә нәтиҗә ясадым инде: бездә барысына да хатын-кыз гаепле. Ир-ат килеп чыкса, хатын кыз гаепле, килеп чыкмаса да гаепле. Ир-ат эчә икән, эчә инде ул нишләтәсең, диләр, хатын-кыз эчсә, җир итәләр. Ир-ат читкә йөри икән, димәк, хатыны начар дип нәтиҗә ясыйлар. Бала тапсаң да хатын кыз гаепле – таба да таба, диләр, тапмаса – кысыр исемен күтәрә. Эшләсә иреннән өстен булырга җыена, эшләмәсә иренең сыртында утыра. Бөтен нәрсәдә хатын кыз гаепле. Бу – язылмаган канун.

Җаваплылыкны үз өстенә ала белгән чын ир-ат булсын өчен улыңны ничек тәрбиялисең?

– Аллага тапшырган. Ялгызым үстерәм. Ир-ат киңәше дә кирәктер, билгеле. Штанга күтәрү буенча Россия күләмендә узачак ярышларга әзерләнә менә. Тренерына башта ук: «Улыма карата таләпчән бул, юл күрсәт», – дидем. Нариман өчен тренеры бик абруйлы. Миңа да күп нәрсәләрне сөйли. «Алай ярамый, болай ярамый», – дип, һаман акыл өйрәтә торган әни түгел мин. Кайбер вакытта ачуланам да бүлмәмә кереп елыйм. Ачуланмыйча да булмый. Мин бит әни дә, әти дә...

Концерт бетеп пәрдә ябылгач Илсөя нишли?

– 15 минут аякларымны уып утырам. 18 ел биек үкчәдә йөргәнлектән, аяклар бик авырта. Концерттан соң икенче кат тамашачы алдына чыгасы бар бит әле. Аңа да концерттагы кебек көч кирәк. Тамашачылар фотога төшәргә, автограф алырга, рәхмәт әйтергә көтеп тора бит. Ничек чыкмый каласың? Ул шундый зур бәхет, әмма менә шуның икенче ягы бар. Араларында үзләрен бик ямьсез тотканнары очрый. Менә шул бераз кәефне төшерә.

Шуңа концертыңа сак егетләре алдыңмы?

– Күпләр аны Илсөя кылана дип уйлар. Әмма аларны алырга мәҗбүр иткән хәл булды. Бер шәһәрдә бурзай бер тамашачы, үзен бик итагатьсез тотып, күлмәк итәгемә басып, мине этеп җибәрде. Тамашачылар каршысына барып егылдым. Шунда торып басарга ярдәм итүче, ул кешедән яклаучы булмады, кызганыч. Менә шул вакыйгадан соң, сак егетләре алырга булдым.

Хыялың...

– Гомер буе болай концерт белән йөреп булмас. Артистларның сәхнә гомере кыска. Сәхнә яшьлекне ярата. Яшьләрне карыйсы килә. Киләчәктә авылдагы йортымда улымны, аның гаиләсен каршылап кунак итү турында хыялланам.

Ә хыялыңдагы теге кечкенә кыз?..

Хыялланмыйм. Ничек булса, шулай булыр. Аллаһы Тәгаләнең үз канцеляриясе анда. Кистереп берни әйтеп булмый...

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.









Фото һәм видео: Анна Арахамия

ӘБИ-БАБАЙЛЫ ЙОРТ



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

– Әйдәгез, әйдә, түрдән узыгыз, бәлеш пешеп чыкты, чәй кайнаган! Татар гаиләсе кунакларны әнә шулай каршы ала. Әле ишек тоткасыннан кулыңны алырга өлгермисең, инде чәйгә чакыралар. Кунакчыллык, киң күңеллелек билгесе ул. Өендә тынычлык тантана иткән тырышларның һәрвакыт табыны мул, һәрвакыт әзер була. Кукмара районы Зур Сәрдек авылында ШӘФИГУЛЛИН-ФӘТХУЛЛИННар гаиләсе безне менә шулай елмаеп-көлеп каршы алды. Бер өйдә нигә ике фамилия яшиме? Хәзер белерсез.

Килеп керүгә, туп-туры мул итеп әзерләнгән табынга утырдык. Юлдан килгәнсез, сусагансыздыр, дип, Гөлүсә безгә чәй хәстәрли башлады.

– Каһвәгез юкмы? – дибез фотограф Аня белән. Юлга чыгарга дип иртүк торгач, йокы ачылып бетмәгән, машинада бәлүләп баргач, кабат күзгә йокы төште, каһәр.

Бар, әлбәттә. Ренат, матурым, әйдә, сыйла әле кызларны, – ди Гөлүсә.

Ренат җәһәт каһвә ясарга керешә. Минем өчен бик ят булган бу күренешкә аптыравым күзләремә чыккан, күрәсең.

– Бездә каһвәне гел Ренат ясый. Аның нык тәмле була инде. Каһвәсен дә, шикәрен дә артык та, ким дә салмый. Мин алай ясый да белмим, – ди Гөлүсә елмаеп.

Чынаякларны безгә суза-суза, Ренат сүзгә кушыла:

– Безнең бит көн кофе-таймнан башлана. Ул инде традиция. Иртән торып маллар карап керәбез дә, икәү, сөйләшә-сөйләшә, каһвә эчәбез. Көнгә планнар төзибез, башкарырга тиешле эшләрне барлап чыгабыз, малайларның хәлләре ничек икән дип бер сөйләшеп алабыз, шунда яшьлек хатирәләре дә искә төшә. Башланасы көнгә шулай көч алабыз. Шулаймы, матурым?..

Без көлешеп алабыз. Чәйләр ясап куелгач, Гөлүсә белән Ренат Фәтхуллиннарның төпчек малайлары Азат читтә генә утырган җиреннән юкка чыга. Әбисе белән бабасын чәйгә чакырган икән. Рафил абый белән Гөлфәрүз апа, үз бәяләрен белеп, әкрен генә атлап, җайлап кына өстәл артына килеп утыра. Азатның урыны – алар уртасында. Әби белән бабай малае икән! Өстәл башында – бу нигезнең хуҗасы, гаилә башлыгы Рафил абый. Өйдә кем баш дип сорагач, бөтенесе бер сүздән иң өлкән кеше, диделәр. Сизелеп тора, өлкән кешегә хөрмәт бик зур бу өйдә.

Өлкәннәр

Рафил абый белән Гөлфәрүз апаның бергә яшәүләренә инде 54 ел булган. Күрше авылдан килгән яшь математика укытучысына кечке мәктәпкә укырга йөргән Рафил күз сала да башкаларга бирми. Бу нигезгә килен итеп алып кайта. 45 ел буе кайнана белән яши Гөлфәрүз апа. «Әнине бөтен кеше усал, ди иде. Булгандыр, гомер буе тол яшәгән, балаларын ялгызы аякка бастырган хатынга усал булмыйча ярамый, әмма мин аның ул сыйфатын сизмәдем. Бөтен өй эшләрен ул карады. Минем гомер мәктәптә үтте. Икешәр смена укыта идек. Әни булгач, балаларым өчен күңелем тыныч булды. Мин бит дүрт кыз табып, шуларның берсен дә юындырган кеше түгел. Гел әни мунча кертте. Ничекләр чыдагандыр?! Биләмгә йөрмәде, гайбәт сөйләмәде. «Үзегез табасыз, кирәк икән миннән киңәш сорагыз, киңәш бирәм, әмма бер эшегезгә дә кысылмыйм», – диде. Һәм шулай итте дә. Мәктәптә дә киленнәргә әйтә идем: «Кайнанагызны хөрмәт итегез. Өегездә булган чүпне тышка чыгармагыз. «Ул шундый, ул мондый», дип сөйләп йөрсәгез, бу сүзләр, күпереп, үзенә барып

Ныклы гаиләнең сере бер-береңә карата хөрмәт булуда.



Бу гаиләдә һәр нәселнең тамырын беләләр. Рафил абый унбер буынга кадәр өйрәнеп, нәсел шәҗәрәсен төзеткән. «Намаздан соң һәрберсенә дога кылам», – ди ул.

житәчәк. Ничек кенә булса да, әйбәт дип әйтегез», – дидем. Ныклы гаиләнең сере шул инде аның: хөрмәт булсын. Хәзер менә без әни урынында калдык. Киңәш бирәбез, кулдан килгәнчә ярдәм итәбез».

Тыныч кына утырган Рафил абый да сүзгә кушыла:

– Сеңлем, элек өлкәннәр балаларны бик дөрес тәрбияләгәннәр ул. Минем әттә (әти сүзен шулай әйткәннәр бу якларда) иртә вафат булды, нәнә гел эштә иде. Безне әби тәрбияләде. Ашарга әзер булса да, нәнә кайтканчы өстәлгә утыртмады. Безнең гаилә гел бергә утырып ашады. Табын – гаиләне ныгыта. Табын артында сөйләшәсең, бүлешәсең... Хәзер дә шулай – өйдәгеләр җыелышып бетмичә, өстәлгә утырмыйбыз. Бездә кичен иң соңгысы булып Азат кайта. Азатны көтеп утырабыз. Шулай гадәтләнгән инде.

– 54 ел бергә яшәгәнсез. Аерылам диган вакытларыгыз булмадымы? – дип сорыйм өлкәннәрдән. Югыйсә җавабын да белеп торам. Рафил абый бик тыныч, сүзен нык итеп әйтә белә торган ир-ат. Гөлфәрүз апаның да ирен хөрмәтләп торганы күренә. Табынга ни китерсәләр дә, иң элек Рафил абыйга куя, аннан соң гына үзенә ала. Бу хөрмәт тә, кайгыртучанлык та түгелме соң?

Рафил абыйның сүзе ирләрчә, кыска булды. Хатынына карап: «Моннан башка тормышымны күз алдына китерә алмадым!» – диде.

– Бөтен барлыгым, бөтен гомерем шушы. Бер сүз әйтмәде, ормады-сукмады. Шофер булып эшләде. Эшендә дә гел алдынгы булды. Фотосы районның Почет тактасында эленеп торды. Иң әйбәт шофер булды. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирделәр, – дип, тиз генә ирен мактап ташлады Гөлфәрүз апа.

«Моны», «бу», «шушы»... Гомер яшәгәннәр генә берберсенә әнә шулай дип эндәшә. Бу күренеш татар



Әбиле өйдә дога булмый калмый. Балалар да иманлы булып үсә.

гаиләләрендә генә очрый. Әлеге сүзләр өлкәннәр авызыннан ниндидер бер җылылык, ярату белән әйтелә. «Кадерлем, җаным, матурым» димиләр, аларның үз җылы сүзләре. Сыналып сынмаганнар, кыенлыкларны, суны бергә кичкәннәр генә шулай сөйләшә ала.

Яшьләр

Ап-ак яулыгын татарча бәйләп куйган Гөлфәрүз апа белән кара бәрхет түбәтәйле Рафил абый Аняны да рухландырды. «Шундый матур утыралар, фотога төшерим әле», – дип, эшен башлады. Шуны гына көткәннәрмени: әби белән бабай башларын бер-берсенә куйды, бер-берсенә карап елмаеша башладылар. Без залга күчеп, яшьләр белән сөйләшеп утырдык.

– Ренат, син – шәһәр егете. Ничек авылга кайтырга булдың әле? Җитмәсә, «теща» янына, – дим, уенынчынын бергә кушып.

– Теща белән кияү турындагы хәлләр байка гына, анекдот. Тормышта алай буладыр дип уйламыйм. Әйе, авылга кайткач, «йортка кергән», «килмешәк» дигән сүзләрне күп ишеттем, әмма үпкәләмәдем. Беренчедән, шәһәр егете булсам да, авылны яраттым. Кечкенә вакытта: «Авылга күчеп кайтып китик», – дип, әти белән әнине гел аптырата идем. Хәзер мин – монда, сеңлем Балтач районында яши. Шәһәр кызы булса да, ул да авылга кайтты, маллар асрап, сыерлар сава. Икенчедән, Гөлүсәне яраттым. Ул хисләр әле дә сүнмәде, шөкер. Рәхәтләнеп яшибез.

– Ренатның апасы безнең авылга кияүгә чыккан иде. Ул шуларга кунакка кайткач таныштык. Безгә 18 яшь иде. Аны армиягә озаттым. Ренат кайткач өйләнештек. Ул вакытта медучилище тәмамлап Казанда эшли идем. Чаллы педагогика институтында читтән торып белем алам. Фатир арендалап яши башладык. Әти авырып киткәч, ярдәм итәргә авылга кайтырга кирәк иде. Без бит дүрт кыз, төп йортта калырга малай юк. Бергә утырып сөйләштек тә, Ренат белән күчеп кайтырга булдык. Ул вакытта әби дә исән иде әле. Ренат аны күтәреп кенә йөртте. Бездә һәркемнең үз эше. Шәһәрдән кайткан вакытта малны әти белән әни карый иде. Кушканны гына эшләдек. Хәзер ишегалдындагы эшләр безнең өстә. Буыннар алмашуы шулдыр инде ул. Безнең әби белән әнинең тату яшәү сере дә шундадыр, мөгаен. Әни гел тыштагы эшләрне эшләде, әби өйдә булды. Алар өстәл янында гына очрашалар иде. Безне әби тәрбияләде, эшкә өйрәтте. Шәл бәйләдек, тегү тектек. Безнең малайлар да эшләп үсте. Шуңа да малларны да бетермәдек, нәрсә икәнен белсеннәр, дидек.

– Балаларны эш белән тәрбияләү кирәк, – дип сүзгә кушылды безнең янга чыгып утырган Гөлфәрүз апа, бабасы белән әбисе уртасына сыенган Азатны сыйпый-сыйпый. Эш балаларны бозмый. Тәртипсезләнергә башка вакыты калмый аларның. Олы оныгыбыз Булат та гел бабасы тирәсендә булды. Әле менә армиягә киткәнче бабасы белән икәүләп алмагачлар утырттылар.

– Бабай димәгән бер минутлары да юк, шөкер, – ди Рафил абый. – Менә монысы да мәктәптән: «Бабай, мин кайттым!» дип килеп керә. Иртән дә «Бабай, мин киттем», – дип саубуллашып чыгып китә. Шушы инде хөрмәт. Аннан да бүтән хөрмәтне күз алдыма китерә алмыйм.

Балалар

Ренат белән Гөлүсәнең өч уллары бар. Олысы Булат армиядә. Бик горурланалар. Әле генә ефрейтор булган. Уртанчысы Самат Казанда политехник көллияттә укый. Спортчы. Азат дүртенче сыйныфта. Җырчы ул. Төрле бәйгеләрдә катнашып, лауреат исемнәре алган. Рөстәм Насыйбуллин кебек булам, ди. Төпчек икәнен белә: әле әбисе кочагында, әле әтисе алдына менеп утыра. «Әби белән бабай мине өйдә көтеп торалар. Аларны бик яратам. Әби әле миңа математикадан өй эшләрен эшләргә булыша. Аңлата», – ди ул.

– Әбиең дога өйрәтәме соң? – дип сорыйм. Беләм, әбиле өйдә дога булмый калмый. Йоклар алдыннан миңа да әбекәй догалар өйрәтә иде. Ә алар гомер буе онытылмый.

– Өйрәтә. Әле мәчеттәге лагерьда дога укып, бәйгедә дә җиңдем, – ди Азат.

– Бабасы белән мәчеткә дә йөри әле ул, әйеме, улым, – дип сүзгә кушыла әбисе. – Аллага шөкер, балаларыбыз иманлы. Ел саен корбан чалдырабыз. Бөтенесе җыелышып ашка кайта. Кияүләр бабай белән мәчеткә баралар. Күңелле бит. Бабай белән икебез дә намазда. Әле ул мәчеттә азан да әйтә. Тавышын бик яраталар. Балалар дога укып юлга чыгуның нәрсә икәнен белә. Менә минем улым да җыр буенча конкурсларга барганда юл буе дога укып барам, ди. Иман кирәк ул тормышта. Булат та армиядә гает көнне: «Безнең бүген изге бәйрәм. Мәчеткә барып хәер бирим әле», – дип, командирыннан сорап, Екатеринбург буйлап мәчет эзләп, хәер салып кайткан. Әй шатландым инде. Ата-ананың, телнең, диннең кадере ерakta тагын да арта шул.

Бу өйдә ярату, хөрмәт яши. Яратуны күрсәтә белү дә талант. Кышын гына бөтенесенә берәү ул Азат. Җәй җитсә, күбәяләр. Гөлфәрүз апа белән Рафил абыйның башка кызларының балалары, Ренатның сеңелләре кунакка кайта. Күп җыела алар. «Бер елны бәйрәмгә 36 кеше җыелдык. Безнең ишекләр һәрвакыт ачык. Туган-тумача бик күп», – дип сөенә Гөлфәрүз апа. Азәрбайҗаннан кадәр кайтсалар да, безнең өйдә татарча сөйләшәләр. Кайткан оныклар да русча сөйләшә башласа: «Без аңламыйбыз», – дибез. «Бала гаиләдә татарча сөйләшеп үссә, ул татар телен гомерендә дә онытмый», – ди өлкәннәр.

– Татар гаиләсендә балалар әтигә «әти» дип, әнигә «әни» дип эндәшергә тиешләр, – ди Ренат. – Без шулай үстек. Иптәшләр руслар иде, аларга карап бервакытта



« Бу гаилә турындагы видеоны QR-код аша кереп карый аласыз.

да: «Мама, папа», – димәдем. Балалар үз динен, үз милләтен хөрмәт итеп үссен. Үзләренең татар булуы белән горурлансын. Без бит бик эшчән, булдыклы халык.

– Малай тәрбияләү бик җаваплы да. Булачак гаилә башлыгы бит ул. Нык тормыш алып бара, акча таба, аны тота, хатыннарына йомшак була белсеннәр. Хатынны – хатын урынына, әти-әнине әти-әни урынына куярга өйрәнсеннәр иде. Моны бары тик үзебезнең үрнәк аша гына бирә алабыз, – ди Гөлүсә ирен куәтләп.

Гөлүсә Зур Сәрдек балалар бакчасында мөдир булып эшли. Ренат: «Мин төнге директор», – дип көлә. «Ренатсыз эшем бармас иде, бөтен ир-ат эшен ул башкара», – ди Гөлүсә, ире янында эшләгәнгә куанып. Аңа бар яклап ярдәм итәргә генә тора. Ренат күптәнге хыялын чынга ашырырга уйлагач та, теләктәшлек белдерә. Менә биш ел инде кыяр үстерә алар. Бакчаларында мич ягып җылытыла торган зур теплицалары бар.

– Кыяр үстерү – минем хобби. Акча өчен түгел бу кәсеп, күңел хакы өчен, – ди Ренат. Аның күзләре очкынланып китә. – Әйдәгез, байлыгымны күрсәтәм, – дип, ябулы бүлмәнең ишеген ача. Ә анда өстәл тулы яңа шыткан кыяр үсентеләре.

– Менә бу минем дөнья инде, – ди аларга су сибәсибә йөргән Ренат. – Тиздән теплицага чыгарып утыртачакбыз. Воронеждан махсус заказ белән шөпшәләр кайтартам. Ә бу сортларны үзебез ясадык. Алар... – Ренат сортлар, тәрбияләү турында тулы бер лекция укыды безгә. Күренеп тора, яратып үстерә, бөтен күңелен биреп. Хатыны аңа карап елмаеп басып тора. Горурланып! Аның ире бит!

– Башта балаларыгызны үстереп очырткансыз, хәзер оныкларыгызны. Моңсу түгелме? – дип сорыйм китәргә җыенганда мөлаем Гөлфәрүз ападан.

– И балам, очыртып җибәрү җиңел түгел инде. Олыгаябыз бит. Кайтканнарын күрербез микән дип тә уйлыйбыз. Тормыш шулай инде ул. Башкача була да алмый. Баланы оядан очыртып җибәрү өчен тәрбиялибез. Бәхетләре генә булсын.

Безне озатырга бөтенесе бергә чыктылар. Янып торган кызгылт сары ихаталары янында алар аеруча бәхетле күренде. «Кызлар, безгә җәй көне кайтыгыз әле. Язарга түгел, ял итәргә. Бездә җәен бигрәк күңелле», – диләр...

Җәй... Йорт яныннан әкрен генә елга ага. Таллыкта сандугачлар чутылдап куя... Кызгылт сары ихаталы йортта әби белән бабай әкрен генә ахшам намазына җыена, Гөлүсә белән Ренат бер-берсенә серле караш ташлап, теплицаларында кайнаша, Булат белән Самат тырыша-тырыша әтиләре кушкан эшне башкара, елга аша салынган күпердән велосипедына атланган Азат уеннан кайтып керә. Бу нурлы өйдә тагын бер көн тәмамланып килә. Алар мал артыннан да кумый, кемгәдер нәрсәдер расларга да тырышып яшәми, гайбәт тә сөйләми. Аларга үз тормышлары кадерле, аларның үз юллары, үз дәвамчылары бар. Һәр татар гаиләсе әнә шулай яшәсә, бу дөньяда бәхетлеләр, итагатьлеләр тагын да артыр иде.











Фото һәм видео: Анна Арахамия

ИҢ ТУГРЫ ДУСТЫМ – ЯЛГЫЗЛЫК





Гөлнур
САФИУЛЛИНА

Аның күңеле – мөлдерәмә! Сәхнәдә үзе иҗат иткән йөздән артык роль сыйган аңа. Кайсы җитди, кайсы моңсу, кайсы шаян... Артист һәрберсе белән өр-яңадан яши. Бер гомер яши! Аның максаты гел югары – тамашачы театрдан үзгәреп китәргә тиеш! Шигырь яраткан кеше дә башкалардан барыбер аерылып торадыр ул. Гамьлерәк, уйлырак, яктырак буладыр. Шигырь – дога кебек бит: җанны, күңелне чистарта. Ә аның күңелендә, юк, һәр күзәнәгендә – шигырь! (Чордаш шагыйрьләрен беренче юлдан танучы тагын кем бар икән бездә?!) Сез бу язманы аның үзегез белгән, үзегез караган рольләрен күз алдына китереп укырсыз, ә колакта тавышы яңгырап торыр...

Әңгәмәдәшем – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Илдус ӘХМӘТҖАНОВ. 1950 елның 19 июнендә Баулы районы Татар Кандызы авылында туган ул. М. Җәлил исемендәге премия иясе, Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты.



ТАМЫРЛАР Әби-бабайларны күргән кеше түгелмен, мин туганда алар күптән мәрхүм булган. Әтине дә хәтерләмим диярлек. Ул авырып үлеп киткәндә, 6–7 яшьләр тирәсендә идем. Әнинең таң белән кереп: «Атагыз үлде», – дип әйткәнен беләм, елаганымны... Кайчак әтине искә төшерергә тырышам: ул бер мизгелгә генә күз алдыма килә дә, аннан югала. Карарга фотосурәте дә юк. Ап-ак сакал-мыеклы, ак чәчле дип хәтерлим. Бөек Ватан сугышы башланганда әтинең яше инде илледән узган була – аны фронтка алмыйлар. Мин белгәндә көтү көтә иде ул. Кырдан кисеп курай ясап кайта да, кич белән капка төбенә утырып, караңгы төшкәнче курай уйный. Тавышы бик матур иде, диләр. Әни: «Мәҗлесләрдә без парлап җырлаганны бөтен кеше яратып тыңлый иде», – дип сөйли иде. Тәравих намазларына халык безгә җыела иде. Шунда әтинең Коръән укуын тыңлап: «И-и, тавышы Хәниф абыйның!» – дип, тирә-күрше апаларның елавын үзем дә хәтерлим. Оренбург Каргалысында мәдрәсәдә укыган. Безнең бабайлар авылда әллә ничә буын мулла булып торган. Пенза ягыннан күчеп килгән алар. Муллаларны авылдан сөрү башлангач, әтине чакыртып: «Әхмәтҗан бабай муллалыктын туктыймы-юкмы?» – дигәннәр. Әти өйгә кайтып, «югыйсә барыбызны да озаталар», дип, шактый каты гына сөйләшкән бугай... Бабай китапларын каядыр күмгән, дип әйтәләр иде. 1905 елда төзелеп, бөтен кирәк-яракны саклый торган келәт бар иде безнең. Мин Ленинградта укыганда бозауны шунда яба башлаганнар. Каникулга кайткач, төп йортта торучы абый белән шул келәттә бозау өчен яңа урын ясадык. Багана утыртырга җирне казый башлагач... сандык килеп чыкты. Зур сандык! Такталары инде черегән. Җайлап кына ачтык – сандык тулы китап. Тик тотынуга бөтенесе көлгә әйләнде...

Әтинең беренче хатыны төрек кызы булган. Рус-төрек сугышыннан алып кайта ул аны. Авылда шуңа безне төрек, дип үртиләр иде. Рус гаскәреннән булгач, кяфергә бирмибез, дип, кызның әти-әниләре башта каршы төшә. Әти Коръән укып күрсәткәч, ризалашалар. Аларның өч балалары туа. Нәзмия исемле кызларын балачакта ук югалталар, абый да күптән вафат булды инде, апа әле быел гына... Аларны төрек ягына охшаган иде дия алмыйм, бу якка тартканнар. Рәшит абыйның «Карачкы» дигән поэмасының нигезендә шушы тарих ята... Беренче хатыны авырып үлгәч, әти әнигә өйләнә. Оренбург өлкәсеннән, бездән җиде чакрымдагы Кряжле дигән авылдан алып кайта ул аны. Без дә – мишәрләр, алар да, ләкин икебез ике төрле. Без каты итеп сөйләшәбез, алар – йомшак.

Әни мин театрда эшли башлагач вафат булды. Җәйге ял вакыты иде. Бер айга авылга кайттым. Әни, бүлеп-бүлеп, тәүлеккә 1 стакан сөт кенә эчә иде инде. Яман шеш... Әтидә дә шул иде. Икесе дә 68 яшьтә киттеләр... Атна-ун көннән соң бернәрсә дә йота алмый башлады. Газапланып ята, ә миңа китәргә кирәк – ял бетте, гастрольгә чыгабыз. Бәхилләштек... «Улым, мин синнән риза», – диде, васыятен, киңәшләрен әйтте. Безнең авыл бик зур, Югары очка кадәр бик озак мендем. Юл буе елап бардым – яшь акты да акты. Мин болай каты күңелле кеше, бик сирәк елыйм... Чаллыга барып җиткәндә, гастрольнең ун көне узган иде инде. Ниһаять, авылга шалтырату мөмкинлеге чыкты. Ничек җирләделәр икән дип сорашасы килә бит. Телефонга сеңел килде. «Әни менә бүген өзелде», – диде ул... Директор машинасын бирде: җеназасына кайтып өлгердем.

Әни укый-яза белми, әмма табигатьтән килгән акыл бар иде аңарда. Һәм бик матур тел! Хатлар яздырганда үзе чыгарган шигырьләрне дә куша. Рәшит абый әнинең чагылышы иде. Бер үкенечем калды: Ленинградта укыганда әнине алып килеп, Эрмитажда йөртергә хыялланган идем. Акча да эшләгән идем. Туры килмәде... Андагы матурлыкны күрсә, әни нишләр иде икән?!



БАЛАЧАК Безнең Кандыз зур авыл иде. Югары оч – татар урамы, Түбән оч – башкортларныкы, «Көл төбәге» дигән урамда – типтәрләр, бездә – Сөләйман очында – мишәрләр яши. Тел аерыла иде, әлбәттә. Башлангыч классны үзебезнең очта, манарасы киселгән мәчеттә укыдык. Аннан Кандыз мәктәбенә бардык. «Мишәр», – дип көләләр иде бездән. И-и ачу килә... Татар теле укытучыбыз Мөсәббиха апа: «Ярар, мишәрләрдән татар ясарбыз», – диде. Телебез, чыннан да, чистарды. Ләкин ниндидер интонацияләр калган, күрәсең. Театр институтында укыганда әле сизәләр иде. Телем бозыла дип, авылга каникулга кайтмый калган чакларым да булды. Ә театрда «мишәр» дип шелтәләмәделәр, хәтта мишәр икәнемә ышанмадылар.

Без гаиләдә 11 бала идек. Олылар белән яшь аермасы шактый зур. Мин үскәндә, абыйларның күбесе читтә иде, кайтып кына йөриләр. Әни, мин, сеңлем – байтак еллар өчәү генә тордык. Җәй көне көтүгә ялланам. Көтү – үзе бер яңа тормыш! Балачактан ук ялгызлык ярата идем. Хәтта шул көтүдә дә. Ике кеше көтәсең бит инде, тик аның янына бармыйм: ул – бер башта, мин – икенче башта. Ниндидер хыялый малай идем! Хыялның очы-кырые юк иде миндә. Шундый рәхәт, татлы хыяллар! Янымда кемдер булса, хыяллану рәхәтеннән мәхрүм калган кебек була идем.



УКУ Мәктәптә укыганда бер иптәшем белән очучы булырга хыялланып йөрдек. Гагарин Галәмгә очкач, космонавт буласы килде. Аннан – шагыйрь! Рәшит абыйның (*шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан – Г. С.*) әле авылда чагы. Өстәл янына утыра да, бөтен дөньясын онытып, кычкырып кабатлый-кабатлый шигырь яза. Яңгырашын тыңлый, күрәсең. Ә мин артыннан ятлап барам... Китапка кергән ул шигырьләрен абый инде үзгәрткән, төзәткән, яңадан язган, ә минем хәтеремдә – балачакта язган вариантлары. Шигърият орлыклары шул вакыт күңелгә кереп

Фото: Maксkar

калды. Бермәл мин дә шигырь язу белән җенләндем. Мәктәптә дә яздым, институтта да. Әшли башлагач кына туктадым, чөнки беркайчан да ике-өч эшне берьюлы башкара алмыйм. Аннан аңладым – Рәшит абый кебек шагыйрь чыкмаячак миннән. Әмма шигырьнең тәмен, матурлыгын аңлап өлгергән идем инде. Нәфис сүз белән гомерем буе шөгыльләндем. Тукай премиясен дә миңа нәфис сүз өчен бирделәр. Башта – Айрат абый Арсланов, аның артыннан мин алдым. Сәнгатьнең бу ике төре игезәкләр кебек, шуңа гына икесен берьюлы алып бара алганмындыр.

Театрга килү исә болай булды. Югары сыйныфларда укыганда укытучы булырга хыяллана башладым. Казан дәүләт университетында укырга телим. Рәшит абый кебек! Казанга килеп төштем. Рәшит абый: «Энекәш, Ленинградтан укытучылар театр институтына студентлар җыя. Әйдә, шунда», – ди. Аның телендә гел театр иде. Укытучы буласым килә дигәнемне ишетми дә. «Әллә алалар, әллә юк – сине генә көтеп тормыйлар әле анда. Барып чыкмаса, университетка керерсең», – ди. Гәүһәр Камалова университетта драмтүгәрәк алып бара икән – абый башта мине аның янына алып китте. Гәүһәр апа чәйләр куйды, үземне имтиханда ничек тотарга өйрәтте, киңәшләр бирде. Сәхнәдән спектакль караган кеше дә түгел бит әле мин. Гомеремдә дә! Чын профессиональ театрны беренче тапкыр Ленинградта күрдем... Безнең авыл Казаннан читтә. Җырчылар килгәли, әмма театрны хәтерләмим. Укытучылар, авыл яшьләре куйган спектакльләрне карый идек, билгеле. Шәп дип, аннары айлар буе тәэсирләнеп йөри идек. Алай ук шәп тә булмагандыр инде ул бүгенге күзлектән. Бераздан үзем дә катнаша башладым: авылның иң оста артистларының берсе булып саналып йөрдем. Биология укытучысы Рәхилә апа: «Сиңа артист булырга кирәк», – дигән иде. Тик бу уй үземнең генә башыма кермәде...

Ярый, килдем имтиханга. Ә анда беренче тур тәмам, инде изложение язалар. Театрның ул чактагы директоры Рәшидә Җиһаншина мине Ленинград укытучылары янына алып керде. Җырлаттылар, сөйләттеләр, этюд эшләттеләр. Аның этюд икәнен дә белмим әле... Һәм миңа имтиханга керергә рөхсәт бирделәр. Башкалар, әйткәнемчә, изложение яза – текст күптән укылган. «Ә син сочинение яз», – диделәр. Тукай турында яздым. Комиссиядә Хәй Вахит та булган икән. Ул: «Бу егеткә университетка керергә кирәк», – дигән. Ә мин шулай җиңел генә Ленинград театр институты студенты булып куйдым.

Рәшидә апа чакырып, гаилә хәлләрен сорашты. Өстә әллә ни кием юк инде. Авылдан күлмәкчән чыгып киттем. Олы абый флотта хезмәт итә иде – аның киң балаклы флот чалбарын кидем. «Кышка киемнәрең бармы соң?» – ди. «Бар, фуфайка», – дим. «Аның белән булмас, хәзер сиңа 85 сум акча бирәбез, киен», – ди. Бик зур акча иде бу! Аннан соң да, ел ахыры җиткән саен, имтиханнар вакытында министрлык аша акча, китаплар җибәрттереп торды. Мәңге онытасым юк ул яхшылыкларын...

Рәшидә апа остазларга безне үзе илтеп тапшырды. Студент тормышы башланды... Биш ел уку дәверендә алган тәэсирләрне сөйләп чыга алмам. Андагы укытучыларның никадәр затлы, зыялы, интеллигент икәнлеген дә. Менә ни өчен укытырга чакыргач баш тарттым. Андый укытучыларны күргәннән соң укытырга барсам, җинаятьче булыр идем. Юк, бара алмадым!



УҢЫШ Камал театрына дүртебезне эшкә алдылар: Шамил Бариев, Шамил Галиуллин, Габделфәрт Шәрәфиев һәм мине. Шундый җылы каршыладылар! Беренче эш итеп Рабит Батулланың «Өчәү юлга чыктык» дигән спектаклен куйдык: төп рольләрне безгә бирделәр. Шәүкәт Биктимеров, Гөлсем Исәнгуловалар белән уйнадык. Беренче эш! Дулкынланасың. Курку да бар, каушау да... Үз-үзеңә ышану да бетеп китә, нигә башка өлкәне сайламадым икән, дисең. Диплом алып кына артист булып булмый. Моның өчен еллар кирәк әле. Ниһаять, спектакль чыкты. Тамашачы өчен ниндидер яңалык булды ул. Театр халкы да әйбәт кабул итте: безнең күңелне күтәрделәр, үзебездә ышаныч уяттылар. Театр гаиләсенә кереп киттек шулай.

Йолдыз булып кайчан уяндыммы? Мин андый чирдән азат кеше. Бөек, даһи, легендар дигән сүзләр ачуымны гына чыгара. Танылу кинәт кенә булмагандыр. Халык теленә керә башлавым театр белән бәйле түгел. Тукайның 90 еллыгына Әхтәм Зарипов телевизион спектакль куйды. Шунда миңа Тукай ролен бирделәр. Шигырь бәйрәменә бер көн кала алдан күрсәттеләр аны. Бөтен кешедән, дөньядан качып берүзем карадым. Юкка борчылганмын, ошады, хур булмаганмын икән, дим. Икенче көнне Шигырь бәйрәменә чыгып киттем. Юлда кемнәрдер миңа төртеп күрсәтеп нидер әйттеләр, аңламадым. Килеп җиттем. Бөтенесе дә минем белән Тукай дип исәнләшә... Ә Мөхәммәт Мәһдиев: «Егетләр, менә бу кеше безгә Ходай тарафыннан Тукайны уйнар өчен җибәрелгән», – диде. Түбәм күккә тиде! Шагыйрьнең 100 еллыгына театр Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» спектаклен куйды. Төп рольне мин уйнадым. Шуннан соң инде миңа бөтен җирдә «Тукай» дип дәшә башладылар. Хәтта тискәрерәк роль уйнасам: «Тукайга бу килешәмени?» – дияләр иде... Онытылмас булып истә калган рольләрнең берсе – Максим («Һаваларда йолдыз»). Празат Исәнбәт аны Максим Горькийның хикәяләре буенча куйды. Җаваплы булганга хәтергә уелгандыр. Тормышта үзем дә шундыйрак булгач, берара гел җитди рольләр бирә башладылар. Ләкин күңел түрендә шаянлык качып ята, һәм аның чыгасы килә. Ниһаять, «Яшь йөрәкләр»дә (Фәтхи Бурнаш) бай малаен уйнадым. Бөтенләй яңача ачтым мин аны: зал көлүдән ярыла иде. Аннан «Банкрот»та (Г. Камал) Закир ролен бирделәр. Хәтта артистлар сәхнә кырыена чыга иде мин уйнаганны карап торырга. Равил абый, халык көлеп бетерсен, дип, залга арты белән борылып басып тора иде... Бу еллар эчендә уйналган рольләр бик күп, барысын да искә төшереп бетерә алмабыз.



МӘХӘББӘТ Кайбер артистлар интервью биргәндә, энәсеннән җебенә кадәр сөйли: кемгә гашыйк булган, кемгә өйләнгән... Аерылышкан, аннан кем белән кавышкан... Халыкка шәхси тормышымның кирәге юк дип саныйм, шуңа күрә бу хакта беркайчан түгелеп-чәчелеп сөйләмәдем. Башкалар сөйләгәнне дә өнәмим.

Хатыным спектакльләргә йөри, әмма беркайчан сәхнә артына кергәне юк. Шуңа күрә театрда да, шаяртып: «Хатынын күрсәтми ул», – диләр. Үзе керми. Сәхнә артына керү дөрес тә түгел. Хатының яки берәр дустың белән тәнәфес арасында нәрсәнедер хәл итәсең, борчыласың йә шатланасың икән, аннан спектаклең син теләгәнчә уйналмый – аңа үзгәреш керә. Спектакльдә, гомумән, бөтен нәрсә чагыла. Кайчак кемдер соңга кала да, пәрдә ун минутка соңрак ачыла. Һәм бу инде башка тамаша, син теләгән түгел... Элек спектакльне обкомнан килеп кабул итәләр иде. Күренекле режиссер Товстоногов, аннан киләсе вәкилләр тоткарланса да, бер минут көтмәгән – ишекне бикләп куя һәм спектакльне башлый торган булган. Чын театр шундый!



ДУСЛАР Дусларымның кайберләре, кызганыч, мәрхүм инде. Гомер буе Хәлим абый Җәләл белән дуслар булдык. Үз абыем кебек... Мин йомшаграк кеше, ул яклаучым да, киңәшчем дә, үзем юкта миңа тел-теш тидертмәүчем дә. Ә болай, гомумән, бик дуслар җыя торган кеше түгелмен. Минем иң тугрылыклы дустым – ялгызлык.



АКЧА Миңа беркайдан да акча ишелеп төшмәячәк. Без, артистлар, тыйнак яшибез, зур акчаларга эшләмибез. Аллага шөкер, тормышымда Тукай бик нык ярдәм итте. Аның шигырьләрен болай гына түгел, акчага да күп сөйләдем: концертларда, хөкүмәт чараларында... Тукай мине данга гына күммәде, тамагымны да туйдырды. Урыны оҗмахта булсын... Кемдер акчаны иблис белән тиңли. Акча кәгазь генә, аның гаебе юк. Бәлки, акча Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешенең рухи халәтен, иман ныклыгын, камиллеген сынау өчен уйлап чыгарылгандыр?!



МАВЫГУ Төрле якка бүлгәләнә алмыйм дип әйткән идем инде. Шигырь язып карадым – барып чыкмады. Тәрҗемәгә тотындым. «Ромео һәм Джульетта», «Король Лир», «Антонио һәм Клеопатра» (У. Шекспир), «Тартюф» (Мольер), «Мәхәббәт маҗаралары» (Лопе де Вега), Островский пьесаларын тәрҗемә иттем. Ләкин үз теләгем белән түгел, режиссерлар сорап килгәнгә генә эшләдем боларын. «Синеке әйбәт», диләр иде... Үзем артист булгач, сәхнә кануннарын язучылардан, бәлки, яхшырак аңлаганмындыр. Шул рольдә уйнаячак артистны күз алдымда тотып, үзем уйнап карый-карый тәрҗемә итә идем. Соңгы елларда инде туктадым. Бик авыр эш ул. Тәрҗемәче – авторның көндәше, диләр. Артык булмаса да, оригиналдан ким булмаска тиеш ахыргы нәтиҗә. Барысы да шигъри тәрҗемәләр иде бит – шигырь белән мавыгуның кирәге менә кайчан чыкты! Соңгы елларда исә Коръән уку белән мавыгам. Минем йокым 2–3 сәгать кенә: иртәнге 2–3 ләрдә инде уянам. Элек шигырь китаплары укый идем, хәзер – Коръән. Иң элек хәрефләрне, авазларны өйрәндем. Аннан, ничек дөрес укырга икән, дип эзләнә башладым. Тәҗвид дигән фән бар икән. Аның кагыйдәләрен өйрәнсәң, гарәп телен аңламасаң да, Коръәнне ялгышмыйча укый аласың – тәртә арасыннан чыгармый. Сораулар туганда, Ислам университетына да барып килдем, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә дә. Хәзер шактый шома укыйм. Мөмкин кадәр яттан да өйрәнәм. Яңа гына «Ясин» сүрәсен ятлап бетердем, хәзер «Тәбарәк»кә керешергә телим. Дини әдәбият белән дә кызыксынам: укыган саен диннең төбенә төшеп җитеп булмавын аңлый барам – ул океан кебек.



БАЛАЛАР Минем бер улым гына бар. Өчәү яшибез. Кызганыч, гаиләбез зур була алмады... Балачакта Рөстәм театрны бик ярата, килә, кайчак тоташ икешәр спектакль карый иде. Кумәк күренешләрдә сәхнәгә дә чыккалады. Аннан бермәлне кинәт туктады, ни өчен икәнен дә аңламадым. Финанс институтын тәмамлады, әйбәт кенә эшләп йөри. Бик тәртипле, инсафлы, сөйләшүләре, үз-үзен тотышлары – барысы да мин теләгәнчә. Киләчәктә дә әйбәт булсын, безгә аның кулына каласы...



КУРКУ Совет таралган елларда күңелдә курку беткәнгә курку бар иде. Бөтен нәрсәдән куркып өйрәнгәнбез – ансыз тормыш күңелсез тоелды. *(Көлә.)* Киләчәктә Ходай Тәгалә каршына барудан курку бар. Сынауны ничек узарбыз?! Әмма бу көннән ул кадәр куркырга да ярамый. Аллаһы Тәгалә, Коръәндә юл саен «гафур рәхим», дип кабатлый. Ул ярата безне, кичерер! Имансыз түгелбез...



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Хатын ачулана-ачулана салдырмаса, бер киемне бик озак кия алам. Кием-салымга кызыккан чаклар бар иде ул... Яшьлектә булмагач, хәзер ис китмидер, күрәсең. Көнкүреш мәсьәләләрендә, ничек итеп әйтергә икән, йомшаграк инде мин. Ә менә кешеләрне танып беләм дип әйтә алам. Нинди икәнлекләрен, нәрсә уйлаганнарын... Әүлиялек түгел бу. Тоемлау, интуиция... Әнидә дә бар иде ул, Рәшит абыйда да, сеңелдә дә бар. Авырый башлагач, әнине Казанга операциягә алып килдек. «Ачабыз да ябабыз гына», – диделәр. Ялынып диярлек ясаттык – терелеп китәр кебек иде... Миңа яңа гына фатир биргән чак. Әни больницадан чыгуга, аны фатир күрсәтергә алып киттем. «Шушында икәү яшәрбез», – дим. «Юк, авылга кайтыйм әле мин, сигез айдан үләм», – диде. Төш күргән икән... Һәм ул шулкадәр рас килде. Әни шул килүендә мине беренче һәм соңгы тапкыр сәхнәдә күрде. «Ак калфак»та Бакыйны уйный идем. Залда әни утыргач, каушаганмындыр да инде, ә ул: «Әйбәт, улым, әйбәт!» – диде...

ЙӨЗ ЕГЕРМЕНЕҢ БЕРСЕ

– Сәламнәр, Фәнзилә апасы! Мәрьямнең телефоннан Юкамен татарларына хас шивә белән җылы итеп дәшүе була, арабыздагы 130 чакрым әллә кая юкка чыга, әйтерсең лә ул янәшәдә генә, янымда гына басып тора. Башта йөзенә елмаю, аннары җитдилек кунуын күз алдына китерәм... Үзем дә елмаеп куям.



Бөтен шатлыгы, борчу-мәшәкатьләре өч гасырдан элек бабалары нигез салган шушы туфракка бәйле...

Без аның белән, гадәттә, күбрәк эш буенча аралашабыз. Шулай көйләнгән инде: Юкамен районының Тегермән авылында гомер кичерүче милләттәшләребез белән элемтә нәкъ менә Мәрьям Яхъя кызы Арасланова аша салына. Сәфәребез Тегермәнгә төшсә дә, безне гел ул каршы ала.

Удмуртиянең иң матур табигатьле районында урнашкан бай тарихлы бу авылда урамнары ак карга күмелгән вакытта да, җәйге чәчәкләрдән балкып утырганда да, көзге сары сарганда да булганым бар. Бүгенгесе бик матур аның! Ә үткәне турында Мәрьямнән дә күп белүче юктыр. Нәкъ менә ул авылдашлары истәлекләрен барлый, аклы-каралы фотосурәтләр җыя.

– Удмуртия картасында «Татарские Ключи» дип язылган, ә бабаларыбыз куйган атамасы – Тегермән. Бездә иң таралган фамилия – Арасланов. Бабаларыбыз Киров өлкәсендәге Арслан авылыннан күчеп килгәннәр, фамилия дә шуннан киткән, ди өлкән буын. Удмуртлар Вукогурт – «тегермәнле авыл» дип йөртә. Һәр ике атама районыбызның табигый һәйкәле саналучы мул сулы чишмәләре белән бәйле. Ә ул чишмәләр бер-бер генә дә түгел, әллә ничә урыннан тибеп чыгып, тәүлегенә 20 мең кешегә җитәрлек су бирү куәтенә ия... Авылыбызга нигез салынганга 370 елдан артык. Халык санын алу мәгълүматларына караганда, халкы 400 гә җиткән чорлар булган, хәзер без – Тегермәнлектә гомер кичерүчеләр – 120 тирәсе...

Мәрьям – шул йөз егерменең берсе. Яшьтәшләре шәһәр тормышын сайлаганда, Пермь дәүләт педагогика университеты дипломы белән туган авылына кайта ул. Гомере буе балаларга белем биргән әнисе Рәшидә Арасланова юлыннан китеп, мөгаллим һөнәрен сайлый. Белгечлеге дә туган туфрагына бәйле дияргә була – география фәнен укыта. Дәресләрне класс бүлмәсендә генә түгел, табигать кочагында уздыра. Компас, нивелир, рулетка кебек җайланмалар алалар да, укучылар белән сәяхәткә кузгалалар... Юкамен районында алар булмаган почмак калмагандыр, укучылары елга, тау, торак пунктларның исемнәрен ишетеп кенә түгел, күреп белә.

Күрше Сидорово авылы артындагы калкулыкның иң биек ноктасына менсәң, туган авылы Тегермән уч төбендә кебек күренә! Мәрьям үзе укыта торган Починки авылы мәктәбендә «Краеведение» – туган якны өйрәнү дәресләрен дә алып бара. «Үз төбәгенең матурлыгын күрмәгән кеше аның кадерен дә белми», – дип өйрәтә ул укучыларын. Сүз генә түгел, гамәл белән өйрәтә! Авыл янынннан Лекмә елгасы ага, аның ярында Тегермән татарларының биш – су, бер җил тегермәне эшләп торган, бөтен тирә-як халкы: татары, русы, удмурты он тарттырырга килә торган булган. Биш тегермән ташын әйләндергән Лекмәгә авыл чишмәсе дә җегәр өстәгән. Авыл янынннан узган мосафирлар аның суын эчеп хәл алган... Менә шул чишмәне карап-тәрбияләп торуда Мәрьям Арасланова башлап йөри дә. Укучылары белән өмәләр уздырып, тирә-ягын чистарталар. Юкамен районы Советы депутаты буларак та сүзе үтә: күмәк хуҗалык ярдәме белән чишмәнең бурасын яңартканнар, басмаларын алыштырганнар. Авылда саклап килүче йола-гадәтләр дә борын-борыннан чишмә белән бәйле. Яңа туган баланы тәүге тапкыр чишмә суы белән юындырганнар, яшь киленгә су юлы күрсәткәннәр, каз өмә (Тегермәндә шулай диләр!) башланган чорда чишмә янындагы инеш басмалары гөр килеп торган. Хәзер дә шулай! Җирле телетапшыруның иҗат төркеме белән барганыбыз, бу йолаларын төшергәнебез бар. Мәрьям ул чакта боларның барысын да оештыручы гына түгел, кунакчыл хуҗабикә дә булды. Әнисе Рәшидә апа белән каз өмәсенә килүчеләрне мичтә кайнар коймак, чүлмәктә өч төрле ярмадан ботка пешереп сыйладылар. Тәмнәре һаман да тел очында тора кебек... Нинди генә бәйрәмгә, чарага җыймасын – һәрвакыт укучылары аның янәшәсендә булыр: алар күреп, сеңдереп үссен дип тырыша. Югыйсә чит төбәктәге башка авыллар кебек үк, Тегермән дә әкренләп катнашка әверелеп бара. Дөрес, катнаш никахлар элек тә булган: удмурт кызлары килен булып төшкән, аларга никах вакытында мөселман исемен биргәннәр, яши-яши татарча сөйләшергә өйрәнгәннәр, ир йортындагы йола-гадәтләрне тота башлаганнар... Язма героемнан читкә киттем кебек. Хәер, авыл турында сөйләгәндә, барысы да Мәрьямгә килеп тоташа.
Аның энергиясе Тегермән генә түгел, тирә-яктагы Починки, Засеково, Шәфи, Палагай авылларындагы милләттәшләребезне рухландырырга да җитә. Үзе әйтүенчә, ел башында бергәләп план төзиләр дә Сабантуй, Нәүрүз, Авыл бәйрәмнәрен гөрләтәләр.

Тегермәндә яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласын төшергәндә, сиксән чиген узган әбиләр белән сөйләшеп торган идем. «Ярый әле Мәрьямебез бар, югыйсә болар инде онытыла бара бит. Ул булмаса, кем яңартыр иде йолаларны?!» – диделәр.

Мәдәният учагын да Мәрьям саклый – авыл клубын җитәкли. Узган җәйдә, җыелып, үз көчләре

Мәрьямне туган авылыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Тегермәнне аның кебек яратучы тагын бармы икән ул?!



Кайда, нинди сәхнәгә күтәрелсә дә, Мәрьям туган ягына дан җырлый – Тегермәнне зурлый.

белән ремонт ясаганнар. «Бабье лето» («Әбиләр чуагы») исемле катнаш ансамбльләре бар. Ничек барысына да өлгерә! Мәрьям бит әле сәфәрләр дә ярата, илнең иң матур почмакларына сәяхәт кыла. Ә юллары барыбер кире туган авылына алып кайта.

Соңгы елларда Тегермән тирәсен балтырган (борщевик) баса башлаган. Авылдашлары белән шушы әрсез үләнгә каршы көрәш ачканнар, тамыры белән казып юк итәләр. «Үзебез тырышмасак, безгә беркем дә китереп бирмәс, кайгыртмас», – дигән фикердә Мәрьям Арасланова. Быел «Инициатив бюджетлау» республика проектлар бәйгесендә катнашырга ниятлиләр. Кискен торган социаль ихтыяҗларны хәл итүгә юнәлдерелгән проект бу. Ниятләре – авылда балалар мәйданчыгы булдыру. Бу хакта авыл җыенында уртага салып сөйләшкәннәр, актив төркем туплаганнар. Урын да сайлаганнар: элек башлангыч мәктәп торган җирдә булачак. Ә Мәрьямнең мәктәбе – күрше Починкида, шулай ук татар авылы. Татар теле фән буларак укытыла торган белем йорты. Туксанынчы еллар башында, милли хәрәкәт күтәрелгән чорда Удмуртия мәктәпләрендә Тукай теле кертелә башлый. Булдыра алмам, дип тормый Мәрьям, география белән беррәттән, яңа фәнне укытуны да үз өстенә ала. Алда язып үткәнемчә, Юкамен татарлары сөйләме үзгә, аралашканда: «Без Казаннар кебек сөйләшә алмыйбыз», – дип кыенсынучылар бар. Әмма Мәрьям түгел! Үз диалектларын татар теленең төрлелеге, байлыгы дип кабул итә, балаларга да шуны аңлата. Аның татар теле дәресләре дә географиянеке кебек үк мавыктыргыч. Әкият икән, көзге яки язгы матур бер көндә аны мәктәп ишегалдына чыгып укырга мөмкиннәр. Ачык һавада, авыл мохитендә табигать авазлары белән әкияткә күпме төсмер өстәлә! Ә шуларны сәхнәләштерүләр, әдәби кичәләр, татар халык ашлары буенча осталык дәресләре! Мәрьям Арасланова 2017 елда «Иң яхшы ана теле укытучысы» республика бәйгесендә катнашты. «Югары педагогик осталык» номинациясендә билгеләп уздылар. Ә аның өчен иң зур бәя – укучыларының мәктәп тәмамлаганнан соң да килеп йөрүләре, рәхмәтле булулары. Шуларның берсе – Айдар Абашев. Кечкенәдән ятим калып, әбибабай тәрбиясендә үсүче малай, Мәрьям апасының күңел җылысын, ихластан кайгыртуын тоеп, тугыз классны уңышлы тәмамлый һәм Ижау музыка көллиятенә укырга керә. Ә андый мисаллар бихисап.

...Күптән түгел Мәрьям укучыларын татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасына алып килде. Һәрнәрсәгә үз карашы, фикере булуы һәм аларны кыю төстә белдерә алуы сокландыра. Шатлыгын да, борчуын да яшерми ул. Авыл мәктәпләре укытучылары бер уңайдан яңа дәреслекләр дә алды. «Тикшерәләр, прокуратура да килә. Сез ничек иске дәреслекләр белән татар теле һәм әдәбиятын укытасыз, дип сорыйлар. Яңалары юк дип, туган телне фәннәр исемлегеннән сызып ташлап булмый бит», – ди Мәрьям Арасланова. Типография буявы исе аңкып торган өр-яңа китапларны актара-актара: «Тагын биш ел тынычлап укытабыз!» – дип сөенә.

Таныш булуың белән куандыручы кешеләр бар. Мәрьям – минем өчен шундыйлардан. Аның белән йөзләрчә чакрымнарны узып, Казанга барып кайткан бар: сөйләшеп сүзебез бетмәде. Юкамен районына барсак та, каршылап, бөтен татар авылларына озатып, кирәкле кешеләр белән очраштырып йөри ул журналистларны. Районны биш бармагыдай белә, вакытын кызганмый. Балаларның да Мәрьям апаларын яратуы, үз фәнен шулкадәр кызыклы итеп бирә алуы аның коеп куйган мөгаллим булуына дәлил.

Фәнзилә САЛИХОВА.
Удмуртия.



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

КҮҢЕЛ ЧИСТАЛЫГЫ

Аллаһ каршындагы дәрәҗә алган гыйлем түгел, ә күңел чисталыгы белән бәяләнә, диләр. Күңел чисталыгы дигәндә ниләр күз алдында тотыла?

– Күңел чисталыгын бөтен кеше үзенчә аңлый. Игътибар итсәгез, күпләр: «Минем күңелем чиста», – диләр. Әмма еш кына күңел чисталыгының нәрсә икәнен белмичә әйтәләр. Әгәр аны ниндидер бер кешелеклелек сыйфаты белән бәйләп карасаң, бу – бер караш. Ә Аллаһы Тәгалә белән бәйләсәк, икенче караш барлыкка килә. Пәйгамбәребезнең шундый сүзләре бар: «Аллаһы Тәгалә бөтен гөнаһны да гафу итә, ширек китерүне генә гафу итми», – ди. Аллаһы Тәгалә каршына килеп басып, ул күңелләребезне, йөрәкләребезне караганда, беренче чиратта иманлымы, имансызмы икәнебезгә игътибар итә. Күп кеше: «Аллаһыга ышану мөһим түгел – күңелең чиста булсын», – диләр.
Ә менә бу очракта Аллаһы Тәгалә иманы булмаган, ширек (хорафатларга ышану) китергәннәргә карамый – аларның гамәлләренә дә хисап бирелми. Андыйларга юл – тәмугка гына. Менә шундый хикмәт. Игътибар итсеннәр, күңеленңне, йөрәгеңне карасыннар өчен иң элек иманлы булу шарт. Инде ничек итеп йөрәккә, күңелгә бәя бирергә була? Күңел чисталыгының билгесе – иман. Ул – Аллаһы Тәгаләгә булган мөнәсәбәт тә. Ләкин әгәр мөнәсәбәтең үзеңә карата яхшы булмаса, күңел чиста булып бетми. Син үзеңә яхшылык теләргә тиеш. Ничек итепме? Үзеңне үз кулың белән тәмугка кертмәскә, ягъни гөнаһ кылмаска тиешсең. Кайберәүләр урлаша, зина кыла, бәйрәмнәрдә эчә, ләкин күңелем чиста, ди. Күңеле чиста кеше үзенә начарлык теләми – мондый гөнаһларны кылмый. Шулай ук күңеле чиста булган кеше башкаларга да яхшылык тели: кеше хакына керми – сүз белән дә, гамәл белән дә, уй белән дә. Кеше хакына кермәү – бик зур әйбер. Әгәр берәр нәрсәсен урласаң, суксаң, гайбәтен сөйләсәң, тел белән рәнҗетсәң, аның турында начар уйласаң – барысы да аның хакына керү була. Кеше әйберенә карап көнләшү – шулай ук уй белән аның хакына керү, начарлык теләү. Күңел чисталыгы ул һәрвакыт гамәлдә чагылыш табарга тиеш. Бу хакта сөйләшкәндә ният төшенчәсен дә онытмаска кирәк. Әгәр дә берәүгә яхшылык эшлисең икән, ниятең изге булырга тиеш. Монда ихласлык та өстәлә: яхшылык эшләгәндә беркемнән бернәрсә дә көтмәү, аны бары Аллаһы Тәгаләдән генә өмет итү. Менә шушы ихласлык та күңелебезнең чисталыгын билгели. Әгәр без яхшылыкны кемнән дә булса мактау өмет итеп эшлибез, аннан шуның хакын сорыйбыз, исенә төшереп торабыз икән, димәк, күңелебез керле.

Күңелне ниләр пычрата?

– Аллаһы Тәгаләдән ерагаю һәм дөньяны артык ярату пычрата аны. Кеше дөньяны артык яратып җибәрә икән, аның нәфесе үсә, һәм ул үзенә гел муллык, байлык тели башлаячак. Теләү генә түгел, шуңа омтылачак. Һәм бу юлда башкалар хакына да керүе бар. Ул саранга әйләнә: байлыгы китсә, кайгыра. Шушылай дөнья белән генә яшәү аның күңелен пычрата да инде. Менә без дөнья бозылды, дибез. Кайчан башланды соң ул? Күпләр туксанынчы елларда дип уйлый. Ә ул дин, иман беткәч, 50–60 нчы елларда ук башланды. Кешеләрдәге агрессия, бер-берсенә булган начар мөнәсәбәт, көнчелек... Күңелдән дин киткәч, кеше дөнья белән генә яши башлый. Ә нәфесне аны берничек туендырып булмый. Бүгенге көндә миллионерларны, миллиардерларны күреп: «Нишләп туктый алмый икән болар?» – дип гаҗәпләнәбез. Пәйгамбәребез әллә кайчан: «Әгәр кешегә җир йөзенең ярты малын бирсәң, икенче яртысын теләр. Анысын да бирсәң, бүтән бер кешедә дә булмасын иде бу байлык, дип теләр», дип әйткән. Иманын, Аллаһы Тәгалә белән элемтәсен югалткан кеше, гадәттә, дөнья малына хирыс була.

Пычранган күңелне ничек чистартырга соң?

– Монда беренче юл – иманга килү, кылган гөнаһларга тәүбә итү, Аллаһ ризалыгы өчен ихластан изге гамәлләр кылу. Кайберәүләр: «Изге гамәл кылудан файда юк, барыбер рәхмәт ишетмисең», – диләр. Болай әйтә икән, димәк, бу кешенең күңеле пычрак: ул изге гамәлне рәхмәт өчен генә кыла. Изге гамәл кыласың икән, иң элек аның өчен үзең куанырга, шатланырга тиешсең – шулай итеп күңелне чистартырга мөмкин. Моны исә иманга килү юлы белән генә эшләргә мөмкин. Әйе, иман булмаса да яшәп була. Әмма нәрсә хисабына, нинди байлык белән яшисең? Мәсәлән, Европада, иман булмаса да, кеше яхшы яши, дибез. Тик яхшы яшәү – дөрес яшәү дигән сүз түгел әле. Кечкенә генә мисал. Кибетләренең берсендә ут бетә: камералар, сигнализация эшләми. Һәм кибетне шул мизгелдә үк талап чыгалар. Урлауга баралар икән – халыкның күңеле чиста түгел. Кабатлыйм: күңел яхшылыгы, чисталыгы иман төшенчәсе белән тыгыз бәйле. «Бүген иманлы дип йөргән кешеләр дә начарлык кыла», – диярсез. Димәк, аларның күңелләре әле ахыргача чиста түгел.

Күңелне чистартыр өчен, кабатлыйм, өч шартны үтәргә кирәк: Аллаһка ышанырга, үзеңә һәм кешеләргә яхшылык теләргә. Менә шулай иткәндә, ихлас белән изге гамәл кылганда, аның өчен куанганда, булганына шөкер итә белгәндә генә күңел чисталыгы белән яшәргә мөмкин.



ДУЛЫЙ БУРАН...

Асия ЮНЫСОВА

Кар өстендә ал розалар

Кар өстендә ал розалар.
Чәчелеп яткан буш вәгъдәләр...
Кемдер әйткән, кемдер көткән...
Кемдер аннан ташлап киткән.

Кар өстендә ал розалар.
Ак җирлектә гөл бизәкләр...
Кемдер кемнән бизенгәнгә
Гаепләме ал розалар?

Кар өстендә ал розалар...
Җылы учта җылынуга
Бик ризадыр сөю гөле.
Читтән-читтән үтүчеләр,

Беләдер дә гаепләнең
Гөл түгелен.
Ачылмый шул назлы гөлгә
Җылы куен.

Тиле гашыйк шашынды ла,
Гөлләр шуңа шаһит кына.
Аңлый алмый садә җисем
Кеше белән гөл арасын.

Хискә тулган касәсеннән
Рәнҗүләре ташып чыга.
Туңган җиргә туңган җанның
Соңгы суты, әрем кебек иң ачысы

Агып төшә. Бардыр ла ул
Кар астында җылы туфрак!
Ялвар аңа, алсу гөлем,
Яклау сорап.

* * *

Дулый буран, бөтерелә!
Күптән көткән бу буранның
Ак ялына ябышканмын.
Дула, буран, бөтерел син.
Ак ялларның ак дулкыны
Минем яклы – терелермен!

Дула, буран!
Безнең холык дулый торган.
Каралыкның табын табып,
Аклык белән урый торган!
Дула, буран!
Сиңа ияреп кузгалдым бит.
Безнең холык бураннарда
Ярсый-ярсый тузгый торган.
Дула, буран!
Ак песидәй йомарланып
Йоклый торган түгел көнем.
Мин дә буран...
Өермәдәй бөтерелеп,
Күккә ашам, күккә ашам...
Ә аннары бөтерелеп,
Кайтырмын мин... бетеренеп,
Юк, терелеп.
Ак буранның ак шәленә
Челтәренә төренермен...
Чибәрләнеп...

Мамык шәл

Көн дә буран дулап тормый.
Ярый әле көн дә түгел.
Дулаганда шәһәр өе җылы тотмый.

Бүген менә дулый икән...
Кәҗә мамык шәлкәеңне
Иңнәреңә сал да уран.

Ике дистә еллар элек
Сеңеп калган әни исе
Тулсын өйгә, иркәләсен,
Сөйсен мине.
Иркә җылы, талгын җылы,
Йомшак җылы – әни кулы.
Һәр күзәнәк, гөл күзедәй,
Җуймый саклый хатирәнең
Җәүһәр кебек кадерлесен.

Һай, бу буран!
Алган булып өй җылысын,
Йөрәгемә җәеп салдың
Хатирәнең иң олысын!

Ике битем мамык шәлдә –
Сулыйм-сулыйм – туя алмыйм.
Менә бит ул – әни монда,
Җылы учы яңагымда.

Тынма, буран, дула гына.
Мин туңмамын –
Яңагымда әни шәле,
Хәтеремдә әни барда.

***

Куе кызыл иреннәрем,
Салкыннандыр, көеп килгән.
Күп газаплар күрүләрдән,
Ирен чәйнәп түзүләрдән
Куе кызыл иреннәрдән
Мәрҗән-сәйлән сибелеп калган.

Явып үткән кар өстенә вак-вак бизәк,
Ялварулы теләкләрем түгелме бу?
Күз яшьләрен мәрҗәннәрнең,
Ачуташтай әрнүләрен
Асылташ дип алданганда
Рәнҗешләрен уйладыкмы?

Һай, матурлар!
Муеннарга урадыкмы?
Рәнҗешләре кайткан икән
Диңгезләрдән безнең белән
Язмышларга уралып ла!

Туң кайту

Зәмһәрирдән өйгә керткәч,
Әйтә торганнар иде –
Туңы кайтсын!
Янәмәсе, җае белән эресен.
Менә мин дә туң җанымның
Көтәм әле эресен.

Астан ут җибәрү түгел,
Ашыктырмау мәслихәт.
«Туң бит әле.
Эчкәенә җылы төшсен,
Туңган җирдән сынмасын».

Сынар чаклар булып торды,
Сынатмау иде исәп.
Сыну мөмкин булгандыр ул,
Җылы сүз ишетеп кисәк.

Дөрләргә иде бит әле!
Сүнеп калмаска иде.
Уттан янмый чыккан коштай,
Канат җәяргә иде.

Дөрләп янам әле мин бер!
«Тавыклар» аунасын әйдә
Миннән коелган көлдә!

Кер чайкау

Хәзергеләр беләмени
Бәкедә кер чайкауларны.
Ул чактагы суыклардан
Ыкта боз чатнауларны.

Көянтәнең ике башы –
Шыплап тулган чиләкләр.
Җырда гына матур ла ул:
«Алмалы көянтәсе,
җиләкле чиләкләре»...
Кыш бабай үзе ясый ул
Кышның гөл бизәкләрен.

Кайнар кердән үскән пардан
Ишеп куя шәмдәлләр,
Чиләкләрдә көмеш камыш,
Чәчтә ландыш-тәлгәшләр.

И-и, ул кер чайкаулары!
Күшеккән сабый кулларны
Чиләктәге кер янында
Җылытып алулары,
Бер мизгел ләззәттән алып,
Гөлсабактай беләгеңне
Бәкегә салулары!

Ярый ла,
Җебек кулыңнан ычкынып,
Кереңагып китмәсә,
Көянтә ырмавы качкынны
Эләктереп өлгерсә....

Ык буенда син берүзең,
Беркем тормый сагында.
Бар ышаныч чиләктәге
Җылы булырга тиешле
Суынып беткән суда.

Җәһәт кайтып, керләреңне
Тезеп өлгерсәң бауга,
Бер-ике көн җилли кереңг,
Җилкән кебек буранда.

Йә кош кебек кагына ул,
Әллә Ыгын сагына.
Кер чайкаган кызның гына
Ак морҗада шәүләсе.
Морҗа җылысы басмый ла
Кызышкан кул әрнүен.

Ә керләр кершәндәй икән.
Беркөн,
Тыш салкынына уралып,
Баудан керделәр өйгә.
Мич тартылган. Майдай җылы.

Усак исен үзенә җыеп,
Туңнар эри җай гына.
Туңнан кергән керләр исе
Сагындыра. Чын менә!

Намазлык

Кыш, гаҗәеп дөнья үзең!
Син олы бер фәлсәфә.
Җир карасын тырышып каплап,
Ниләр әйтәсең, нәрсә?..

Шундый булырга тиештер
Без яшәгән бу гавам.
Син китеп торган арада
Керләнәбез бит тәмам.

Кыш, син рәнҗемә инде!
Күтәп алабыз сине.
Каралыкны җуйган аклык
Тансык намазлык безгә!

Һәммәбезгә җиткелекле
Күз чагылдыргыч бу аклык,
Җаннарны сафламый гына
Кыеп басмалы түгел.

Син күкләрдән Җиргә иңгән,
Һич кер кунмаска тиешле
Килен бирнәсе сыман.
Киленнең дә кер кунмаган
Чиккән намазлыгы бар.
Шушы бирнә, шул намазлык –
Күк нигъмәте – ап-ак кар!

Кошлар, әнә, таң намазга
Бездән алда өлгергән.
Ул кошкайлар бездән элек
Кардан тәпи йөгергән.

Капка төбе

Зәмһәрир суык бер кичтә
Кем капка сакламаган?
Миһербанлы егетеңнең
Итегенә баса-баса,
Төнге Айны озаткан да,
Йолдызлар күзләмәгән?

Булган инде, узган инде.
Ай да һаман шул йөрүдә,
Йолдызлар да качмаган ул.
Картаела җай гына.
Безнең яшь гомерләр генә
Үрдән төшү җаенда.

Теге киез итекләрне...
Капка төбен саклауларны
Онытып бетергәч кенә
Салкыннар кайтты менә.
Яшьлек тә кайтыр микән, ә?

Шагыйрь Рәфикъ Юныска

Ап-ак карда яңа яра!
Яңа кабер – яра яңа!
Уттай кайнар бер йөрәктән
Карлы туфрак көйрәп яна.

Шагыйрь йөрәге анда,
Көйрәми буламыни?!
Карга төшәр, утка төшәр,
Сайрамый тынамыни?!

Уттай түшле Кызылтүш –
Миләшкә кунды йөрәк.
Шул мизгелдә миләшләрдә
Ялкын кабынды дөрләп.
Миләш төймәләре саен...
Бирәр йөрәк, меңәр йөрәк..
Янар да янар инде.

Ап-ак карлар – шигырьләре
Явар да явар инде...
Яралар соң, еллар саен
Яңарып торыр инде...



Ул күңелгә үтәрлек нечкә шигырьләре белән генә түгел, хатын-кыз йөрәге аша уздырып язылган хикәяләре белән дә укучылар күңелен яулады инде.
Шагыйрь диеп сокландылар бар да –
Мин хатын-кыз идем иң элек! – дигән шигъри юллары ук иҗатын күз алдына китерергә булыша. Илсөяр Иксанова! Бу көннәрдә юбилеен билгеләп үтүче каләмдәшебезне гомер бәйрәме белән котлыйбыз, иҗат уңышлары телибез! Игътибарыгызга Илсөяр Иксанованың «Коткару» хикәясен тәкъдим итәбез.



Илсөяр ИКСАНОВА

КОТКАРУЧЫ

(Хикәя)

Тәрәзәдән караганда, пары чыгып торган сөт төсле тоелса да, һава шактый салкынча икән. Иртәнге дымлы һава Розалиянең тәнен чиркандырып куйды. Ул, култыгына гына элеп чыккан җиңел кофтасын тиз генә киеп алды да, таң чыгы юешләп тимгел-тимгел иткән асфальтка бу көннең беренче эзләрен салып, юлына ашыкты.

Күтәрелә барган томан эчендә йокысыннан әле уянып җитмәгән шәһәр әкрен генә тибрәлеп торгандай тоела. Томанга төренгән биек йортлар арасында Розалия үзен бер мизгелдә таулар тарлавыгында калгандай хис итте. Юк, таулардагы томаннар башка. Башка иде. Таралып бетте дип уйласа да, ул томаннар хәтер төпкеленнән һаман да баш калкытмакчы икән әле. Юк, юк, томаннар турында уйлар вакытмыни! Әнә, аксыл томан артында кояшның сүрән шәүләсе шәйләнә.

Кичә кайтып та торасы калмаган икән. Катлаулы операциядән соң ул, гадәттә, хастаханәдә кала иде. Алай тынычрак. Тик кичә кайтып йоклыйсы итте шул. Пациентның хәле авыр булса да, тотрыклы иде. Шулай да хәл төрле якка үзгәрергә мөмкин. Күзенә барыбер йокы эленмәде. Тәрәзә артында таңы да сызылмый азаплады. Торып сәгатьне караса, биш тулган икән инде, ә тәрәзә артында куе томан...

Өеннән хастаханәгә кадәр булган ун минутлык ара да әллә никадәр озын тоелды бу юлы. Ишектә дә аны кичә озатып калган вахтер каршы алды. Хастаханә яңалыкларын вахтерлардан да күбрәк белүче юктыр, мөгаен. Хәлләрне генә түгел, сулышыңны-тыныңны белеп тора алар. Менә хәзер дә Розалия белән исәнләшүгә, тынычландырырга ашыккан тавыш белән: «Тәртип!» – дип куйды. Розалия күңел халәтен тавышына чыгармый гына: «Рәхмәт, Мансур абый!» – диде һәм, баскычтан йөгереп китүдән чак тыелып, лифт төймәсенә басты. Розалиядән бер адымга гына калып, артыннан вахтер атлады.

– Роза Фатиховна!.. Әнисе... Таңга кадәр утырды. Монда. Ишек төбендә... Докторны көтәм, дип. Таң белән килеп җитәсегезне белсәм дә: «Доктор алай иртә килми әле ул, берәр җиргә барып чәй эчеп алыгыз!» – дип җибәрдем... көчкә. Озак тормас, килеп җитәр...

– Яхшы. Тик аның белән әле төштән соң гына сөйләшә алырмын.

Соңгы җөмләне әллә вахтерга әйтте, әллә үз-алдына...

...Әнисе. Көтсен! Көтсен... Көтү өмет бит ул. Билгесезлекнең никадәр җанны талкуын белә Розалия. Тик, барыбер, өмет... Өмет иң соңыннан үлә, диләр. Дөрестән дә шулай.

Ире, Фәрухы идарә иткән хәрби вертолетның югалу хәбәрен ишеткәч тә, күңеленә килгән яман уйларны куып, өметен кабызды Розалия. Вертолетның томанда кыяга бәрелеп, тарлавыкка төшүе билгеле булгач та өметен сүндермәде. Билгесезлек шомы җанын талкыса да, көтте. Көтү авыр иде. Көтү... яшәү иде... Өмет иң соңыннан сүнде.

Ә бу ананың өмете сүнмәячәк! Тик аның белән очрашканчы Розалиягә әле пациентны карыйсы, әнисенә әйтәсе сүзләрне тәгаенлисе бар. Кирәк бит, шулкадәр катлаулы операцияне җиңеп чыгабыз гына дигәндә... йөрәге туктады да куйды! Ярый бөтенләйгә туктамады... Тик... алга таба йөрәге ничек булыр? Түзәрме? Әле тагын операция өстәленә ятасы бар бит егетнең.

Кабинетына кереп халатын гына элде дә, реанимация бүлегенә ашыкты Розалия. Егет наркоздан айныган, аңына килгән иде. Кизү табиб, хәлен «тотрыклы, уртача авыр», дип җиткерде. Авыруга иелә төшеп, Розалия ак җәймә өстендә яткан салкынча кулны кысты: «Яхшы. Бар да яхшы булачак!» Егет кипшенгән иреннәрен чак кыймылдатып алды: «Яхшы...» – дип кабатлады кебек. Яхшы гынамы соң! Искиткеч! Исән! Аңында! Күз төпләре күгелҗемләнеп, тәүлек эчендә битенең тиресенә сары кунып өлгерсә дә... Болай булгач, яхшы! Аның хәзер үтереп эчәсе килүен аңлый Розалия. Шәфкать туташына кашыклап кына су бирергә кушты. Пациент мониторындагы күрсәткечләргә күз йөртеп алды, аларны авыруның картасына кизү табиб теркәп калдырган күрсәткечләр белән чагыштырып карады да, тынычланып, реанимация бүлегеннән чыкты. Өске катка күтәрелде. Коридорның зур-зур тәрәзәләрен кояш алтынсу-ал төскә буяган иде. Иртәнге томан таралган. Яңа көн туган. Көн үзәгенә таба үҗәтләнеп кыздырып алырга ниятләгән август кояшы күтәрелеп килә.

Эш бүлмәсе ягына борылуга, кабинетлар арасына куелган урындыкларның берсендә утырган хатын, сикереп торып, аның ягына омтылып алды: «Рузалия!» Аннан туктап, Розалиянең янына килеп җиткәнен көтә башлады.

Розалия дә түгел, Рузалия! Әбисеннән башка кешенең аңа болай дәшкәнен дә хәтерләми. Юк, аңа дәшүче түгелдер. Аңа биредә беркемнең дә Розалия дип тә әйткәне юк. Роза Фатиховна! Бары шулай. Бу хатын кем беләндер бутадымы? Розалия хатынга игътибар итмәскә тырышып, алдына гына карап атлавында булды. Үзеңә төбәлеп торган кеше яныннан битараф кына узып китүе кыен иде. Узып китәргә өлгермәде, пышылдап диярлек әкрен чыккан тавыш аны туктатты:

– Рузалия... Син... мине танымыйсың инде...

Хатынның арыган йөзенә текәлеп, таныш чалымнар табарга тырышып караса да... юк, күргән-белгән кешесе түгел иде бу.

– Танымыйсы-ы-ың! Мин сине астагы фотоңнан ук таныдым. Утыз еллап күрешкән булмаса да...

– Гафу итегез, танымыйм шул. Минем янга булсагыз...

Розалия гадәтенчә кул сәгатенә карап алды.

– Беләм... эшең тыгыз. Шулай да улымның хәле турында гына әйт инде! Мине кертмиләр бит аның янына...

Хатын сулкылдап елап җибәрде. Әнисе! Аңлады Розалия. Кичә ул операция ясаган егетнең әнисе. Аның белән төштән соң гына сөйләшермен дигән иде.

– Борчылмагыз, бар да яхшы. Әйдәгез...

Хатын, сулкылдавын тыярга тырышып, аның артыннан иярде. Кабинетка кергәч тә, танырга теләп, аны тагын бер кат күздән кичереп алды Розалия. Юан дип әйтеп булмаса да, олыгаю ягында: бил турылары калынаеп, киңәебрәк киткән, бөтен килеш-килбәтеннән гадәти гадилек бөркелеп торган хатын. Джинсы чалбарына бик үк килешле булмаган туника киеп куйган. Күптән буялмаган чәч төпләре чаларып үскән. Талчыккан йөзендә шактый тирән җыерчыклар... Инәлеп караган дымлы күзләр... Хәтер төпкелендә бер мизгелгә генә нидер кыймылдап куйгандай булды. Тик хәтердә казынып торыр вакыт түгел, ана кешегә улының хәле турында җиткереп, көндәлек эшләренә тотынасы иде.

– Тынычланыгыз! Иң авыры артта калды. Улыгыз терелер. Тик тиз булмас.

– Мине... алып кер инде янына. Күрим үз күзләрем белән исәнлеген!

– Исән ул, аңында. Хәле начар түгел. Ышаныгыз миңа. Мин сезне реанимация бүлегенә кертә алмыйм...

– Син... бүлек мөдире, дигән бит... Син дә кертә алмаска!..

– Хәле шулай торса, берничә көннән палатага күчерерләр. Анда күрерсез.

– Кайлардан син... туры килдең, Рузалия! Әйттеләр инде... Операцияне үзе ясады, дип... Үлемнән тартып алды, дип...

Хатын тагын елап җибәрде.

– Еларга түгел, сөенергә кирәк. Хәл чынлап та бик катлаулы иде. Берьюлы берничә органга операция ясарга туры килде. Мин генә түгел, өч хирург ясадык операцияне... – Фрагментларга бүлгәләнгән бавырын яңадан җыеп куйдык, дип үк әйтмәде инде. – Йөрәге ничек иде элек?



– Йөрәге?.. – Хатын бер мәлгә сискәнеп куйды. Үзен кулга алырга тырышып сөйләсә дә, җан елавы тавышына чыкты. – Зарланганы юк иде йөрәгенә.

– Яхшы, йөрәген кабат тикшербез. Хәле бераз рәтләнгәч, аягына операция ясарга туры киләчәк. Чәрдәкләнеп сынган.

– Тагын... операция!

– Шунсыз булмый. Монысы өчен Ходайга шөкер итегез!

– Итмәгән кая! Ул машина эчендә кеше исән калыр дип уйларлыкмыни! Яньчелгән-сытылган тимер өеме генә калган бит машинадан!.. Ходайга да, сиңа да мең рәхмәтләр!.. Син булмасаң... Балачактан ук врач булып уйный идең шул син!

Балачактан?.. Менә кай заманнан таныш икән бу хатын...

– Балачакта бергә уйный идек без синең белән. Авылда. Әбиең безнең күрше иде. Фәгыйлә апа...

– Гүзәл!..

Юк, мәңге танымас иде! Гүзәл! Нинди кыз иде бит ул! Чая! Янып торган кыз! Розалия аның исеменә кызыга иде. Аның чыркылдап көлүенә кызыга иде...

Киеренкелекне йомшартыр өчен, Розалия балачак хатирәләрен уятасы итте.

– Хәтерлисеңме, Гүзәл, без күлмәкләрне алмашып кия идек.

Гүзәл бер мәлгә аптырабрак калгандай булды. Аннан нindидер үтә моңсу тавыш белән сүзгә кушылды.

– Син шундый матур күлмәкләр киеп чыга идең уйнарга. Капрон. И кызыга идек инде синең күлмәкләргә!

– Минем әби ул капрон күлмәкләрне яратмый иде. Балага бер җүнле кием алып кайта белмиләр, дип әниләрне ачулана иде.

– Синең күлмәкне киеп өйгә кайткач, әни мине әрләде. Кеше күлмәген кияргә ярамый, диде.

– Кызык. Өстемнән синең күлмәкне салдырганда, миңа да әби, кеше киемен кияргә ярамый, дигән иде.

– Дөрес әйткәннәр. Һәр кешенең үз киеме, үз язмышы. Менә мине танымаслык итеп үзгәртте язмыш дигәнең.

– Барыбызны да үзгәрткән инде... – дип кенә куйды Розалия.

– Юк, мин сине фотоңнан ук таныдым. Улымны... Раилемне монда китергәннәрен ишеткәч, килеп җиттем. Операциядә, диделәр. Үземне куяр урын тапмый бәргәләнеп йөрүемне күзәтеп торган вахтер: «Борчылма, операцияне Роза Фатиховна үзе ясый! Аның кулына эләккәч инде!» – дип, аскы катта эленеп торган фотолар янына алып барды. Бит очындагы чокырлардан ук танып алдым: Рузалия! Күпме гомердән соң менә ничек итеп очраш...

Әйе, күпме гомер! Әбисенең авылына Розалия соңгы тапкыр унынчыга күчкән җәйне кайткан иде. Шул көздә әбисе дөнья куйды. Аннан Розалия Ленинградка китте. Хәрби-медицина академиясенә укырга керде.

– Рузалия!.. Бер генә минутка алып кер инде Раилем янына... улым янына! Зинһарлар өчен!..

– Хәзер түгел, Гүзәл! Кичкә карарбыз, яме. Син хәзер монда берни дә эшли алмыйсың. Тынычлан, иң авырын үттек. Кайт, ял ит. Сәгать бишләрдән соң килерсең.

Гүзәл инде дүрт тулганда хастаханәдә иде. Розалия өчен бу көн гадәти, тыныч эш көне саналса да, ниндидер матавыклы булды. Ул сәгать алтыларда гына бушады.

– Әйдә, миңа кереп торыйк әле, – диде ул, Гүзәлнең улы янына керергә сабырсызланып утырганын аңласа да. – Хастаханәнең үз тәртипләре.

Алар кабинетка кергәндә өстәлдә ике кешелек җыйнак чәй табыны корылган иде. Гүзәлнең тамагы бик кипкән идеме, дулкынлану-борчылу галәмәте булдымы, Розалия тәкъдим иткән чәйне йотлыгып-йотлыгып эчеп куйды. Ни конфетка, ни печеньеларга кагылмады. Үзе өзелеп-өзелеп:

– Рузалия, Рузалия! – дип кабатлады. – Ничекләр генә бәхилләтеп бетерербез сине?!

– Гүзәл! Улың исән! Бу инде минем өчен иң зур бәхиллек!

– Аллага шөкер! Инде монысын да алса...

Ана кешенең өзелеп әйткән сүзләреннән Розалия сискәнеп китте. Монысын да?..

– И Рузалия! Танымаганыңа гаҗәпләнмим. Танырлыкмыни! Бала хәсрәте бетерде мине! Белсәң!.. Олы улыбыз... Рамилебез Чечняда... Шулкадәрләр дә йомшак күңелле бала иде... «Әни!» дип өзелеп тора иде.

Гүзәлнең сүзләре Розалиянең йөрәген кисеп төшкәндәй булды. Бер мизгелдә күз алдында инде томаннар артында калган таулар тибрәлеп алды. Вакытсыз һәм урынсыз баш калкытырга иткән хатирәләрне күңеленнән куарга маташкан арада Гүзәлнең ниләр сөйләгәнен ишетми дә калды ул.

– ...коткаручы! Улыбызны гына түгел, безне дә коткардың син! Бусын да күтәрә алмас идем!.. Карап торган бердәнбер бит...

Розалиянең кинәт үзгәреп, күз алдында кырыслanып киткән йөзен күреп, сүзеннән туктап калды Гүзәл. Артык сөйләнәм бугай дип уйлап алды. Шундый зур дәрәҗәләргә ирешкән, үзенең түгәрәк дөньясында яшәгән кешенең балачактагы бер танышының тормышында ни эше? Язмыш аларны табиб һәм авыруның әнисе рәвешендә генә яңадан очраштырды. Ә ул... әрсезләнеп...

– Улыгыз... Чечняда кайчан?..

– Туксан тугызда... 1999 елның көзендә.

Икесен дә авыр тынлык басты. Тынлыктан котылу өчен, Розалия суына башлаган чәен йотып куйды.

– Кайнар чәй китертимме?

– Юк, юк, рәхмәт!

Розалия Гүзәлне улы янына үзе алып керергә ниятләгән иде. Инде ул уеннан кайтты. Кул сәгатенә күз ташлап алды да:

– Гүзәл, сине хәзер улың янына озатырлар, – диде. – Озакка түгел. Биш кенә минутка, яме. Елама, улың янында елама. Аны сөйләштерергә азапланма. Ышанычлы, өметле сүзләр генә әйт.

Гүзәл урыныннан сикереп торды. Ишеккә атлады. Күзләренә яшь бәреп чыккан иде инде. Аны Розалиягә күрсәтмәскә тырышты. Еларга ярамый, ди бит.

– Ашыкма, – диде Розалия. Телефоннан кемнедер чакырды. Озак та үтми ишектә ак халатлы яшь кенә кыз күренде.

Гүзәл чыгып киткәч, Розалия үзе дә аңламастан бүлмә ишеген бикләп куйды. Онытырга теләгән хатирәләренә ишекне ябарга маташу идеме бу? Тик хәтер ишеген алай гына бикләп булмый шул! Иртән кояш күтәрелгәч тә аксыл томан эченнән калкып чыккан таулар кебек, офыклар артында калган хатирәләр бөтен җетелеге белән күз алдына килде дә басты.

Икенче Чечня сугышының башланган көннәре иде ул. Розалия махсус билгеләнгән медицина отрядында Чечняга җибәрелде. Аргун тарлавыгында разведка отрядының һөҗүмгә дучар булуы, подполковник дәрәҗәсендәге командирның да яралануы турында хәбәр алдылар. Ул тирәдән боевикларны кысрыклап чыгарганнар, тик озакка булмас, яңадан кайтасылары көн кебек анык иде. Итум-Кали–Шатали юлы алар өчен стратегик кыйммәткә ия юл, аны җиңел генә бирмәячәкләр. Ашыгырга кирәк. МИ-8 санитар вертолеты тиз арада һавага күтәрелде. Төп бурыч – подполковникны табып, эвакуацияләргә! Вакыт бик чикле, тиз эш итәргә кирәк иде. Вертолетның шассилары җиргә тию белән коткаручы бригада җиргә сикерде, тигезле-тигезсез ташлы җир өстеннән төрлесе төрле якка таралып, командирны эзли башладылар. Розалия дә җирдә яткан солдатларның әле берсе, әле икенчесе янына килде. Тик аларга инде табиб ярдәме кирәк түгел иде... Үзенә кемнеңдер якынлашканын тоепмы, берсе кыймылдап куйды. Исән! Корсак турысыннан кысып тоткан ике кулы кып-кызыл...

– Әни-и-и!

Әллә өстенә иелгән Розалиягә әйтә, әллә саташып пышылдый иде яралы солдат. Татар егете! Хәзер, хәзер... Әмма Розалия солдатка ярдәм итәргә өлгермәде. «Монда, монда килегез! Тизрәк!» – дип, яралы подполковник янына җилтерәттеләр. Ул арада: «Время истекло. Немедленно покиньте позицию!» – дигән приказ килде. Командирны алып, барысы да вертолетка чабышты.

– Солдат! – диде Розалия ачыргаланып. – Ул исән!

– Вакыт юк! Күтәрелергә! – Артык тоткарланырга ярамаганлыгын, бирегә барысына да үлем куркынычы янаганын аңлый Розалия. Тик солдатны алырга иде...Вертолет, «пәри өермәсе» куптарып, җирдән аерылды...

– ...Коткаручы!

Хәтердәге таулар арасындагы тарлавыкта Гүзәлнең тавышы таралып киткәндәй тоелды.


– Коткаручы...


Рәсем: Наталья Васильева

МӘСКӘҮДӘ БАР ТАТАР «ЧИШМӘ»СЕ



Һәр күзәнәгең белән татар булыр өчен Татарстанда яшәү мөһим түгел. Моның өчен хәтта Татарстанда туарга да кирәкми. Бары үз халкыңны чиксез яратырга, үз милләтең өчен көчеңне кызганмаска гына кирәк. Мәскәүдә яшәп иҗат итүче һәвәскәр композитор Рифкат АСИКОВ – әнә шундый фидакарь җаннарның берсе.



Лилия ГӘРӘЕВА

Булачак композитор Мордва Республикасының Татар Умысы авылында туа. Җиде балалы гаиләдә барысы да татарча сөйләшә. Мәктәптә хәтта туган тел дә укытыла. Сүз уңаеннан, Рифкатнең иң яраткан дәресе була татар теле дәресләре. «Авыл халкының 99 проценты ул чакта татарча сөйләшә иде әле. Без чын татар мохитендә үстек», – дип искә ала композитор бу хакта.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, әтисе Али агадан җырлау сәләтен откан Рифкаткә укытучысы Саранскидагы Леонтий Кирюков исемендәге музыка училищесына барырга киңәш итә. Аксыл бөдрә чәчле, мәһабәт гәүдәле егетне, бернинди музыкаль белеме булмаса да, хор белән дирижерлык итү бүлегенә кабул итәләр. Биш ел тиз үтә. Казан консерваториясе доценты Ирина Тихонова аны үзләренә укырга чакыра.

Хыял бишеге – Казан! Радиодан тавышларын гына ишетеп белгән җырчыларның үзләрен күрү, китаплардан шигырьләре генә таныш шагыйрьләр белән аралашу, музыка дөньясында кайнау аның иҗади нигезен – нык, күңел офыкларын чиксез-кырыйсыз итә. Атаклы композитор Рөстәм Яхин белән бер елларда укый алар. Бу аның иҗатында да чагылыш таба, әлбәттә.

«Аның әсәрләре көйле, нечкә, нәфис, җете образлы һәм профессиональ яктан җитлеккән булулары белән күңелгә кереп кала. Бу – композиторның бик җитди,

уйлап эш итүе, сүзләргә һәм язылган көйләренә таләпчән булуы нәтиҗәсе», – дип яза Рифкат Асиков турында композитор Риф Гатауллин.

Казан консерваториясенең хор белән дирижерлык итү бүлеген тәмамлаган белгеч кабат туган ягына юл тота.

Казан – иңнәренә канатлар куйган кала булса, Мәскәү иҗат күгендә канат ярып очарга мөмкинлекләр тудыра.

1986 елда Мәскәүнең «Яуза» мәдәният сараенда «Чишмә» үзешчәннәр ансамбле оештыра ул. Чишмә сүзен төрлечә аңларга була – сусауны басучы салкын сулы кизләү дә ул, зур дәрьяларның юл башы да, рухларны баетучы илһам чыганагы да... Мәскәүдә юл алган «Чишмә» дә башкаладагы милләттәшләребезнең милли сәнгатькә булган сусавын гына басып калмый, композиторның үз иҗатын баетучы мул сулы кизләүгә дә әверелә.

Татарстан Композиторлар берлеге әгъзасы Рифкат Асиковның җырларын барласаң, йөздән артадыр. 2004 елда Казанда «Моң дәрьясы» дип аталган җыентыгы дөнья күрә. Аны академик җырлар, романсларга якын җырлар иҗат итүче дияргә була. Композиторның Роберт Миңнуллин («Әллүки», «Әнкәйләр», «Ялгыз каен», «Таулар»), Резеда Вәлиева («Китмәгез, тургайлар», «Сандугач булсам иде»), Нажар Нәҗми («Туган моңнар»), Рәшит Әхмәтҗанов («Карлыгач»), Флёра Тарханова һәм башка күп кенә язучыларыбыз шигырьләренә язылган җырлары Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева, Зилә Сөнгатуллина, Миңгол Галиев, Флера Сөләйманова, Зөһрә Шәрифуллиналар репертуарында яңгырый.

– Рифкат белән электән үк гел аралашып яшәдек, – ди Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиева. – Репертуарымда аның берничә җыры бар. Рифкат нечкә күңелле, игелекле, бик ярдәмчел кеше. Ул көтә белә. Кайчак җыр тусын өчен еллар кирәк. Роберт Миңнуллин сүзләренә язган «Әнкәйләр» җыры да үз сәгатен шактый озак көтте. Мөнәҗәт стилендә язылган бу җырны яратып башкарам. Рифкатнең үзенчәлеге шунда – ул җырчының үз фантазиясенә дә урын калдыра. Җырны баета икән, җырчының интерпретацияләренә каршы килми. Төрле стильләрдә – киң диапазонлы романс стилендә дә, халыкчан җырлар да, эстрада әсәрләре дә иҗат итте. «Чишмә» ансамбле аша халыкка күрсәткән хезмәте дә бик зур булды. Нинди зур, көчле коллектив туплый алды. Мәскәүдә татар җырчыларының, язучыларының иҗат кичәләрен үткәрде. Казаннан кунаклар чакыра иде. Мәскәү татарлары бу кичәләрне көтеп алды. Мәскәүдән торып, татар халкы өчен никадәр эш башкарды ул.

Рифкат Асиков музыкант кына түгел, белеме буенча ул медик та. Язмыш аңа иң игелекле ике вазыйфа йөкләгән. Рифкат кебек, кешеләрнең тәнен дә, җанын да берьюлы дәвалаучылар сирәк. Менә шул сирәкләрнең берсе – ул.



Казандагы очрашулар. Сулдан-уңга: Рифкат Асиков, Флера Сөләйманова, Резеда Вәлиева.



Истәлекле мизгелләр. Сулдан-уңга: Рифкат Асиков, Илһам Шакиров, Рафаэль Ильясов, Рөстәм Вәлиев, композиторның улы Илдар.



Әлфия Афзалова белән Мәскәү Сабан туенда.



Иң бәхетле көннәрнең берсе – хатыны Талия белән никахлашу көне. Мәскәү. 1992 ел, 18 апрель.

Фотолар: гаилә архивыннан



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Яшьтәш

1989 елның 15 феврале – Әфганстаннан совет гаскәрләре тулысынча чыгарылган көн. Бу сугыш безнең гаиләгә дә хәсрәт китерә. Әбием Бибигөлнең улы Дамир Вафинның гәүдәсен цинк табутта кайтаралар. Аңа нибары 19 яшь була.

Әбием үзе 1930 елны Балтач районының Янгул авылында туа. Әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак була. Тылдагыларның исә бу елларданиләр кичергәнен кешелек белә инде – авыр хезмәт, коточкыч салымнар. Әбием бары 3 класс кына белем алырга өлгерә, 12 яшеннән аны укытучылар гаиләсенә бала карауччы итеп бирәләр. Куанып алып кайткан беренче хезмәт хакын әнисе иртәгәсен үк салым өчен илтеп түли.

Сугыш тәмамлана. Ләкин көткән җиңел тормыш тиз генә килми әле. 1954 елны Куйбышев сусаклагычы төзелә башлый. Бик күп авылларның су астында каласы билгеле була. Халыкны башка җирләргә күчерәләр, яңа авыллар төзелә. Әбиемне дә Лаеш районы Атабай авылына урман кисәргә җибәрәләр. Шунда ул үзенең булачак ирен – Миңнулланы очрата. Өйләнешәләр, бер-бер артлы өч уллары, бер кызлары туа. Балалар үсә, тормыш дәвам итә.

1982 елның язында әби-бабам төпчек уллары Дамирны армиягә озата. Бер авылдан өч егет – өч классташ китәләр. Казан военкоматында егетләрнең Әфганстанда хезмәт итәсе билгеле була. Дамирдан хатлар гел килеп тора. Бер генә зарлану сүзе дә юк аларда, бары сагыну, ярату, кайгырту...

Ә өч айдан – 1982 елның 5 июлендә Дамир һәлак була. Әбиемнең зәңгәрсу-яшькелт күзләрендә хәсрәт уты кабына. Белмим, бу кайгыны җиңәр көчне кайдан алды икән ул? Бөтен хәсрәтен, кайгыларын салып, улына багышлап бәет яза әбием. Ә Дамирны вафатыннан соң Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр, авыл урамына аның исеме бирелә. «Үлгәч тә мине кайгырта бит улым», – дип, моңсу елмая иде әбием улы өчен пенсиягә өстәмә алгач.

Бу хәсрәт әле башы гына була, 90 нчы елларда тагын ике улын һәм ирен дә югалта әбием. Кызы белән икесе генә яшәп калалар. Шулай да яшәүдән бизмәде ул: «Минем әле өч улым һәм ирем өчен дә яшисем бар», – ди иде. Кемгә генә эндәшсә дә, аның өчен бары ике генә исем: «Дамир-Миңнулла». Авылдашлары аның бу гадәтенә күнекте, гаеп итмәделәр.

Пенсиягә чыккач, әбием догалар өйрәнде, Коръән укыды. Бераздан аның тагын бер сәләте ачылды – ул сеңерләр тартылганын, бәрелгән-сугылган урыннарны тоя һәм дәвалый белә башлады. Бу хакта беркемгә дә сөйләмәде, ләкин кешеләр белеп алып, дәвага киләләр иде.

Әбием 87 яшенә кадәр яшәде. Соңгы көненә кадәр үз хуҗалыгын үзе карады. Аны озатырга бөтен авыл килде. Кызганыч, аның үзе чыгарып җырлаган такмакларын язып ала белмәгәнбез. Кешелек кичергән фаҗиганең бер шаһиты булып «Дамир улыма» дигән бәете калды. 1982 елның 10 июлендә язылган ул.

Әни, бәгърем, йөргән идең
Мин үскәнгә куанып,
Үле гәүдәмне күреп,
Әни, үлмә капланып.
Мин укырга китә идем
Иртән сәгать җидедән.
Унсигез яшь тулуга
Чыгып киттем илемнән.
Кара матур чәчләремне
Тарадым, үрә алмадым.
Улым, гәүдәләрең кайтты,
Йөзеңне күрә алмадым.
Әни, бәгърем, сезнең белән
Мин туйганчы тормадым.
Армиягә киткән чакта
Кайтырмын дип уйладым.
Әни, сиңа хатлар яздым,
Менә бер ай булды дип.
Әни, бәгърем, уйламадым
Җаным монда чыгар дип.
Атлар килә атлап-атлап,
Атлар килә адымлап.
Хәсрәтләрем күлмәк булса,
Юар идем сабынлап.
Яз көннәре җиткәчтен,
Кыр казлары кайтырлар.
Синең балаң шәһит, дип,
Мине дә юатырлар.
Тәрәз төбем тулы гөл,
Кышлый торган гөлләр бар.
Сагынганда карар идем,

Фото: Анна Арахамия

Сиңа охшаган кемнәр бар?
Улым, бәгърем, хат язгансың,
Энҗеләр күк тезгәнсең.
Гомеремнең буйларына
Үзәгемне өзәсең.
Солдатлар яшел киенә –
Чирәмнән күренмәскә,
Булдым бер кайгылы ана
Гомергә сүрелмәскә.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ.
Казан шәһәре.

Ир баланы сөннәтләү – шәригать кануны. Сәламәтлек өчен дә кирәк ул, чисталык, пөхтәлек билгесе дә булып тора. Халкыбыз әлеге йоланы гомергомергә үтәргә тырышкан.

Үзем эшләгән оешманың директоры, су коенырга баргач, бер гыйбрәтле хәл сөйләгән иде.

Аның әтисе район партия комитетының беренче секретаре була. Улын сөннәткә утыркан дип, өлкә партия комитетына өстеннән шикаять язалар. Әнисе, әтиләренә нахак гаеп ягуларын раслау өчен, улын җитәкләп район партия комитетына алып бара.

Казанга укырга килгәч, бер татар кызы белән таныша бу егет. Ничектер сүз чыгып, авылда булган теге хәл турында да сөйли. Кыз бик гаҗәпләнә һәм алга таба араларны өзәргә кирәген әйтә. Шуннан ул хастаханәгә үзе барып, сөннәт ясатып кайта. Теге кыз белән аралары кабат җайланып, никах укыталар.

Үземнең туган ягым Апас районында да сөннәт белән бәйле бер гыйбрәтле хәл булганын беләм. 1945 елны район советы башкарма комитеты рәисенең хатыны өйгә бабай чакыртып, 2 яшьлек улын сөннәткә утырта. Әлеге факт 1952 елны калкып чыгып, аны хәтта «Крокодил» журналына да язалар. Малайның әтисенә шелтә белдерелә, дини хорафатларга ышанган өчен, дип, эшеннән үк алалар.

Хәзер нинди милләттән, диннән булуга карамастан, табиблар сөннәтләүнең кирәклеге турында сөйли. Хатыным да 15 ел Казандагы бер хастаханәдә хирургия бүлеге мөдире булып эшләде. Җенес органнарында тайпылышлар булган малайларга операция ясыйлар иде. Алар өстеннән дә шикаять язучылар булды. Министрлыкка чакыргач, хатыным: «Ярар, моннан соң андый пациентларны сездән рөхсәт алырга җибәрербез», – дип җавап биргән. «Монда җибәрмәгез, диагноз таләп итсә, урында хәл итегез», – дигәннәр министрлыктагылар.

Шөкер, хәзер мондый тыюлар, каршылыклар юк. Динебез кушкан йолаларны үтәр өчен ирек.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ.
Казан шәһәре.



Язмыш җилләренә бирешмичә, гәүдәсен төз тотып, салмак адымнар белән сукмактан укытучы килә. Ул нидер уйлана. Үз укучыларының язмышы турында уйлый микән, әллә үзенең сикәлтәле тормыш сукмаклары турында уйга калганмы? Уйланырлык әйберләр күп икән шул...

Нәфисә Вәлиевна – гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган кеше. Үзенә кыен вакытта да яшь аралаш елмая белгән, башкаларга җан җылысын кызганмаган укытучы ул.

Чуашстанның Батыр районы, Шыгырдан авылында дөньяга килә. Малайлардан соң көтеп алган кызга Нәфисә дип исем кушалар. Бу авыл бүген дә Батыр районында иң бай, иң зур татар авылы дисәм, ялгыш булмас. Авылда җиде мәчет кенә бар... Яңа мәктәп эшли. Болар барысы да бу халыкның никадәр тырыш, уңган булуын сөйли.

Мәктәпне тәмамлагач, Нәфисә Канаш педагогика колледжында белем алып, Татар Тимәше авылында башлангыч класста укыта. Авыл халкы бик яратып кабул итә укытучы кызны. Насыйп ярын да шушында очрата – Рәмис белән кавышып, яшь гаилә Казанга юл тота. Яшәргә фатирлары юклык та юлларына киртә була алмый, бергә булганда авырлыклар да куркытмый. Уллары Азат туа. Гаилә башлыгын Казан милли мәдәният үзәгенең директор урынбасары итеп билгелиләр. Бераздан дөньяга икенче уллары Ирек аваз сала. Шатлыкларының чиге булмас кебек тә бит... Ирек авыру булып туа. Кая гына алып бармыйлар, ничә операция ясаталар... Ниләр кичергәнен әни кеше үзе генә беләдер.

Сынауларга бирешми алар. Яңа фатир алалар. Инде шатланып яшәрбез дисәләр... Эштән соң кайтып ял итәргә генә ята Рәмис. Ни булганын да белми кала Нәфисә. Ашыгыч ярдәм килгәндә соң була инде: Рәмис мәңгелеккә күзләрен йома. Алга таба ничек яшәргә? Олы улларына – 12, кечкенәсенә 8 яшь, өстәвенә, авыру.

Сыңар канаты белән яңача яшәргә өйрәнергә туры килә Нәфисәгә. Ике баланы үстерергә кирәк. Иренең туганнарына рәхмәт, гел ярдәм итеп торалар. Улларына төпле тәрбия бирә ул. Азат бию түгәрәгенә йөри, Банк мәктәбен тәмамлый. Ирек музыка мәктәбендә укый, класстагы иң алдынгы укучыларның берсе, аның фикерләү сәләтенә шаккатарлык.


Нинди генә авырлыкларга очраса да, Нәфисә үзенең күңел көрлеген, шаянлыгын югалтмый. Матур итеп җырлый. Бәйрәмнәр җитсә, түгәрәк табынга туганнарын җыя. Иренең туганнары белән элемтәләрне бер дә өзми. Кайнанасы өчен ул әле дә «кызым».

Киләчәктә дә күңел күтәренкелеген югалтмыйча кешеләргә шатлык өләшеп, туганнарына, балаларына терәк булып яшәргә язсын Нәфисә ханымга.

Рузилә КӘРИМОВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

СЫҢАР АЛКАЛАР





Фәгыйлә
ШАКИРОВА

Моннан шактый еллар элек Казандагы бер хастаханәнең травматология бүлегендә ятарга туры килгән иде миңа. Урыным алты кешелек зур, якты палатага туры килде. Күршеләрем дә үзем кебек татар хатыннары: кем Мамадыштан, кем Азнакайдан... Берсе егылган, икенчесе аварияга очраган, өченчесе... Тормыш шундый бит ул: үзеңне уйламыйча, дөнья куам дип чабасың-чабасың да, берзаман, Аллаһ әмере буенча, сәламәтлегеңә зыян килә – урынга ятарга мәҗбүр буласың. Эштән кайтып кермәгән кеше өчен вакыт кинәт туктый. Күз алдыңнан экрандагы кебек гомер юлың үтә, яшәүнең мәгънәсе турында фәлсәфи уйларга чумасың. Мондый чакта бөтенесе дә кабаттан Аллаһка ышана башлый. Өйләреннән дога китаплары китертә, исәнлек сорап Ходайга ялвара. Операция алдыннан исә татары да, урысы да үзе белгән догаларны укый, нәзер әйтә...

Палатадашларымның үзара татарча сөйләшүләренә шатланып бетә алмадым. Процедуралардан соң дөнья хәлләре турында сөйләшәбез, туганнарыбыз алып килгән күчтәнәчләр белән чәй эчәбез. Күрше караватта ятучы 87 яшьлек Асия әби белән аеруча якынайдым (*язмадагы барлык исемнәр дә үзгәртелде. – Ф. Ш.*). Күзләреннән нур чәчеп торучы ак яулыклы бу әбинең ике аягына да операция ясадылар. Чаллыдан кызы килеп, яныннан китмичә, өч көн буе саклап утырды. Мин беренче көнне үк Асия апаның колагындагы алкаларына игътибар иттем. Ике колагына ике төрле алка таккан иде ул. «Олы кеше бит, ялгышкандыр», – дип уйладым.

Операциягә керер алдыннан санитарка Асия әбигә алкаларын салырга кушты. Әби исә: «Салмыйм, бирмим», – дип, кытыршы куллары белән колакларын каплады. Без дә кечкенә бала кебек киреләнгән әбине тынычландырырга ашыктык. Тик күпме генә күндерергә тырышсак та, әби ишетергә дә теләмәде. Хәтта елый ук башлады. Тәки үзенекен итте – алкаларны салмады.

Алкаларын наркоз биргәч кенә салдырганнар – хирургларны да тыңламаган. Уянып, аңына килүгә үк колагын капшаган. «Алкаларымны урлаганнар!» – иң беренче сүзе шул булган. Пакетка салынган алкалар-

ны кулына китереп тоттыргач кына тынычланган. Нигә бу кадәр кадерле икән соң аңа әлеге алкалар? Инде моның серен беләсе килә иде. Күрше әбием операциядән соң бераз көч җыйгач, сөйләттем мин аны. Тик башта аның хастаханәгә эләгү тарихына тукталыйм. Шактый сәер ул.

Биш вакыт намазын калдырмаучы Асия әби җәйге җылы кичләрнең берсендә, ахшам намазыннан соң, ачык верандада урындыкка утырып көйли-көйли Коръән укыган җиреннән егылып аякларын сындыра. «Утырган җиремнән ниндидер көч ике-өч метрга алып ыргытты, – диде ул. – Өйдә дә, ишегалдында да беркем юк иде. Давыл түгел, җилсез дә кич иде. Шайтан үзе булгандыр, балакаем. Коръәнем бер якка очкан, үзем ишегалдында аңыма килдем. Егылган җиремнән тора алмыйча бер сәгатьләп ятканмын. Ярый улым кайтып керде. Төне буе сызланып чыккач, икенче көнне ашыгыч ярдәм машинасы белән районга алып киттеләрр. Аннары менә монда операциягә килеп эләктем. Аллаһының зур сынавы бу, кызым, хәерле булсын...»

Асия апа сөйләгәннәрне шаккатып тыңладым.

...Ирен сугышка озатканда аңа 20 яшь тә тулмаган була әле. Беренче баласына авырлы, өйдә 70 яшьлек кайнанасы да бар. Таңнан торып эшкә китәләр, кояш баегач кына кайталар. Баласын да кырда, ашлык урганда таба... Көндез иген уралар, төннәрен шәм яктысында оекбаш бәйлиләр. Кайнанасы «Тәфтиләү»не җырлый-җырлый җеп эрли, бер аягы белән бишектә яткан оныгы Габдерәхимне тирбәтә. Күздә – яшь, күңелдә сагыну... Керосин лампасының яктысы чагылмасын дип, авыл халкы тәрәзәләрне авыр япмалар белән каплый. «Авыл өстеннән очып узган самолетлар күрмәсен өчен шулай эшли идек, – ди Асия апа. – Адашып, дошман самолетлары килеп чыгар да, бомба яудырыр дип курка идек. И-и заманалар... Ирем Габдулладан хат килгән көнне бөтен авыл халкы аны укырга килә. Шундый гадәт бар иде. Таягына таянып, аргы очтан хәтта Маһриҗан әби дә менә. Дүрт улын фронтка озаткан иде ул. Инде икесенә кара кәгазь килгән. «Асия, кызым, ирең улларымны күрмәгәнме, алар белән сөйләшмәгәнме?» – дип сорый, ә үзенең ике күзеннән дә яшь ага...»

Ил өстенә килгән кайгы бер хәл: дүрт ай тулыр-тулмас Асиянең улы кызамыктан вафат була. Бу хәлдән соң кайнанасы Гөлчирә абыстай акылын югалта яза. Буш калган бишекне матчадан алдырмый – мендәргә утын пүләнен салып тирбәтә башлый. Үзе елый, үзе җырлый:

Безнең авыл зур авыл,
Килә кыйбладан давыл.
Алдагысын белеп булмый,
Их, хәзергесе бик авыр...

Алар авылы тимер юл станциясеннән ерак урнашмаган. Ара-тирә поездлар узып киткән тавышлар ишетелеп тора. Асиянең ирен дә шушы станциядән сугышка озаталар. Әле җитмәсә, гармунын да кыстырып китә Габдулласы. Киткәндә җырлаган җыры аның йөрәгендә һаман саклана.

Әнисе тарафыннан ташланган сабыйга Асия үзенең барлык назын, мәхәббәтен бирде...

Беркөнне Асия, сугыштагы ирен, сабый килеш бакыйлыкка күчкән Габдерәхимен уйлый-уйлый, тимер юл станциясе ягындагы урман юлыннан өенә кайтып бара. Шул вакыт аның колагына бала елаган тавыш ишетелгәндәй була. Чү! Габдерәхиме елый бит! Ашыйсы килгәндер – бигрәк өзгәләнә. Хатын шашынып, тавыш килгән урман куелыгына атлый. Башында мең төрле уй. Аннан кинәт туктап кала: «Син кая барасың?! Балаң үлде, үз кулларың белән җирләдең ләбаса. Үзең кабер казып ләхеткә салдың!»

Асия, барган җиреннән туктап, агачка сөялә: «Йа Аллам, акылдан шашам бугай!..»

Ә чытырманлык эчендә яшь бала елый да елый. Асия билдән югары булып үскән үләннәрне ера-ера тагын тавыш килгән якка атлый. Агач астында ак чүпрәккә төргән күкрәк баласын күреп туктап кала. Якынрак килеп, баланы төргән чүпрәкне ачып җибәрә. Йа Ходаем! Ай ярым чамасындагы зәп-зәңгәр күзле бала! Йөзе, куллары тире авыруыннан кып-кызыл булып кутырлаган. Бер мизгелдә аналык инстинкты уянып, баланы ничек күтәреп алып, кочагына кысуын сизми дә кала Асия. «Хәзер, хәзер, балакаем, өйгә генә кайтыйк, ашатырмын, юындырырмын», – дип кабатлый ул.

Урман юлыннан табып кайткан балага Мәрьям дип исем кушалар. Сабыйның тәне кутырдан гына тора, кычыткангадыр, көн-төн елый. Асия баланы көнгә ике тапкыр канлы үлән салынган төнәтмәдә коендыра. Тәненә авыл фельдшеры биргән мазьны сөртеп урап яткыра. Ходай рәхмәте, бер атнадан баланың тәнендәге кутырлары коела башлый, аның урынына алсу тире барлыкка килә. Бәхете була сабыйның: Асияләрнең кәҗәләре карт булса да, сөтне күп бирә. Шул кәҗә сөтенең дә файдасы тигәндер, Мәрьям тиз арада тернәкләнә. Зәп-зәңгәр күзләре белән Асиягә тутырып карый, елмая, аңа нәни кулларын суза башлый.

Ташландык бала табып кайтуны зур вакыйга итеп кабул итми авыл халкы – берәүдә дә кеше кайгысы юк чаклар бит.

Сугыш башланып дүрт ел узгач, Асиягә кара кәгазь килә. Акылы җиңеләйгән кайнанасы, 4 яшьлек Мәрьяме белән торып кала ул.

Ниһаять, сугыш та тәмамлана. Авылга берән-сәрән ирләр кайта башлый. Кемдер кулсыз, кемдер аяксыз... Төскә-биткә чибәр Асиягә яучы килә: фронтовик Заһидка димлиләр аны. Асиянең икенче ире кырыс, сүзгә саран була. Колхозда каравылчы булып эшли. Әмма кырыс булса да, Асиягә, зиһенен җуйган

Сынауларның иң зурысы – кадерләп үстергән баланың башка хатынга ияреп китеп баруыдыр...

Гөлчирә карчыкка, кечкенә Мәрьямгә сүз әйтми, кул күтәрми.

Мәрьям авыл балаларыннан аерылып тора: күзләре, әйткәнемчә, зәңгәр, чәче аксыл була. Татар баласы түгел инде... Бик чая булып үсә кыз, мәктәптә дә яхшы укый, 10 яшьләрдә инде камыр ризыклары да пешерә, бәйләм дә бәйли. Табылдык бала булуын аннан беркайчан яшермиләр.

«Ирле йорт – көйле йорт», диләр халыкта. Кулына балта тота белгән Заһид иң беренче чиратта йорт-җирне рәткә китерә, каралты-кураларны яңарта. Бер-бер артлы биш балалары туа. Шулай яшәп ятканда гаиләгә тагын бер зур сынау килә.

Көннәрдән бер көнне Заһид өйгә аты белән кайтып керә дә, кабалана-кабалана капка келәсен төшерә. Асия үз күзләренә үзе ышанмый: ат арбасындагы печән астында ике капчык ята. Туп-тулылар – авызлары бау белән бәйләнгән. Хатынның йөрәге «жу» итеп куя. Ике уч бодай өчен Себер китә торган заманалар бит. Ләкин иренә бер сүз дә әйтә алмый – барыбер үзенекен итәчәк. Ир капчыкларны җәһәт кенә лапас башына алып менгереп яшерә. Асиянең эченә борчу оялый: «Хәерлегә булмас бу...»

Кичке эңгер-меңгердә өйгә күршеләре – авыл советында эшләүче Рәбига килеп керә.

– Ирең кайда? – дип сорый ул, бусагага атлап узмас борын.

– Каравылда. Нәрсә булды? – ди Асия.

– Амбардан ашлык югалган, иртәгә сезгә тентү киләчәк, – ди күршесе.

Кара төндә ике кара шәүләнең капчыклар өстерәп бакча артындагы инешкә таба юнәлүенә бары күктәге ай гына шаһит була. Ике ахирәт, тубыктан суда килеш, тирән чокыр казыйлар. Ашлык төялгән капчыкларны, брезентка урап, чокырга урнаштырып бетергәндә, сызылып таң ата башлаган була инде. Асия төнге хәлләрне иренә әйтми.

Икенче көнне Асияләр йорты каршына кара машина килеп туктый. Машинадан погонлы дүрт ир чыгып, икесе өйгә керә, икесе туп-туры абзарга юнәлә. Заһидның йөзе ап-ак төскә керә... Лапас түбәсендәге печәнне җиргә төшерәләр, ләкин күпме генә эзләсәләр дә, берни таба алмыйлар. Асия шулай ирен зинданнан саклап кала...

Кырыс ирнең йөрәге генә йомшармый: бергә торган дәвердә хатын аннан рәхмәт ишетми. Сугыш Заһидның йөрәген дә, күңелен дә шактый кырыслаткан була шул. Ә инеш ярына яшерелгән ашлык ишле гаиләгә кыш чыгарга ярап куя.

Көн артыннан көн уза, айларны еллар алыштыра. Мәрьямгә 16 яшь булганда, авылга көтелмәгән юлчылар килеп чыга. Алар туп-туры Асияләр яшәгән йорт янына килеп туктыйлар. Машинадан сапсары чәчле, яхшы гына киенгән 50 яшьләрдәге хатын чыга.

Асия бер караудa аңлый: аңарда Мәрьям чалымнары. Әнисе эзләп килгән, дигән уй яшен тизлегендә баштан узды. Инде ни булыр?! Хатын үзен Светлана дип таныштыра. Асия чакырылмый килгән кунакларны чәй табыны янына чакыра.

Светлана күз яшьләре белән 16 ел элек булган вакыйгаларны сөйли. «Кызымны үлсен дип ташламадым, башка чарам юк иде... Сезнең аны алып киткәнегезне күреп тордым. Шуңа күрә исәнлегенә беркайчан шикләнмәдем – килеп алырга хыялландым», – дип, кат-кат кабатлый ул. Светлананың бүгенге тормышы инде җитеш: ире, тагын ике баласы бар икән.

Әнисен җылы кабул итә Мәрьям. Нишләтәсең, җан тартмаса – кан тарта, димәк... Тәмле телле хатынның сөйләгәннәрен тын да алмый тыңлап утыра ул. Бу минутларда сугыш чоры баласының күңелендә нинди хисләр, нинди уйлар кайнагандыр, караңгы...

Үзен дөньяга тудырган әнисенә ияреп китәргә җыенган Мәрьямне кочаклап, күз яшьләрен тыя алмый озак елый Асия. «Кызым, тормышта нәрсә генә булса да, мин синең әниең, ә бу йорт – синең туган йортың. Кайчан телисең, шул вакытта кайт, балам! Без сине көтәбез, яратабыз!» – ди.

– Мәрьям безне ташламады, – дип сөйләде Асия әби. – Күчтәнәчен, бүләген төяп кайта гел. Чаллыда яши, үз гаиләсе, ике баласы бар... Син аны күрдең инде – операциядән соң мине ул саклады.

Асия әбине хастаханәдән уллары, киленнәре каршы алды. Без аны матур теләкләр теләп озаттык. Киткәндә колакларында һаман шул ике төрле алка иде. Бу алкаларның үз тарихы бар булып чыкты.

– Бер пар алкамны вафат булган улым Камил бүләк иткән иде, – дип сөйләде ул. – Сыңары бакчада бәрәңге утыртканда колагымнан төшеп калды: туфрак арасыннан күпме эзләсәк тә, таба алмадык. Икенче улым Салих та туган көнемә алтын алка алып кайтты. Аларын ярты ел гына тагып йөрергә өлгердем. Гөнаһ шомлыгы димме, бер сыңары юкка чыкты. Салих үзе дә дөньяда юк инде, балакаем... Шуннан соң балаларга бүтән алка алмаска куштым. Бу ике парсыз алка – минем өчен иң кадерле хатирә. Вафат булган улларымның төсе итеп тагам...

Асия әбине бик еш искә төшерәм. Исән дә түгелдер инде ул... Яңа яуган карга карап, ак яулыклы Асия әбине күз алдыма китерәм. Бу язмам сугыш афәтен татыган әби-апаларның рухына дога булып ирешсен...

ЛАЕКЛЫ АЛМАШ БАР

«Сөембикә» журналы социаль әһәмияткә ия проектларда һәрдаим катнашып килә. Гыйнвар аенда Казанның УНИКС концертлар залында узган «TMTV» музыкаль телеканалы оештырган «БАЛАЛАР ПРЕМИЯ»се бүләкләү тантанасында да журнал мәгълүмати спонсор иде.

«БАЛАЛАР ПРЕМИЯ»се проекты – яшь талантлар арасында уздырылучы беренче музыкаль-телевизион премия. Бу чара кысаларында, туган телдә җырлаучы, татар көйләренә иҗат итүче 16 яшькә кадәрге җырчылар, инструменталь, хореографик коллективлар бүләкләнә.

«TMTV» музыкаль телеканалы берничә ел дәвамында талантлы балаларны барлау юнәлешендә эш алып бара: сәләтле балаларны таба, аларны эфирда күрсәтә, «Балалы Солянка» концертларын оештыра.

Тамашачы тавыш бирү юлы белән җиңүчеләрне сайлаган.

Бәйрәм лауреатларны бүләкләү тантанасыннан башланды: яшь талантлар әти-әниләре, вокал укытучылары, туганнары белән бергә кызыл келәмнән уздылар. Раяна Миңнегалиева әнисе – җырчы Ильвина белән, Зәлия Зиннурова әтисе – шоумен Зөлфәт Зиннуров белән... «Веснушки» вокаль ансамбле кызыл келәм буйлап студия җитәкчесе җырчы Чәчкә белән атлады.

Лауреатларга сыннар, дипломнар, сертификатлар, партнерлардан бүләкләр тапшырылды.

Балаларны игълан иткәндә аларның башка күпсанлы бәйгеләрдә яулаган җиңүләре дә әйтелде. Алар исемнәрен танытып өлгергән инде: араларында халыкара, Россия күләмендә узган бәйгеләрдә җиңү яулаган, гүзәллек конкурсларында катнашкан малайлар-кызлар да бар.

Җәмилә Әсәдуллина, Айза Галиева, Милина Хәйруллина, Азалия Хәйруллина, Раяна Миңнегалиева, «Веснушки» вокал ансамбле, Лерия Гайфетдинова, Раяна Ибәтуллина, Карина Нәбиуллина, Аслан Миргаязов, Амелия Феофанова, Наилә Славина, Азалия Яфясова, Әминә Әхмәтҗанова, Зәлия Зиннурова «БАЛАЛАР ПРЕМИЯ»се лауреатлары булдылар.

Музыкаль премиянең тагын бер үзенчәлеге: кайбер җырчылар үз балалары белән түгел, ә башка талантлы кызлар-малайлар белән бергәләп чыгыш ясады. Тамашачылар сәхнәдә яшь талантлар белән бергә популяр җырчыларны да күрү бәхетенә иреште. Илнар Миранов белән Амелия Феофанова, Филүс Каһиров белән Азалия Яфясова, Иркә белән Аслан Миргаязов дуэтлары көчле алкышларга күмелде. Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова гаиләсенең музыкаль кораллар белән чыгышы беркемне дә битараф калдырмагандыр. Ләйсән Гыймаева кызы Таңсылу белән җырлады. Данир Сабиров чыгыш ясаганда кызы Мәрьям биюче Сергей Казаков белән тамашачыларга биюле номер бүләк итте.

Наилә Славина һәм Гүзәлем башкаруында «Сәйдәш» бию ансамбле белән берлектә яңгыраган «Бас әле» музыкаль номеры тамашачыларның аерым игътибарын җәлеп итте. Салават Миңнеханов бу чыгышта биюче ролендә булды. Әлбәттә, Гүзәлем белән Салават бергәләп тә җырладылар.

Эльмира Кәлимуллина, Ризат Рамазанов, Зәйнәб Ферхетдиновалар да яшь йолдызлар белән матур җырлар яңгыраттылар.

Оештыручылар әйтүенчә, балалар үкчәгә басып килә. Татар эстрадасының киләчәге өметле булуына тамашачылар инанды. Яшь талантларны татар җыр-моңына якынайту юнәлешендә мондый чаралар уздыру дәвам итсә, Илһам Шакиров, Зифа Басыйрова, Әлфия Афзаловаларга лаеклы алмаш килә...

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА 6+



PRESSA



Автор фотолары

ТУНИС БЕЛӘН ОЧРАШУ



Руслан АХУНОВ

Туниска сәяхәтебез гел уйламаган җирдән килеп чыкты. Җәй иде, көтмәгәндә күптәнге бурычны кайтардылар. Инде саубуллаша язган... Нигәдер күктән төшкән акчалар булып тоелды алар безгә. Инде боларны бит хәзер туздырырга кирәк! Хәләл җефетем белән диңгезгә юллама алырга йөгердек. Беренче чиратта арзан булсын дип эзләдек. Төркиядер инде, дибез: таныш та, аңлашырга да уңай. Отельләр сайларга керешкәч, күзгә Тунис чалынып китте: бәясе тагын да арзанрак, кунакханәсенең йолдызлары да күбрәк... Зәлия белән бер-беребезгә карашып куйдык. Тукта, тукта, кайда әле ул? Африкада түгелме соң?! Бу җәһәттән без аның белән икебез дә маҗараларга хирыс. Ә монда Африка!..

Моңа кадәр Туниста булганыбыз юк иде әле. Барган кешеләр, әнә, анда диңгез дә чиста, отель вәгъдә иткәннән дә яхшырак, ашау да хәләл дип яза. Мин акыллы кыяфәттә тартырга чыгып киткән булам: янәсе, уйлыйм әле. Гәрчә Туниска барачагыбыз билгеле инде. Зәлия мине бәхетле елмаеп озатып кала... Әнә шулай 20 минутта хәл иттек, ә тагын ике көннән гаиләбез белән самолетта идек инде. Тәҗрибәле сәяхәтчеләр сәфәргә чыгар алдыннан барасы җирләре турында азмы-күпме белешә, укый, өйрәнә. Башка чакта без дә шулай итә идек. Бу юлы исә вакыт тар – боларның берсенә дә өлгермәдек. «Диңгез Африкада да диңгездер инде ул», – дип юаттык үзебезне.

Менә кайда икән ул ләкләкләр!

Аэропортлары шәп, әйбәт каршы алдылар. Автобусларга утырттылар да отельгә озаттылар. Барганда, юл читләрендәге пычраклык, чүплекләр эчне пошыра башлады. Зәлия белән сүзсез генә карашып алабыз: күреп торам – икебезне дә шик корты кимерә... Әйтерсең лә күзләребезне бәйләп, баскан урында әйләндерделәр-әйләндерделәр дә, дүрт ягыгыз кыйбла дип чыгарып

җибәрделәр. Ялгыштык микәнни? Кая барганыңны белмичә юлга чыгарга ярыймыни?! Һәм шул вакыт электр баганалары башында ләкләк оялары күреп алдык. Багана саен ләкләк! Нindидер гадәти булмаган матурлык... Ни өчендер нәкъ менә шушы күренеш тынычландырды безне. Кошлар оя корган җирдә начар булмас!

Ерактан ук күренә: кунакханәбез зиннәтле булып чыкты. Чемоданнарны ресепшнда гына калдырдык та диңгезгә йөгердек. Ә анда!.. Табан асларын кытыклап, күбек кебек бармак араларына тула торган ап-ак, вак, йомшак ком һәм чип-чиста – үтә күренмәле диңгез. О-hо-hо! Юк, ялгышмаганбыз!

Номерның диңгезгә карап торуын теләгән идек. Безнең өчен ялның бу ягы һәрвакыт мөһим. Тунис монысы белән дә сынатмады. Әйтерсең лә безне генә көткән! Барысы да әкияттәге кебек иде...

...һәм иң күп зәйтүн

Беренче тәэссоратлар сүрелгәч, Тунис белән якыннанрак таныша башладык. Һмм... Танышыр идек тә, биредә, нигездә, французча сөйләшәләр икән бит. XIX гасырда Франция анда үзенең протекторатын урнаштырган булган. Балаларны мәктәптә берьюлы дүрт телгә өйрәтәләр: гарәп (дәүләт теле), француз, инглиз һәм җирле телгә. Бушлай укыталар, мәктәптән соң, акча түләп, башка илләргә укырга җибәрәләр. Кыскасы, биредә мәгърифәтле халык яши. Бу һәр адымда диярлек сизелә (без шәһәргә еш чыгып йөрдек). Аралашканда, әдәп-әхлак саклап сөйләшәләр, юк-бар белән бәйләнмиләр. Акча мәсьәләсендә Тунисны кыйммәтле ил дип булмый. Тунис динарлары безнең акча белән күпме йөргәндер, әмма юрган кадәр сөлгеләрне 150 сумга гына алганны хәтерлим.

Монда күбрәк французлар ял итә икән: Париждан самолет белән бер сәгатьтә килеп җитәләр, хәтта шимбәякшәмбеләрне дә шушында үткәрәләр. Әйтәм аны Төркия белән Мисырда аларны очраткан юк диярлек.

Без дә берничә көн кояш астында – ак комда яттык та (Сахара чүле якын булганга, биредә тән тигез карала һәм озакка җитә, дип аңлаттылар), бу кадәр олы тарихлы илне якыннан күрмичә кайтып китү дөрес булмас дип, сәяхәтләргә кузгалдык. Зәйтүн маен ярата торган кеше буларак, зәйтүн мае экспорты буенча дөньяда беренче урынны тоткан илгә битараф калып буламы?

Бусаидта каһвә дә тәмлерәк

Иң элек Бусаид шәһәренә бардык. Әлеге аксыл-зәңгәрсу кала диңгезгә терәлеп урнашкан тауда төзелгән. Әйтерсең лә, диңгез өстендә болыт эленеп тора! Чиста-пөхтә итеп җыештырылган тыкрыклар, таш түшәлгән урамнар, чәчәкләр – бәләкәй Италия диярсең. Эрбет чикләвеге салып пешерелгән ниндидер тылсымлы чәй эчтек без анда урамда. Кунаклар килгәч, мантый яки пылау салып чыгара торган кулдан ясалган тәлинкәне дә шуннан алдык. Ул да аксыл-зәңгәрсу төстә. Башка бөтен нәрсәләр кебек. Билгеле инде, бик күп итеп фотосурәткә төштек – шәһәр шуның өчен генә төзелгән кебек.

Зәйтүн – җирле валюта аларда, кешенең байлыгы да ничә төп зәйтүне булу белән бәяләнә.

Аннан соң Тунис амфитеатрына киттек. Аны 30 мең кеше сыйдырышлы, диләр. Таш диварлар, ат чабышлары уза торган ташлы юллар, гладиаторлар яшәгән бүлмәләр һәм искиткеч акустика. Бер тавыш бирсәң, борынгылыкның мең кайтавазы кайтып ишетелә... Ни өчендер без анда үзебез генә идек. Мин ташларны тотып-тотып та карадым. Һәм вакыт агышын тойгандай булдым... Аннан соң каһвә эчәргә туктадык. Сөйләшмичә генә эчтек: алган тәэсирләр шулкадәр күп – барыбыз да аларны кабат күңелдән үткәреп утырдык бугай...

Каһвә дигәннән, каһвә ярата торган кеше буларак әйтәм: Туниста бу эчемлекне ясый беләләр! Монда аны хәтта бәләкәй генә кафеларда да яратып, җиренә җиткереп пешерәләр.

Сахара – башка галәм

Һәм менә без Сахарага да килеп җиттек... Чүлнең капкасы бардыр дип белә идегезме? Безне бер капка янына алып килделәр дә: «Ә теге якта йөзләрчә чакрымнарга сузылган чүл», – диделәр. Шунда ук чүлгә чыгып китмәдек әле, башта махсус кунакханәгә урнаштык, бассейнда йөздек, ял иттек.

Иртән торуга чүлгә сәяхәткә әзерләнә башладык. Безгә махсус халатлар өләшеп чыктылар. Кызларга күлмәк, яулыклар бирделәр. Авыз-борыннарга, күзгә ком тулмасын өчен яулыкны дөрес итеп бәйләргә өйрәттеләр. Ул күлмәкләрнең чуарлыгы, матурлыгы! Сөенә-сөенә әнә шул чуар киемнәрне киеп, төркемебез белән дөяләр янына киттек. Безнең Россиягә дә Венециядәге яки Бразилиядәге кебек шундый бер чуар бәйрәм кирәк – ниндидер бер тылсымы бар бугай аның.

Дөяләргә утыртып (ә алар куркыныч дәрәҗәдә шундый биек икән!), безне кәрван белән чүлгә алып чыгып



■ Ни өчен Римның Колизее турында бишектәге бала да белә, ә менә Колизейны хәтерләткән шушы амфитеатр турында белмәгәнбез икән?

Дәрәҗәләрен белгән, башкаларны да ихтирам иткән берберларның ниндидер безгә ачылмас сере бар кебек.



«Йолдыз сугышлары» фильмы төшерелгән урын менә шушы инде ул!

киттеләр. Һәр дөянең үз холкы – тере җан ияләре бит. Ритмын тоярга, сулышын ишетергә – аны аңларга кирәк. Тирә-якта ком, тынлык һәм чиксезлек булганда, синең белән тәнгә тән, җанга җан дөя генә кала да... Улым белән икебез бер дөядә бардык. Озак бардык без... Улымның анда алган хис-кичерешләрен беркайчан да онытмаячагын төгәл беләм... Туктап ял иткәндә кызлар фотосурәткә төшеп кинәнде: ул рәсемнәр башка галәмнән кебек. Без чүлгә чыккан көнне, бәхеткә, баш өстендә болытлар бар иде – бик эссе булмады. Аннан соң улым белән квадроциклларда ком таулары буйлап чаптык – авыз тулы ком, әмма бәхет икебездә дә ташый! Ярый әле әнисе күрмәде – эләгер иде.

Икенче көнне чүл аша джипларда чыгарга планлаштырдык. Безгә иске генә «Лэнд Крузер» туры килде, аның каравы, йөртүченең шәбе эләкте. Ком таулары буйлап сикерә-сикерә очканда, кискен борылышлар ясаганда, без алган адреналин гомер буена җитәрлек булгандыр, мөгаен. Шул рәвешле мин моңа кадәр хыяллана да алмаган урынга килеп җиттек: Джордж Лукас «Йолдыз сугышлары» («Звездные войны») фильмын төшергән җир! Ташландык планетада комнан түгәрәкләп эшләнгән өйләрне хәтерлисезме? Ярышларда җиңгән малай – Энакин Скайуокерны, аның әнисе, Роботлар торган бүлмәләр, чит планета антенналары – болар барысы да биредә икән бит, Җирдә! Мин – урта яшьләргә җиткән ир – авызымны колагыма кадәр ерып, бер бүлмәдән икенче бүлмәгә, бер йорттан икенчесенә чабып йөрим, һәрнәрсәне тотып карыйм. Тунис мине генә түгел, Лукасны да ничек әсир иткән!

Сюрпризлар моның белән генә бетмәгән икән әле. Күпмедер вакыт барганнан соң, күз алдында мираж – рәшә барлыкка килә... Юк, рәшә түгел, оазис икән ул. Җан әсәре булмаган чүлдән кинәт кенә дымлы, тропик үсемлекләр каплап алган утрауга килеп керәбез. Биредә бөтен нәрсә чәчәк ата, хуш ис аңкый, олы хөрмә пальмалары күләгәсен бирә, әрәмәлекләр... Кыскасы, джунгли! Без моңарчы белмәгән, ишетмәгән ниндидер җимеш сулары эчерделәр дә: «Ә хәзер тауларга барабыз!» – дип алып киттеләр. Бу могҗизадан соң, алга таба безне инде башка берни дә шаккаттырмас кебек. Ялгышканбыз!

Оазис уртасында, чыннан да, ниндидер кыялы таулар бар икән. Куркыныч упкыннар, тар гына юллар... Озак кына вакыт югарыга күтәреләбез. Арыта. «Нигә кирәк иде инде монысы?» – дигән үкенүле уйлар күңелгә үрмәли... Һәм шул вакытта күз алдында гаҗәеп манзара ачыла: биек шарлавык һәм аста яшеллек белән әйләндереп алынган күл! Чүл уртасында шарлавык булыр дип кем уйлар?! Тунис турында берәр нәрсә укырга кирәк булган икән лә... Ә Зәлиянең коенасы килә. Нәкъ менә шушы күлдә! Балаларны туңдырма ашарга алып китәләр, ә без су буена йөгерәбез. Йә Тунис, шаккаттырып армадыңмы әле?

Шулай уйлап, чүл уртасындагы күлдә чырык-чырык су коенганда, ярдан тавыш килә:

– Карале, хатын, Африка уртасында татарча сүләшәләр!

Чип-чиста мишәр диалектында әйтәләр бу сүзләрне! Зәлия белән янә чын мәгънәсендә шок кичерәбез. Тунис, син безнең өчен бигрәк тырыштың!

Яңа танышларыбыз – яшь пар – туристларның икенче бер төркеме белән килгән Самара татарлары булып чыкты. Хәтта уртак танышларыбыз барлыгы да ачыкланды. Дөнья түгәрәк дип кем әйткән әле?!

Шәрык базарында

Киләсе сәяхәтебез – Туниснең башкаласына. Туниска! Яңа исем эзләп мәшәкатьләнмәгәннәр. Архитектурасы белән Италияне һәм Францияне хәтерләтә. Париждагы кебек Арка капкасы да бар, Европадагы кебек кечкенә кафелары да адым саен... Ә безгә базар кирәк! Алдан ук: «Биредә товар арзан, әмма ләкин барыбер сатулашыгыз!» – дип кисәтеп куйдылар. Истанбулныкына охшаган зур базар булып чыкты ул. Чын лабиринт мәгәр – очына чыгармын димә. Без югалмас өчен бер-беребезгә тотынып йөрдек. Керүгә үк көмеш әйберләр сатучының алкалары, йөзеге, сәйләне ошады. Артыгы белән сатулаштым бугай – килешә алмадык. Менә дигән күннән эшләнгән сумкаларның арзанлыгына шаккатып, күн сандалиларның 300 сум гына булуына тел шартлатып йөри-йөри, товарның муллыгыннан, чуарлыгыннан баш әйләнә башлады. Ә андагы исләр... Якында гына нәрсәдер кыздыралар, каһвә пешерәләр. Күңелгә бәйрәм хисе кереп тула да шатлыктан бөтен нәрсәне аласы килә башлый!.. Без дә нәрсәләрдер алган булдык, чыкканда янә теге көмеш сатучыга юлыктык. Бәясен килештек бу юлы. Зәлия аны тагып берәр җиргә чыкса, бик кыйммәтледер дип сорамый калмыйлар. Ә без шул өч эшләнмәне нибары 750 сумга алдык!

Карфаген хәрабәләре

Аннан соң Карфагенга юл алдык. Бик көчле цивилизация үзәге булган ул. Урта диңгез ярына урнашкан олы кальга Рим империясенә каршы тора алмаган. «Карфаген җимерелгән» – тарих бөтенләй башка юлдан киткән.



■ Берберларның йортын күз алдына китерегез: калкулык үзәгенә чокыр казылган. Шул ук чокыр – ул зал. Залдан башка бүлмәләргә ишекләр чыга. Калкулыкның бер ягыннан йортка керә торган ишек тә бар.

■ Бербер келәмнәре дөньяда иң кыйммәтлеләрдән санала икән.



Хәзер инде хәрабәләре генә калган. Ләкин әле шул хәрабәләрдә дә аның көче, рухы сизелә. Ярым җимерек биек аркалардан гына да ул вакыттагы архитектураның ни дәрәҗәдә камил булганлыгы аңлашыла. Тыкрыкларыннан үткәндә Зәлия белән аяк астындагы мозаикага игътибар иттек. Рәссам буларак әйтәм: бик нечкә һәм югары сәнгать әсәре ята аяк астында. Һәрбер таш: «Әйе, бөек цивилизация иде, әмма «Карфаген җимерелде», – дип пышылдый кебек... Ләкин безгә алар сагышлы булып тоелмады. Ялтырап торган зәңгәр диңгез ярында хәрабә хәлендәге ташлар шундый мәгърур ята... Юк, алар кызганыч түгел!

Берберлар – горур халык

Алга таба безне берберлар белән танышу көтә иде. Берберлар – чүлнең җирле халкы, Африканың бөтенләй башка цивилизациясе. Алар безне өйләренә кунакка чакырды.

Йортлар шактый зур мәйданны били: 300 квадрат метрлап булыр. Диварлар нык, буялган. Эчтә уңайлы, салкынча һава. Электр уты, телевидение, интернет – барысы да бар. Калкулык өстенә антенналар чыгып тора. Игътибар белән карасаң, мондый антенналарның бик күп икәнен абайлыйсың. Еракка карыйсың: алда япан кыр җәйрәп ята, ә аста – олы бер авыл.

Мине идәннәренә җәелгән келәмнәр әсир итте. Алар төрле төсле итеп, искиткеч бизәкләр ясап тукылган – күзне алып булмый. Африка төсләренә шунда гашыйк булып кайттым.

Безне табынга чакырдылар. Пирожныйлары телеңне йотарлык иде. Балалар берсен-берсе уздыра-уздыра ашап бетерделәр, әниләренә нәкъ шундыйны пешерергә өйрәнергә куштылар. Кайтышлый бербер бөтнеген сатып алдык. Банкасын ачуга, әле һаман да хуш исе бөтен өйгә тула. Татарлар мине аңлар: ул чәйне эчеп туеп булмый!

Безнең өчен иң мөһиме – берберлар үзләре булды. Кешелекле, тыныч холыклы булып истә калдылар. Алар ак тәнле. Хатын-кызлары бик чибәр, йөз чалымнары төгәл.

Бөек Укба мәчетендә гыйбадәт

Аннан соң маршрутыбыз Кайрун шәһәренә иде. Иң элек келәмнәр кибетенә алып керделәр. Әлбәттә инде, һәрбер келәм – сәнгать әсәренә тиң, шуңа күрә бик кыйммәт тә. Күрше бүлмәдә келәм тукыйлар – мин дә тукып карадым. Үтә дә нечкә эш икән: кулың эш белү генә җитми, олавы белән түземлек тә кирәк. Шуннан соң келәмнәргә ихтирамым тагын да артты.

Бик матур намазлык сатып алган идем. Кибеттән чыгуга якында гына азан тавышы ишетелде. Мәчет ерак түгел иде: гидка әйттем дә, намазга йөгердем. Бу мәчеттән дә борынгырак бина күргәнем юк иде әле! Аның калын таш диварлары гына да ни тора... Ә эчтә салкынча, рәхәт. Картлар, чит кавемнән булсам да, мөселман дип, үз итеп карадылар. Дөньямны онытып, намазымны укыдым... Автобуска килсәм, бар да мине генә көтә. Ачуланып та алдылар, ә минем авыз ерылган... Һич җыеп алып булмый – шундый бәхетле идем ул мизгелләрдә. Кайткач, укып карасам, Мәккә, Мәдинә һәм Иерусалим мәчетләреннән кала, әһәмияте ягыннан ул дүртенче урындагы Аллаһ йорты – Бөек Укба мәчете булган икән!.. Ялгыштык шул: сәфәргә чыгар алдыннан Тунис турында аз булса да мәгълүмат җыясы калган. Әгәр дә азан тавышын ишетмичә, бу мәчеткә кермичә киткән булсам?!.

Мозаика музееннан соң отельгә тәмам алҗып, арып кайтып егылдык. Ялыбызның да ике генә көне калып бара иде инде. Диңгез давыллап тора, яңгыр ява, күк күкри, яшен яшьни. Һәм Зәлия шул давылда диңгездә коенырга дип чыгып китте. Фотоаппаратны эләктереп мин дә аның артыннан йөгердем... Беренче тапкыр шунда диңгез белән күк тоташканны күрдем. Күккә омтылган дулкыннар белән болытлар диңгезгә иелеп кочаклаша сыман. Ә Зәлия күлмәкчән генә шул дулкыннарга каршы йөгерә... Бу мизгелләрдә без – дөньяга, дөнья безгә ачык иде. Тунис безне үзенә әнә шулай көтмәгәндә чакырып китереп, җанын, күңелен, йөрәген ачты...

«ЛӘЙСӘН ХӨСНУЛЛИНА ИРЕ...»



Илнар ХӨСНУЛЛИН, журналист, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррир урынбасары.
гаилә стажы – 15 ел;
балалары – Зәйнәп, Аяз.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Миңа калса, барлык ир-атлар да иң элек хатын-кызның тышкы кыяфәтенә карый. Буй-сынына, күзләренә... Әле тавышы да бәреп егарга мөмкин бит! Аннан соң гына эчке дөньясына чират җитә. Җитмәгән чаклар да була...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Юк-барга да үпкәләвен, кайбер нәрсәләрне онытып җибәрүен, шалтыраткач, җавап бирмәвен, телефоннан сөйләшеп, плитәдәге ризыкны яндыруын...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтне. Алла сакласын, хәтта балалар хакына да андый нәрсәне оныта алмас идем. Шундый кешеләрне беләм: ахырга кадәр гаиләләрен таркатмаска тырышалар. Тик ахыр чиктә барыбер өзелә андый мөнәсәбәтләр. Һаман саен шул вакыйганы искә төшереп яшәгәнче, нокта кую яхшырак түгел микән? Бу, әлбәттә, тәҗрибәсез кеше җавабы гына.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Әлбәттә, икесен дә якын күрәм. Ике сыйфат та булсын дип теләр идем. Инде берсен генә сайларга кирәк икән, икенчесен өстен күрәм. Безнең кебек иҗади, кеше белән күп аралаша торган эштә ир-атны илһамландыручылар болай да җитәрлек. Тик аның белән генә ерак китеп булмый. Өйдә җаның тыныч түгел икән, илһам гына җитми. Шәхси тәҗрибә шуны сөйли. Кайтуга ашарга пешкән, балалар тук, өс-башлары бөтен икән, бу инде үзе үк илһам бирә. Әнә шул матди як хәл ителмәгән икән, рух бик тиз сына.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Була. Бар туганнар гына ишетергә тиешле сүзләр, бар дуслар гына белерлек серләр. Ә хатын күңеленә боларның барысы да сыя. Барысы ук булмаса да, күбесе инде... Мәхәббәт ул хисләр өчен кирәк. Тормыш алып бара башлагач, дуслык та сынала. Бер өлкәдә эшләгәч, хатын белән дусларча сөйләшә торган темалар аз түгел безнең.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Хәтерлим... Миңа ул вакытта 25 тулып киткән иде инде. Шуннан артып киткәч, төрлесен уйлый, артыгын сайлана башлыйсың. Күпне күргәч, күпне белгәч тә җиңел түгел бит. Хәтерлим, бакчада бәрәңге матиклый идек. Бездә шулай сөйләшәләр. Көтмәгәндә әти сүз катты: «Син өйләнергә җыенасыңмы соң ул?» Чәй эчәргә кергәч, Ләйсәнгә шалтыраттым. Мәйтәм, шундыйрак сүз чыкты бит әле. Нәрсә дип җавап биргәнен, соңрак ничек итеп рәсми рәвештә тәкъдим ясалганын бик хәтерләмим. Романтика бик юк миндә. Кыскасы, ике айдан өйләнештек без. Көтмәгәндә килеп чыккан вакыйга булмады инде бу, әлбәттә. Ләйсән белән өч елдан артык очрашып йөрдек, аның укуы тәмамланганны көттек. Булачак хатынымны, телевизордан карап, туганнар, ярты авыл белә иде инде. Ләйсән белән без «Шәрык» клубында таныштык. Анда атна саен диярлек чәй мәҗлесе оештыралар иде. Шунда чибәр бер кызның тәлинкә-чынаяк юып йөрүен күреп алдым. Күз шундук миңнәренә төште... Икенчесендә «Шәрык»ка әнә шул кыз белән танышу өчен махсус бардым. Хәер, аңа кадәр булачак хатыным турында хәйран гына мәгълүмат җыеп өлгергән идем инде. Бик тыйнак кыз булып чыкты ул. Баштарак хәтта озата кайтырга да рөхсәт бирми маташты. Ә аннары төнге автобус маҗаралары башланды... Ләйсәннәр шәһәр читендәге «Жилплощадка» бистәсендә яши иде. Казан халкы белә булыр: бигүк тыныч урын түгел. Әнә шуннан көн саен соңгы автобуска утырып, 10 нчы микрорайонга йөргән вакытлар булды. Хәзер егетләр йөри микән ул кызларын трамвай яки автобус белән озатып, билет алмаган акчага шоколад алып?

Ләйсән телевидениедә эшләгәч, аны, әлбәттә, күп җирдә таныйлар. Моңа инде күптән ияләшкән. Төрле мәзәк хәлләр дә килеп чыккалый. Ике ел элек Актанышка, дусларга кайтып барышыбыз. Боларның күрше авылларында туктап, күчтәнәч алырга кибеткә кердек. Гадәти хәл инде:

«Кем сез, нишләп йөрисез?» – дип сорашалар. Күрше авылдан гына булгач, дустыбызны танышлар булып чыкты. Күңеле күтәрелеп китте моның. Миңа төртеп күрсәтә: ә моны танышсызмы, янәсе. Җавап катгый булды: «Әйе, Ләйсән Хөснуллинаның ире Илнар, ике балалары бар, Казанда торалар». Сорасам, ИНН номерын да әйтеп бирәләр иде!

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Белмим... Ләйсәнне әнә шундый мантыйк белән сайладым дип әйтә алмыйм. Кем белә, бәлки, үзеннән-үзе шулай килеп чыгадыр, ир-егет үзе дә сизмәстән, кечкенәдән якын күргән кешесен эзлидер. Алай дисәң, килен-кайнана проблемасы бөтенләй булмас иде. Бер-берсенә охшаган кешеләр уртак телне җайлырак табарга тиеш бит инде.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Тагын да күбрәк тырышырга кирәк. Иң гади җавап шул булыр, әлбәттә. Тик барыбыз да белә инде: күбрәк мал табу өчен тырышлык кына җитми. Миңа калса, бу очракта күп нәрсә холыктан, тәрбиядән тора. Бар үзе бернигә ярамаган ирләрнең гомере буе көнләшеп, тегеләй, болай итеп хатынын изеп яшәгәннәре. Бар, авырып, урын өстендә яткан ирен еллар буе патшалардай күреп тәрбия иткән хатын-кызлар. Тагын бер фактор бар икән әле: кеше сүзе. Менә анысы бөтенләй малсыз калдырырга мөмкин инде.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бик уңай карыйм. Ир-егетнең башын әйләндерә инде андый сүзләр, бер башка үстереп җибәрә, рәхәт була... Хатын-кыз заты бик оста файдалана аннан. Баш кына югалмасын.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Белмим. Төс-кыяфәт дип әйтер идем, шикле тоела. Оят булса да әйтәм: яшь чагында кызлар игътибарсызлыгыннан артык интекмәдем. Ә төс-кыяфәтем модельләр, спортчылар өммәтеннән түгел. Минем очракта сөйләшә белү һәм үҗәтлек йогынты ясагандыр, ахры. Шунсыз Ләйсән кебек кыз миңа карамас һәм хатыным булмас иде.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Теләсә кайсы хатын-кызның йомшак, нечкә урыны буладыр, дим. Барысына да җылылык һәм игътибар кирәк. Чибәр хатын-кызның үзеннән курыкмый ирләр, башкаларның да күзе аңа төшәр, дип шикләнә.

12 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Сәгатьләр буе йөреп тә, кибеттән берни алмый кайтканын аңламыйм кайчак. Әле менә берничә көн элек Ләйсән телефонга язган: «Дару алып кайтырга кирәк». Кердем даруханәгә, сатучы кыз сорый: «Сезгә эчә торганымы, сылый торганымы, әллә башкасы кирәкме?» – ди. Хатынга шалтыратам, җавабы мондый: «Ә мин каян белим, үзең кара инде!» Иң кызыгы: хатын-кыз даруы сорый бу!

13 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Башта хаклы булуымны ничек тә исбатларга тырышам. Сүгенер чиккә җиткәч, туктыйм да, барыбер үземчә эшлим. Табак-савыт ваткан юк, шулай да бер мәртәбә яңа телефон сатып алырга туры килде.

14 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Уйга калдырды әле бу сорау. Чөнки өйгә кайткач, ашарга берни булмаган чакны хәтерләмим икән. Беренчедән, соң кайтам. Икенчедән, кызыбыз мәктәптән кайтып, кабат чыгып киткәнче капкалап алсын дип, һәрвакыт ризык әзерләп калдыра Ләйсән. Өченчедән, бик уңган хатын әлкте миңа. Кафеларга да чыгып киткәлибез, пицца-фәлән дә китерткәлибез. Әмма андый көннәрдә дә ашарга пешерә хатын. Сәбәбен әйттем инде. Хәзер инде кызыбыз да кухняда озаграк тоткарлана башлады. Кирәк икән, үзем дә пешерә алам. Шөкер, тәҗрибә бар. Төркиягә укырга киткәндә, дөресен әйтим, йомырка пешерүдән башкасын белми идем. Тегендә исә биш-алты егет бергә торабыз. Чиратлашып иртән һәм кич ашарга пешерәбез. Нәрсә эшләсәң – эшлә, әмма кичкә табында ризык булырга тиеш! Тора-бара төрлесенә өйрәндек. Бу тәҗрибә өйләнгәнче генә кирәк булды. Аннары кухняга ашау өчен генә керә башладым. Хатын кертмәгәнгә түгел. Кызыбыз Зәйнәп тугач, әби-бабай янында яшәп алдык. Кияү кеше, ничек инде, әбидән узып ашарга пешереп йөрсен ди?! Елга берәр мәртәбә ясмык яки фасоль ашы пешерсәм, зур вакыйга була ул бездә.

15 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме?

– Бик тә. Бигрәк тә ерак юлга чыгасы, авылга кайтасы булганда. Көтәргә яратмыйм! Кыш көне җайлырак әле: алданрак чыгып китеп машина җылыткан буласың, тәтен суыра торган начар гадәтем бар – анысы да вакыт уздырырга ярдәм итә. Ничек көрәшәмме? Бер хәйләле ысулым бар. Әйтик, «бөке»дә утырам, кайтып җитәргә әле ким дигәндә тагын ярты сәгать вакыт бар, ә мин «15 минут» дим. Әмма нәрсәдер эшләп кенә хатынны үзгәртеп булмый. Теләсә дә, үзгәрә алмас иде. Мин чыгам да машинага утырам, аның үзен генә түгел, балаларны да җыясы бар бит. Башта кызып китәм дә, аннары аңларга тырышам.

Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: 16 ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Без инде хәзер 15 ел бергә яшибез. Бүләкне ошыйошамыйга түгел, кирәк яки кирәк булмаганга карап ала минем хатын. Мин, мәсәлән, азык-төлек кибетендә, базарда сәгатьләр буе йөри алам. Кием яки башка нәрсә сайлаганда түземлек 15–20 минутка гына җитә – чыдамыйм. Шуңа күрә соңгы вакытта бүләккә күбрәк кием эләгә. Ошамаган әйбер алганын хәтерлим. Бәлки, ошамаганны да ошатып кабул иттерә белү сәләте зурдыр минем хатынның?!



Әлеге патология яңа туган балаларның терәк-хәрәкәт системасында күзәтелүче чирләрнең 70 процент чамасын тәшкил итә. Аны вакытында күреп алу бик тә мөһим, чөнки ул киләчәктә бала сәламәтлегенә җитди куркыныч тудыручы фактор булып тора. Республика балалар клиник хастаханәсенең травматология бүлеге мөдире Ленар ДЗЮМЕНКО белән сүзебез балаларда еш очраучы оча-бот буыны дисплазиясе хакында.

БАЛАДА БУЫН ДИСПЛАЗИЯСЕ

Баланың тумыштан килгән оча-бот буыны дисплазиясе – буынның тумыштан җитлегеп бетмәве ул. Дөрес формалашмавы сәбәпле, әлеге буын урыныннан күчәргә, хәтта чыгарга да мөмкин. Кыз балаларда ул ешрак очрый (80 процент очракта). Нәселдәнлекне дә кире кага алмыйбыз, әтиәнисендә бу патология булган балаларда оча-бот буыны дисплазиясе ун тапкыр ешрак күзәтелә. Бала ана карынында дөрес урнашмыйча, арты белән туганда да оча-бот буынына зыян килергә мөмкин. Хатын-кыз беренче баласын тудырганда әлеге куркыныч тагын да зуррак. Авырлы чорда йөклелекне дару препаратлары белән көйләү, әни кешенең көчле токсикоздан интегүе дә туасы балада оча-бот буыны дисплазиясе булу ихтималын арттыра. 60 процент очракта сул яктагы буын зарарлана. Кайчагында дисплазия сул якта да, уң якта да булырга мөмкин.

Әлеге патология баланы клиник карау вакытында ачыклана. Диагнозны раслау өчен УЗИ, рентген билгеләнә. Бала тудыру йортында сабыйны тикшергән ортопед тарафыннан ук дөрес диагноз үз вакытында куелырга тиеш. Алга таба мондый балалар яшәү урыны буенча ортопед күзәтүендә булалар. Дөрес һәм үз вакытында дәваланган очракта, буын дисплазиясе җитди кимчелекләргә китерми. Тиешле дәва чаралары күрелмәсә, тора-бара балада диспластик коксартроз башланырга мөмкин, соңгы стадияләрдә зарарланган буынны эндопротезга алыштырырга туры килүе ихтимал.

Билгеләре

- күкрәк баласын корсагына салып, аякларын турайтканда утракса уемнарының (ягодичные складки) бер тигезлектә булмавы. Әлеге күренеш мускулларның тонусына да бәйле, шуның өчен төп күрсәткеч булып саналмый;
- баланың аякларын тездән бөккәндә бер тезе икенчесеннән өстәрәк була;
- баланың аякларын ян-якка җәйгәндә бер аягын өстәлгә кадәр тидереп булса, икенчесендә хәрәкәтнең чиклелеге сизелә. Ике яклы дисплазия күзәтелгәндә, ике аягын да өстәлгә тидерү мөмкин түгел;
- баланың ике аягын ике якка җәйгәндә буыны җиңелчә генә шыртлап куя.



Табиб киңәш итә



- оча-бот буыны дисплазиясе куркынычы янаганда баланы иркен итеп биләү (широкое пеленание), ягъни аяклары арасына калын итеп бөкләнгән биләүсә куеп калдыру файда бирә.
- Йөклелек чорында табиб кушканнарны тәгәл үтәү мөһим. Дару препаратларын үзбелдегең белән куллану бала сәламәтлеге өчен куркыныч булырга мөмкин.
- Булачак әнинең көчле стресслардан, төрле инфекцияләрдән саклануы кирәк.
- Яңа туган баланы каты итеп кысып тотарга ярамый. Яңа туган балаларның аякларын ян-якка таба җәеп ятуы – табигый халәт.
- Сабыйга профилактик гимнастика ясау файдалы.
- Балага подгузникларны дөрес сайлагыз. Подгузникның артык тулып, авырайганын көтмәгез.



Дәвалау ысуллары

- Һәр очрак индивидуаль, кайсы ысулның отышлы булуын табиб кына билгели. Кайчак беренче айларда баланың аякларын дөрес халәттә тоту өчен махсус ортопедия җайланмалары кулланыла. Әйтик, Павлик өзәңгесе. Әлеге җайланма баланың аягын дөрес бөгеп, буын өлгереп җиткәнче дөрес халәттә тотарга булыша, шул ук вакытта баланың хәрәкәтләнүен дә чикләми.
- Андый җайланмалар күптөрле. Аларны үзбелдегең белән куллану мөмкин түгел. Дисплазиянең нинди дәрәҗәдә булуына карап, аларны табиб-ортопед билгели һәм җайланманы дөрес кулланырга өйрәтә.
- Махсус чаралар нәтиҗә бирмәсә, хирургия ысулы кулланылырга мөмкин.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

Фото: www.pixabay.com



Кешенең иң нечкә җире күз, диләр. Дөньяның матурлыгын, кояшның яктысын, якыннарыбызның көләч йөзләрен күрү өчен күзләр кирәк. Тик яшь барган саен, алар да җителеген югалта, тоныклана. Медицина телендә күзнең тоныклануы катаракта дип атала. Республика клиник офтальмология хастаханәсенең беренче микрохирургия бүлеге мөдире, Татарстанның атказанган табибы, югары категорияле офтальмохирург Гүзәл АНИСИМОВА белән әлеге чир хакында сөйләшәбез.

КАТАРАКТА

Катаракта – күз хрусталигы тоныклану ул. 55 яшьтән узган кешеләрдә күз күреме начараюга еш кына нәкъ менә шул сәбәпче була. Катаракта кайчак яшькә генә бәйле булмый, ул берәр травмадан соң да башланырга мөмкин, кайбер төр дару препаратлары, организмдагы башка чирләр дә хрусталикның тоныклануына китерә ала. Катаракта көчәя барган саен, кешенең күрү сәләте кими, хәрефләр генә түгел, хәтта башкаларның йөзләре дә ачык күренми башлый. Тора-бара кеше бары яктылык һәм караңгылыкны гына аера алыр хәлгә кала. Вакытында чарасын күрмәсәң, ул дөм сукырлыкка да китереп җиткерергә мөмкин.

Катаракта булу-булмавын бары тик күз табибы гына ачыклый ала. Гадәттә, диагноз кую кыенлык тудырмый. Табиб күрү җителеген ачыклый, күздәге басымны үлчи, биомикроскопия ярдәмендә күзнең алгы өлешен тикшерә, күзнең күрү кырларын (периметрия) билгели, челтәр катлавын һәм күрү нерв дискын карый. Кайчак УЗИ да билгеләнергә мөмкин.

Кызганыч, катарактаны бернинди тамчылар тамызып, дарулар эчеп кенә дәвалап булмый. Болар тоныкланган хрусталикны ача алмый. Күздә нниндидер тайпылышлар барлыгын сизү белән, табибка күренергә кирәк.

Бүген катарактаны дәвалаганда стандарт дәва ысулы булып ультратавышлы факоэмульсификация методы санала. Бер үк вакытта кечкенә генә кисем аша күзнең хрусталигы ясалма хрусталикка алыштырыла. Әлеге операция урынлы анестезия белән амбулатор шартларда 15 минутта башкарыла. Пациент бернинди дә авырту тоймый. Исегездә тотыгыз: катаракта авыруын бары тик офтальмолог ярдәме белән генә дәвалап була.

Билгеләре

- көчле яктылыкта предметлар тирәсендә ареола (якты боҗра) күренә;
- күзнең күрүе тоныклана;
- язылганны уку кыенлаша, хәрефләр аерылмый башлый;
- эңгер-меңгердә күрү начарлана;
- төсләрне аеру читенләшә.

Катарактага китерергә мөмкин:

- күз эчендәге югары басым;
- гормоннар җитештерү бозылу;
- яман гадәтләр;
- күз травмалары (контузия, күзнең химик яки механик җәрәхәтләнүе);
- эчке секреция бизләренең дөрес эшләмәве (шикәр диабеты, матдәләр алмашы бозылу, авитаминоз);
- күзнең башка авырулары булу – югары дәрәҗәдәге күрә карау (близорукость), глаукома;
- агулланулар;
- көчле ультрашәмәхә нурланыш алу;
- көчле радиация;
- кайбер төр дару препаратларын озак вакыт куллану.

Катаракта булмасын өчен:

- күзне ультрашәмәхә нурлардан сакларга;
- антиоксидантларга бай ризыклар белән тукланырга;
- глюкоза һәм холестерин күләмен гел тикшертеп торырга;
- күз авыруларын вакытында дәваларга;
- табиб киңәше белән поливитаминнар кулланырга;
- начар гадәтләрдән, аеруча – тәмәке тартудан туктарга.

Операциядән соң ничек сакланырга

- табиб киңәш иткән даруларны күзгә тамызуны дәвам итәргә;
- бер атна дәвамында операция ясалган якка ятмаска;
- операция ясалган күзгә тимәскә;
- урамга чыкканда кояш нурларыннан саклый торган күзлек киярге;
- операциядән соң бер ай буе кайнар мунчага, саунага, кайнар ваннага кермәскә;
- бер ай авыр физик эшләрдән сакланырга – авыр күтәрмәскә, көчәнмәскә, иелеп эшләмәскә.



Республика клиник күз авырулары хастаханәсенең матбугат сәркатибе Рида Борһанова ярдәме белән әзерләнде.

ЯЗ СУЛЫШЫ СИЗЕЛӘ

Урамда әле ак карлы кыш, ләкин Җирдә инде яз сулышын тоябыз. Көннәрнең озыная баруы да сиздерә аны, тәрәзәдән төшкән кояш нурларының җылысы да, песнәкләрнең күңелле чыркылдашуы да... Безгә дә бакча эшләренә керешергә вакыт, яз озак көттермәс ул, килер дә җитәр.

Яшелчәчегә

Февраль ае – чәчү сезонына ныклап керешә торган ай. Баклажанны, борычны һәм помидорның соң өлгерешле сортларын инде чәчәргә кирәк. Бакчага чыгарганда алар 75 көнлек булырга тиеш. Шулай ук порей суганы, тамыразык петрушка, сельдерей, кәбестәнең иртә өлгерешлесен, чәчәк, брюссель, кольраби кәбестәләрен чәчүгә дә соңармый керешәләр. Кәбестә үсентесе салкынча һавада гына яхшы үсә, мартта инде кояш җылырак карый, тәрәзә төбендә эссе була. Башлы суганны орлыктан үстерергә теләсәгез, аны да февральдә чәчегез, суган озак тишелә.

Үсенте утырткан савытлар тәрәзә төбендә күп урын ала. Порей суганы, башлы суган, сельдерей ишеләрне савытка түгел, 10 см киңлегендә киселгән калынрак полиэтиленга (ламинат аслыгы бик кулай) 1–2 см калынлыгында түшәлгән туфракка чәчеп, аны әкәмтөкәм кебек төреп куйсагыз, урынны күп алмас. «Әкәм-төкәм»не сайрак савытка утыртып куегыз.

Бүлмә гөлләре

Яз якынлашуын, мөгаен, иң беренче булып бүлмә гөлләре сизәдер. Әнә яраннар инде кышкы йокыларыннан уянып килә – ни арада бер буынга үсеп тә өлгергәннәр. Яран гөле уртача гына биеклектә, берничә тармаклы булганда матуррак күренә, чәчәкне дә мулрак ата. Февраль ахыры, март башларында тәрәзә төбендә кышлаган гөлләрнең артык озын булып үсеп, бер-берсенә комачаулый торган тармакларын кисеп, куакны формалаштыралар. Бик карт үсемлекне артык кыскартмагыз, кабат яшәреп китәр өчен көче җитмәскә мөмкин. Ә яшьрәкләренең төбеннән ике-өч буын гына калдырып, сабакны үткен пычак белән яфрак өстеннән кыеклап кисәләр. Төп сабактан кырыйга таба үсеп чыккан кечкенә тармакларны да кисеп алалар. Киселгән урынга вакланган агач күмере сибәргә яки «зеленка» тидереп куярга кирәк. Берәр атнадан соң яраннарны азотлы ашлама белән тукландырырга була.



Чәчәкләр яратсагыз

Иртәрәк чәчәк атсын дисәгез, тагетес, петуния, львиный зев, лобелия, хризантема, дельфиниум кебек чәчәкләрнең орлыкларын февральдән дә калмый чәчәргә кирәк.

Петунияне күпләр ярата, тик үсентесен үзләре үстерергә авырыксыналар. Югыйсә катлаулы түгел ул. Беренчедән, петуниянең берничә төре барлыгын белергә кирәк: асылмалы (ампель), куаклы (кустовой), каскадлы (үрмәле). Балкон,



верандаларда биеккә элеп үстерү өчен асылмалы сортлар әйбәт. Клумбалар өчен куаклы сорт матур, үрмәләтү өчен – каскадлысы. Петуниянең орлыгы бик вак, аны ком белән катнаштырып чәчүе уңайрак. Орлык чәчәсе туфракка кар түшәп, шуның өстенә чәчегез, туфрак белән күмдерергә кирәкми. Орлыклар тишелгәнче, өстен каплап, савытны җылы урынга куеп торыгыз. Тишелеп чыккан үсентеләр бик зәгыйфь була, суны бары бөркеп кенә сибәргә кирәк. Петуния җылыны һәм яктылыкны ярата. Кулга тотарлык була башлагач, һәрберсен кечерәк савытка күчереп утыртыгыз, калийлы-фосфорлы ашлама белән ашлагыз.

Бакчачыга

Быел кар күп. Кар катламы биек булганда, кыр тычканнары алмагач, груша агачларының кайрысын кимерә. Шуның өчен агач тирәсендәге карны яхшылап таптарга кирәк. Февраль азагына таба һава 5 градуска кадәр җылытып җибәрсә, агачларның кәүсәләрен агартыгыз (көздән агартмаган очракта). Бакчачының дуслары – кошларны җәлеп итү өчен, җимлекләр элегез. Кышын сез аларны кайгыртсагыз, яз көне – корткыч бөҗәкләр уянып чыккач, алар сезгә ярдәм итәр.

Юллардагы, сукмаклардагы карны теплица эченә, агач төпләренә түшәгез. Буш мичкәләргә дә кар тутырып куярга була. Кар суы яшелчәләр өчен бик файдалы.

Теплицада һәм ачык туфракта үстерү өчен баклажанның иртә өлгерешле сортлары: «Король севера» F1, «Уральский скороспелый», «Ультраранний» F1, «Алёшка» F1, «Полосатая семейка» F1.

Теплицада үстерү өчен борычның иртә өлгерешле сортлары: «Абрикосовая фаворитка», «Беладонна» F1, «Факир», «Винни-Пух», «Морозко», «Добрыня Никитич», «Кардинал» F1.

Теплицада һәм ачык грунтта үстерү өчен помидорның эре һәм итләч сортлары:

«Адамово яблоко», «Болгарское чудо», «Бельмонте», «Бычье сердце», «Дикая роза», «Мишка косолапый желтый», «Розовый гигант», «Сахарный великан», «Шоколадное чудо», «Шунтукский великан», «Японский краб».

Фото: www.pixabay.com



АРКА МУСКУЛЛАРЫН НЫГЫТАБЫЗ

Бик күп хатын-кызлар зур бер хата ясый: кысып торган бюстгальтер кия дә, аның өстеннән трикотаж кофта киеп куя. Алдан, бәлки, бик матурдыр, ә менә арттан, бигрәк тә ишелеп утырган вакытта бюстгальтерның киң поясы тирәсендә бөрмәләр барлыкка килә: буй-буй май катламнары ерактан ук «кычкырып» тора. Әлбәттә, дөрес итеп киенә белү, артык таза булмау бу кимчелекне качырыр. Әмма физик күнегүләр ясасагыз, арка мускуллары җыелып, сыныгыз төз булса, җаныгыз ни тели шундый кием кия аласыз. Тренер Резеда МУСИНА өйдә ясау өчен махсус күнегүләр өйрәтә. Моның өчен бары тик ике кечкенә гантель кирәк. Һәр күнегүне өчәр тапкыр 12–15 кат эшләү җитә. Бу – ярты сәгатьтән әзрәк вакыт кирәк дигән сүз. Бары тик теләк кенә булсын!



1 Корсак белән идәнгә сузылып ятабыз. Гантель тоткан кулларны алга таба сузабыз. Аякларны һәм иңсәне идәннән күтәрәбез. Сулыш чыгарганда кулларны үзебезгә тартып китерәбез. Сулыш алганда – алга сузабыз. Күнегүне бик салмак кына эшләргә кирәк.



2 «Дүрт аяклап» басабыз. Кулларда – гантельләр. Башта сул кулны һәм уң аякны, аннан соң уң кул һәм сул аякны күтәрәбез. Бу күнегүне эшләгәндә арка сыгылмасын. Аяк-куллар арка белән бер дәрәҗәдә күтәрелсен. Сулыш алу турында да онытмагыз.



3 Аякларны сузып утырабыз да: арканы әз генә артка җибәрәбез, аякларны тездән бөкләп, идәннән күтәрәбез. Куллар – күкрәк турында. Башта бер якка борылып, кулларны артка сузабыз, аннан – икенче якка. Күнегүне ясаганда аякларны идәнгә тидерергә ярамый. Арка да төз булсын.



4 Ян белән туры итеп сузылып ятабыз. Сул терсәкне идәнгә куеп, гәүдәне күтәрә төшәбез. Уң кул белән башны тотабыз. Сулыш чыгарган вакытта уң аяк тезен уң кул терсәгенә тидерәбез. Сулыш алганда элекке халәткә кайтабыз. Шушы ук күнегүне икенче якка да ятып эшләргә кирәк.



5 Туры итеп басабыз. Гантель тоткан куллар алга каратып күтәрелгән. Сулыш чыгарганда куллар ян-якка төшә. Сулыш алганда кабат күтәрелә. Күнегүне эшләгәндә туры торыгыз, бөкрәймәгез.



Зарядка күнегүләрен QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия

Юыну бүлмәсе

Юыну бүлмәсен уңайлы да, матур да итеп җиһазлау – үзе бер сәнгать төре. Бу бүлмә бәләкәй дә булса, аны бөтен таләпләргә җавап бирердәй итеп кору аеруча кыен. Тиешле размердагы сантехника урнаштырып, матур плитка ябыштыру – айсбергның башы гына. Юыну бүлмәсенә куелучы төп шарт – аның уңайлы булуы. Кеше үз гомерендә бу бүлмәдә 19 ай гомерен уздыра икән. Йокы бүлмәсе кебек үк, юыну бүлмәсе дә – җанга һәм тәнгә ял ала торган урын. Дөрес җиһазлар сайлап, аларны дөрес итеп урнаштырганда, хәтта бик кечкенә юыну бүлмәләрен дә уңайлы итеп корырга була. Интерьер дизайны белән күптәннән шөгыльләнүче Диләрә МИНИГУЛОВА безгә нәкъ менә шулар хакында сөйләр.





Автор рәсемнәре

Материаллар

Агач, бетон һәм таш – болар бер-кайчан да кулланылыштан чыкмаячак. Табигый материаллар бер-берсе белән бик яхшы яраша. Чын таш, әлбәттә, кыйммәт. Сатуда аларга охшатып ясалган плиткалар бар. Төсләре генә түгел, хәтта фактуралары да туры килә. Андыйлар Россиянең үзендә дә җитештерелә, шуңа күрә бәяләре дә гадәти плиткалардан әллә ни аерылмый.

Ваннада махсус составлар белән эшкәртелгән чын агач такталар яки рейкалар куллану да отышлы. Агач интерьерга җылылык өсти. Бу киштә яисә шкаф ишеге, раковина куелган өстәл, көзге кысасы булырга мөмкин.

Ванна бүлмәсен ямьлерәк итүнең тагын бер сере – контраст төсләр куллану. Бер стенаны яки стенаның бер өлешен җете төс белән аерып күрсәтү бүлмәне ачып җибәрә.

Материаллар ярдәмендә бүлмәне биегрәк яки киңрәк итеп тә күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, бүлмә тәбәнәк булса, турыпочмаклы плитканы вертикаль ябыштырырга, декорны вертикаль кулланырга була. Плитка һәм бордюрлар горизонталь ябыштырылганда, бүлмә киңрәк кебек күренә.

Шулай ук берничә төрле плитканы, әйтик, гади һәм арзанлы плитка белән кыйммәтлерәген бергә яраштыру да отышлы алым. Кергәч тә күз төшә торган стенага затлырагын ябыштырырга яисә аны панно рәвешендә кулланырга мөмкин.

Ваннамы, душмы?

Юыну бүлмәсе берьюлы берничә төрле функцияне башкара. Җиһазлаудагы кыенлыклар күбесенчә шуның белән бәйле. Бер кечкенә генә бүлмәгә тулы размерлы ваннаны да, кер юу машинасын да, раковинаны да, көнкүреш химиясе саклanучы шкафны да, кайчак хәтта су җылыта торган бойлерны да сыйдырырга кирәк була.

Дөресен әйткәндә, хәзер күбебезнең ваннага су җыеп, озаклап ятарга вакыты юк. Ванна урынны да күп ала. Бәлки, аны куйганчы, душ почмагы ясаргадыр? Бу очракта кер юу машинасын куяр урын да барлыкка килә. Әзер душ кабиналары урынына, су агып китәр өчен идәнне чак кына күтәртеп, плитка җәелгән душ почмагы ясау отышлырак санала. Юынганда су чәчрәмәсен өчен, пыяладан яки пластиктан ширма корыла. Пыяла ширма чак кына кыйммәтрәк булса да, аны карап һәм чистартып торуы күпкә җайлырак.

Душ почмагын корганда аннан файдалануның уңайлы булырга тиешлеген дә истән чыгармагыз. Иң минималь размер – 75 сантиметрга 75 сантиметр. Шуннан да кечерәк икән, душта юыну җайсыз булачак.

Күп вакытта ванна һәм бәдрәф бер бүлмәдә була. Хәзер идәнгә беркетелүче унитаз урынына күбрәк инсталляция кулланыла. Кечкенә бүлмәләр өчен бу отышлырак, инсталляциянең өске ягына шкаф яисә киштәләр урнаштырыла. Киштәдә көн дә кулланылучы әйберләр, ә ябык шкафта көнкүреш химиясен саклау уңай.



ВАННАДАГЫ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК

✓ Техниканың кайда урнаштырыласы, лампаларның кайда булачагы ремонтның иң беренче этабында ук уйланырга тиеш. Ванна бүлмәсендәге электр челтәренә иң катгый таләпләр куела. Күршеләргә күңелсезлек тудырмас өчен, су түгелгәннән датчиклар кулланырга мөмкин. «Система контроля от протечек» дип аталган бу җайланманың бәясе бар, билгеле, ләкин җан тынычлыгы кайчагында кыйммәтрәк була.

✓ Шулай ук өйдә өлкән кешеләр яки балалар булса, душта һәм бәдрәфтә тотынгычлар булдыру, идәнгә таймый торган плитка җәю яисә махсус келәм куллану кирәклеген дә истән чыгармагыз. Вак кына нәрсәләр кебек тоелсалар да, уңайлылык шундый вак-төякләрдән тора.

Раковина тумбаларының да стенага эленә торган модельләрен куллану бүлмәне визуаль киңәйтеп җибәрә. Идәннең буш булуы әнә шундый эффект бирә. Бу бүлмәне җыештырганда да бик уңай.

Кер юу машинасын ничек сыйдырырга?

Әлбәттә, өйдәге иң мөһим бу техниканы юыну бүлмәсенә урнаштыру күпкә отышлырак. Ләкин кайчак урын җитәрлек булмый. Кемдер кер юу машинасы өстенә раковина урнаштырып, әлеге хәлдән чыгу юлын таба. Мин болай эшләргә киңәш итмим, бу очракта раковинадан файдалануы кыенлаша. Стандарт үлчәмнәр буенча, раковина идәннән 80 сантиметр биеклектә урнашырга тиеш. Әгәр дә ваннаны душ белән алыштырсаң, бик кечкенә бүлмәдә дә кер юу машинасы өчен урын табарга була.

Керне кайда киптерергә?

Балконы булмаган яисә кечкенә балалары булган гаиләләр өчен кер киптерү мәсьәләсе дә бик актуаль. Элек ванна өстенә бау тарттырып, күпләр керне шунда киптерде. Хәзер кер киптерә торган махсус машиналар бар. Урынны экономияләү өчен, аны кер юу машинасы өстенә урнаштырып, бу колоннаны шкафка яшерергә була. Өстә буш калган урынга киштә тезеп, нәрсәнедер сакларга мөмкин. Шкафларны үз размерларыгыз белән хосусый эшмәкәрләрдә ясатып алу артык кыйммәткә төшми.

Мөмкинлек булса, суны электр белән җылыта торган бойлер куярга киңәш итәм. Җәйге чорда – җылы су булмаганда бик нык ярдәм итәчәк.



Яктылык

Юыну бүлмәсе якты булырга тиеш. Яктылык бу очракта турыдан-туры үз функциясен генә башкарып калмый, бүлмәне киңәйтеп, биегәйтеп тә күрсәтә. Бүлмә мәйданы бик кечкенә булса да, һәр зонаның аерым яктылык чыганагы булса яхшы. Көзге һәм аны яктырту турында да онытмагыз.

Бер стенаны яки стенадагы панноны диодлы лампалар белән аерым яктырту ванна бүлмәсенә серлелек һәм үзгә атмосфера өсти. Бу лампаларны уенты эченә кертеп ясалган киштәләрне яктырту өчен кулланса да бик матур.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

Йорт куяныннан рагу



Уйладык-уйладык та, февраль аенда «Аш-су» сәхифәсен ир-егетләр кулына тапшырырга булдык. «Ирләрчә иң тәмле ризык пешерәчәкбез!» – дип, дилбегәне үз кулына алды бертуган Альберт һәм Айрат ШАКИРОВлар. Алар безгә гади һәм үзенчәлекле ысул белән йорт куяныннан яшелчәле рагу әзерләп күрсәтергә булды. Бу егетләрнең аш бүлмәсендәге осталыкларын, ризыкны сәнгать дәрәҗәсендә әзерләүләрен күзәтеп тордык та, шундый нәтиҗәгә килдек: кулинарлар дөньясында бернинди Ханкишиев һәм Лазерсоннар түгел, үзебезнең Шакировлар мәйдан тотарга тиеш икән бит!

– Әзерләр өчен яшь куян итеп сайларга тырышыгыз. Куянның, сарык итенеке төсле, үзенчәлекле исе була. Шуңа күрә, беренче эш итеп, куянны эчке һәм тышкы майларыннан чистартырга кирәк. Ә аннан соң итне дөрес итеп бүлгәләү мөһим, – дип, Айрат безгә иң элек куян түшкәсен дөрес итеп бүлү буенча мастер-класс күрсәтте. (Сез боларның барысын да журналыбызның Ютуб каналыннан карап, йорт куяны итен яшелчәләр белән пешерүнең бик күп серләрен белә аласыз.)

Итне әзерләп куйгач, егетләр рагу әзерләргә керәште.

Кирәк

- куян түшкәсе;
- ике кишер;
- ике баш суган;
- шулпа өчен бер-ике кисәк тавык ите;
- дәфнә (лавр) яфрагы;
- түгәрәк кара борыч;
- бер аш кашыгы сыер мае;
- зәйтүн мае;
- көнбагыш мае;
- он;
- ике сельдерей сабагы;
- розмарин;
- бер-ике баллы борыч;
- издерелгән томат (кибеттә протертый дип язылганы сатыла);
- брокколи (яраткан очракта);
- укроп, петрушка.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия



Эш барышы

■ Тавык ите белән шулпа куябыз да кайнатып чыгарабыз. Күбеген җыеп алабыз.

■ Кишерне чистартабыз, суганны кабыгы белән юабыз һәм икесен дә урталайга бүлеп, коры табага куябыз. Аскы өлешләре кызарып чыкканчы утта тотабыз. Аннан аларны тавык шулпасына салабыз, ярты дәфнә яфрагы өстибез. Шулпага учак тәме сеңсен өчен шулай кирәк.

■ Ит кисәкләренә тоз һәм борыч тидереп куябыз.

■ Табага сыер мае белән көнбагыш маен кушып салабыз һәм шунда 2-3 теш сарымсакны кыздырабыз да кырыйга алып куябыз.

■ Ит кисәкләрен онда әвәләп, тышы кетердәп киткәнче сарымсаклы майда кыздырабыз.

■ Кыздырылган итне зур кәстрүлгә сала барабыз.

■ Сельдерей, кишер, суган, татлы борычны зуррак кисәкләргә бүлеп, турыйбыз һәм аерым табада зәйтүн мае белән биш минут пешереп алабыз. Бу – яшелчәләрнең үз тәме бүленеп чыксын өчен генә кирәк. Артык кызып китмәсен өчен, туктаусыз болгатып тору мөһим.

■ Алдан кыздырылган сарымсакны, табадагы яшелчәне куян ите янына салып, утка куябыз. Ит җылынган арада розмарин, әче кызыл борыч (аны турамыйча салсагыз, әче тәме күп чыкмас. Әгәр очын кисеп кенә саласыз икән, шулпада озак тотмый, яңадан кырыйга алып куегыз. Борычның бу үзенчәлеге турында да Айрат тәфсилләп Ютуб каналдагы видеода аңлата), издерелгән (протертый) томат (бакчада үскән помидор белән дә алмаштырып була) өстибез.

■ Кәстрүлдәге ингредиентлар күмелгәнче әзер тавык шулпасын салабыз. Талгын утта 35–40 минут пешерәбез. Шулпаның майлылыгына карап аз гына сыер мае өстибез һәм кашык очында гына паприка салабыз.

■ Сүндерергә биш минут кала, теләсәгез, брокколи да өсти аласыз.

■ Куян ите диетик ризык булып санала, шуңа күрә бәрәңге салып торырга кирәк түгел.

■ Өстәлгә ит белән шулпаны аерым бирәләр.

Башны әйләндерерлек хуш исле рагу өйләрегезгә ямь, бәйрәмнәргә куаныч алып килсен!

Тәмле булсын!



Киноа

Дөньяда иң файдалы ризыкларның берсе дип йөртелсә дә, бу ярма турында Россиядә бик аз гына кеше белә. Безгә Көньяк Америкадан кергән ул. Борынгы ацтеклар һәм инклар киноаны артык тазарудан иң яхшы дәва дип санаган.
Ярма дип атасак та, чынлыкта ул бөртекле культура түгел, ә алабута төренә керүче үсемлек.
Киноадан боткалар пешерергә, аны ашларга кушарга мөмкин. Ә менә дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА аннан салат әзерләп карарга тәкъдим итә.



Киноа – аксым һәм кеше организмы өчен кирәкле күп кенә аминокислоталар чыганагы. Әлеге файдалы үзлекләре белән ул дөрес тукланырга тырышучыларның игътибарын инде күптәннән үзенә җәлеп итте. Тагын бер үзенчәлеге – бу үсемлектә бөртеклеләрнең күпчелегенә хас булган глютен юк. Югыйсә глютен организмда төрле проблемалар китереп чыгарырга сәләтле.
Ул A, E, C һәм B төркеменә керүче B_1, B_2, B_3, B_5 B_6, B_9 витаминнарына бай.
Составында калий, кальций, фосфор, тимер, цинк, марганец, магний, натрий һәм селен бар.
100 г коры ярмада марганецның көнлек нормасы 102 процентка кадәр җитә.
Киноадагы антиоксидантлар һәм фитонутриентлар организмга зарар салучы иреклe радикалларга каршы көрәшә һәм яман шеш авыруын кисәтә.

Киноадан җылы салат

Кирәк:

- 100 г киноа;
- 200 г шампиньон гөмбәсе;
- 100 г черри помидоры;
- 200 г кузаклы фасоль (стручковая);
- 2 аш кашыгы зәйтүн мае;
- лимон;
- күнҗәт (сим-сим) орлыгы;
- яшел үләннәр;
- тәменчә тоз, борыч.

Эш барышы:

■ башта киноа ярмасын әзерлибез. Моның өчен бер өлеш ярмага ике өлеш су салына. Кайнатып чыгаргач, утны киметеп, ярманы 20 минут пешерәбез. Тизрәк пешсен һәм составындагы фитин кислотасы кимесен өчен, киноаны 4–8 сәгать буе лимон суты яки алма серкәсе салынган суда чылатсаң яхшырак. Бу аның файдалы үзлекләрен арттыра гына.

■ Шампиньоннарны турап, томалап пешерергә куябыз.

■ Кузаклы фасольне кайнап торган суда 3–5 минут пешереп алабыз һәм суын саркытып, гөмбә янына салабыз. Икесен бергә 10 минутлап пешерәбез.

■ Соус өчен лимон сутын зәйтүн мае белән катнаштырып, тоз, борыч, күнҗәт орлыгы һәм ваклап туралган яшел үләннәрне кушабыз.

■ Тәлинкәгә башта пешкән киноаны, аның өстенә гөмбә белән фасольне, черри помидорларын салып, өстеннән әзер соусны сибәбез. Салат җылы килеш ашалырга тиеш.

Киңәш:

Киноалы салат башка төрле соуслар белән дә тәмле. Мәсәлән, 2 йомшак авокадоны, 1 тырнак сарымсак, петрушканы блендерда издереп, 1 чәй кашыгы лимон суты өстәргә, тоз һәм борыч сибеп болгатырга була.

Тагын бер соус:

100 г кешью чикләвеген кичтән чылатып калдырып, иртән блендерда ваклатырга, шуңа 1 аш кашыгы горчица порошогы, 1 аш кашыгы зәйтүн мае, 120–180 мл су (суны башта 120 мл гына салып карагыз) кушып, яхшылап болгатырга.
Бу соус хәтта майонезны да алыштыра ала.

Фото: Камилә Димөхәммәтова

Сукояр
хатын-кыз

Сукояр – һава стихиясеннән. Бәлки, шуңадыр, бу йолдызлыкта туган хатын-кызлар күзаллауга бай, сизгер күңелле, үзгә фикер йөртәләр, зирәкләр, теләсә нинди эшне башкарып чыгарга сәләтлеләр. Алар акыллы, гаҗәпләндерә беләләр, кызыклы әңгәмәдәшләр, авыр бәхәсләрне дә шаяртуга борып җибәрә алалар. Сукоярларны тануы авыр түгел – алар нечкә зәвыклы, шуның белән игътибарны җәлеп итәләр дә. Тормышның төрле өлкәләреннән хәбәрдар, күп укыйлар, гомер буе үзләрен камилләштерәләр. Бер урында утыру алар өчен түгел.

Мәхәббәт

Чибәр һәм экстравагант Сукоярлар бик тиз гашыйк булучан. Ләкин күп вакыт тирән, җитди хисләр түгел бу. Чынлап торып яратырга алар хәтта курка да бугай. Ир-аттан идеаль мөнәсәбәтләр көтәләр. Күңеле бәхетле пар тормыш турында хыялланса да, кандидатларның юк кына гаебе өчен дә араларны шундук өзәргә мөмкиннәр. Иң кызыгы шунда: еш кына алар бөтенләй үзләренә туры килми торган егетләрне сайлый. Кучкар, Игезәкләр, Бизмән, Чаян йолдызлыгында туган ир-егетләр белән яхшы пар була алырлар иде.

Мөнәсәбәтләр

Дуслыкны Сукоярлар кебек бәяли белүчеләр тагын бар микән? Дуслык алар өчен хәтта мәхәббәттән дә өстенрәк. Сөйгән яр тагын булыр, ә чын дус сирәк очрый, аны сакларга кирәк дип уйлый алар. Дуслары да үзенә охшаган: интеллектуальләр, югары культурага омтылалар. Дусларга ярдәм кирәксә, Сукояр берни белән дә исәпләшми. Бу мөнәсәбәтләр күбрәк ана белән бала мөнәсәбәтләрен хәтерләтә. Дустын ул беркайчан сатмас, гаепләмәс.

Гаилә

Рухи яктан бик көчле ир-егетләр генә Сукоярлар белән яши ала. Аларны мускул һәм акча белән генә кызыктырырмын димә. Аңа үзе кебек хыялый, әмма иң матур кешелек сыйфатларына ия зат кирәк. Сукояр белән гаилә тормышы беркайчан да күңелсез булмаячак.

Карьера

Сукоярлар үтә дә төгәл, җаваплы һәм амбициоз хезмәткәрләр. Ул беркайчан да ялкауланмас, әгәр дә туктаусыз күзәтеп һәм ашыктырып тормасалар, эшен бик яхшы итеп башкарып чыгар. Зирәклеге һәм җор телле булуы аркасында теләсә кем белән уртак телне тиз таба.

йолдызнамә
март

Кучкар. Март хаталар өстендә эшләү һәм кимчелекләрне төзәтү өчен кулай вакыт. Максатыгызга ирешү өчен ниләр комачаулаганын да аңларсыз. Бу айга планнарыгыз зурдан булса да, яңа, зур эшләр башламый торуыгыз хәерле.

Үгезбозау. Беренче планга аралашу, очрашу ихтыяҗы чыгачак. Күңелегездәге идеяләрне тормышка ашыру өчен, бу очрашуларның файдасы да булыр. Карьера, алдагы перспективаларны кайгырту өчен яхшы вакыт.

Игезәкләр. Гаҗәеп тыныч ай, чөнки Игезәкләр Меркурий тәэсирендә. Бу айда сезгә берни дә комачауламас, бар да үз җае белән хәл ителер. Барысын да уйлап, җитди карарлар кабул итү өчен уңай чор.

Кысла. Еллык циклның иң мавыктыргыч көннәре. Теләкләр һәм мөмкинлекләр бик сирәк очракта туры килә, ә менә хәзер сезнең өчен нәкъ шундый вакыт. Бик көчле энергетик кыр үзе ярдәм итәчәк, файдаланып калыгыз.

Арыслан. Катлаулы булса да, тормышын үзгәртергә теләүчеләр өчен яңа мөмкинлекләр ачылган ай. Тырышлык һәм хезмәт сөючәнлегегез беренче планга чыгар. Ниятегезне тормышка ашырыр өчен шул ярдәм итәчәк.

Сөмбелә. Ай уңышлы булыр. Бу тормышның бөтен өлкәләрендә дә бәхет елмаер дигәнне аңлатмый, шулай да күп нәрсә сезнең файдага хәл ителер. Үз эшегезне башлар, тормышка яңалык кертер өчен бик кулай чор.

Бизмән. Гадәти булмаган карарлар кабул итәргә туры килер. Бәхетегезгә, алар барысы да сезнең файдага булыр, һәм нәтиҗәдә, көткәннән дә артыграк уңышка ирешерсез. Тормышыгызда нindидер үзгәрешләр көтелә.

Чаян. Тырышырга туры килер. Барысын да үз кулыгызга алып, кыю эш иткәндә генә уңышка ирешерсез. Төрле юнәлешләрдә үзегезне сынап карар өчен яхшы вакыт, ләкин игътибарыгызны юк-барга сарыф итүдән сакланыгыз.

Укчы. Теләсә нинди ситуациядән җиңүче булып чыгарсыз. Ләкин моның өчен бик зур тырышлык күрсәтергә туры килер. Яхшырак вакытны көтеп утырыр чак түгел, үз дигәнегездә нык торыгыз, үзегезчә эшләгез.

Кәҗәмөгез. Вакыйгаларга бай ай. Хисләрегезне йөгәндә тотмасагыз, шәхси тормышта нindидер аңлашылмаучылык килеп чыгуы ихтимал. Аның каравы, тормышка карашыгыз үзгәрер, моңарчы күрмәгән нәрсәләргә күзегез ачылыр.

Сукояр. Тирә-юнегездә вакыйгалар үзгәреп торса да, сезнең өчен бик тыныч ай булыр. Моңарчы уйлаган ниятләрегезне тормышка ашыра башларга мөмкин. Ләкин бөтенесен бергә колачламагыз, әздән башлагыз.

Балык. Яңа мөмкинлекләр һәм перспективалар ае. Сезгә бары кайсы юнәлештә эш итәргә кирәген генә сайларга кала. Мотивация белән бәйле проблемалар туарга мөмкин. Фикердәшләрегез булса, бу гына комачаулык итмәс.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.







Фото: Анна Арахамия

БИШБАЛТА ҖИЛЕ

Атаклы Вера Мухинаның әтисе Игнатий Кузьмич бервакыт кызы ясаган рәсемгә игътибар итә. Кыз арба ясаган, ә аның астыннан итекле ир-ат аяклары тырпаеп тора икән. «Игътибарлы, рәссам булачак!» – ди әтисе һәм гимназиядән укытучы яллый. Героинябыз, Казакъстанда туып, 12 яшендә әти-әниләре белән Казанга күчеп килгән Зөлфия Мөхәммәтҗанова белән дә шуңа охшаш хәл кабатлана.

Новотроицк авылы мәктәбендә укучы Зөлфия дә рәсем ясау белән мавыгып китә, «Рәссам» түгәрәгенә йөри башлый. Рәсем ясау кызны илһамландыра, аңарда игътибарлылык, предметны анализлау, мөстәкыйльлек кебек сыйфатларны үстерә. ВУЗның психология факультетында уку белән беррәттән, Казан художество училищесында скульптура белгечлеге буенча да белем ала. Ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнмичә, Зөлфия В. И. Суриков исемендәге сәнгать академиясе филиалын тәмамлый.

«Мин училищега кергәндә «Скульптура» дигән яңа бүлек ачылды. Кызыксына калдым. Сәнгатьнең бик катлаулы юнәлеше икәнен белгән булсам, йөз кат уйлаган булыр идем», – дип көлә Зөлфия.

Буяулар белән яктылык эффекты тудыручы рәссамнан аермалы буларак, скульптор төшкән яктылыкны дөрес таратып һәм эш өслегендә күләгәләр ясап, бары тик тышкы яктылыкка гына таянырга тиеш. Шуңа күрә аның скульптуралары һәрвакыт хәрәкәттә, алар кинәт искән җил кебек.

Пространстволы скульптура – бүген иң динамик үсештәге сәнгать төре. Хәзер заманча скульптура һәм керамика яки металл эшләнмәләр арасында чикләрне дә аеру кыен. Скульптор һәм индустриаль дизайнерның роле бер-берсенеке белән шулкадәр охшаш – хәтта скульптур техниканы дизайнда да кулланалар.

Скульптор өчен үз эшенең кайда урнашуы бик мөһим. Кызыклы иҗади эш, конкурсларда, күргәзмәләрдә катнашу, Мәдәният министрлыгы заказларын үтәү... 2015 елда иҗат ителгән беренче мөстәкыйль эше «Берег» Харис Якупов исемендәге конкурста җиңеп, премиягә һәм стипендиягә лаек була. 2016 елда Зөлфиянең эшләре Кремль территориясендә урнашкан «Сугышчы рухы» күргәзмәсен бизәүдә катнаша. 2017 елда Болгардагы беренче зур эше «Рәбыйга» шулай ук күпләрдә кызыксыну уята. Зөлфия Адмиралтейская бистәсендә урын алган «Бишбалта» скульптур композициясен иң зур уңышларының берсе саный. Бишбалта – Казанның борынгы өлешенә урнашкан. Бу бистәдә балта осталары – агач белән эшләүчеләр яшәгән. Якындагы Идел култыгына – бухтага күпсанлы сәүдә кораблары һәм хәрби корабльләр керә торган булган. Казан татарларының борынгы бабалары суднолар төзү өчен тирә-яктагы имән, нарат урманнарыннан файдаланган. Казанда ясалган корабларда аларның татар исемнәре дә сакланып калган. Ярма, тоз һәм башка түгелә торган йөкләр өчен насадлар кулланылган. Текстиль әйберләрне, мех эшләнмәләрен учаннарга төягәннәр. Учан – уртача зурлыктагы судно. Кирәк булса, хәрбиләрне күчерү өчен дә кулланылган ул.

Казанда елга суднолары төзү эше Петр I игътибарын да җәлеп иткән, һәм патша Каспий флоты өчен суднолар ясаучы һәм җиһазлаучы урын, ягъни адмиралтейство итеп Бишбалтаны сайлаган.

«Яши-яши, башта хыялда идея туа, әкренләп аны тормышка ашыра башлыйсың. Аннары инде скульптура үз тормышы белән яши башлый... » – ди Зөлфия.

Зөлфиянең иҗади гаиләсендә бер кыз, бер малай үсә. Ире – ышанычлы таянычы: зур һәм катлаулы эшләрне башкарып чыгарга ул булыша.

Рәмзия КАШАПОВА











ЗӨЛФИЯ МӨХӘММӘТҖАНОВА



2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



Фото: Анна Арахамия

Николай ДЕМЬЯНОВ.
Яшел Үзән районы,
Рус Әҗиле авылы.

Николай татарча икенче сыйныфта укыганда сөйләшә башлый. Чуашстан Республикасы Урмар районы Тегеш авылында туып-үскән малай нәкъ шушы яшендә Яшел Үзән районындагы Бакырчы авылына җәйгелеккә көтү көтәргә яллана. Җәй буе татар авылында яткан малай көзгә татарча өйрәнеп кайта. Мәктәпне тәмамлаганчы бу авылга эшкә йөри ул. Аннары армиягә китә. Аннан кайткач, үзләреннән ерак булмаган Яшел Үзән районының Рус Әҗәле авылына килеп, сөт ташый торган машинага утыра. Бу вакытта ул татар телендә чип-чиста сөйләшә инде. Үз туганнары белән генә чуашча аралаша.

Кечкенә чакта Николай: «Мин татар кызына гына өйләнәм», – дип әйтә торган булган. Бик тә токмачлы аш яраткан ул. Ә ул ашны нәзек кенә итеп киселгән өй токмачы белән татар хатыннары гына тәмле итеп пешерә. Ходайның «амин» дигән чагына туры килгәндер: унынчы сыйныфта укыган Сәрия белән таныша. Татар Наратлысы авылына, Гөбнә елгасын кичеп, ике ел йөри ул, аннан соң өйләнешәләр. Ике яктан да әниләр фатиха бирә. (Әтиләре күптән вафат булган.) Мөселман кануны буенча никах укыталар. Өч кыз үстерәләр. Хәзер инде оныклар сөяләр.

Татары, русы бергә дус-тату яшәгән авылда 35 ел гомер кичерә ул. «Гомеремнең күпчелек өлеше Татарстанда, татарлар арасында узды. Татар җырларын тыңларга бик яратам», – ди шат күңелле Николай. Хәтта аның сөйләменә дә шушы якның диалектик үзенчәлекләре сеңгән. Дини ашлар да уздыралар, гөрләтеп май чабу бәйрәмен дә үткәрәләр.
Бер телдә – татар телендә сөйләшәләр.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.


4 612750 670028